# ТӘҮРАТ, ЗӘБУР, ИНҖИЛ
# һәм
# КОРЪӘН

## ОХШАШ УРЫННАР

Изге Китапны тәрҗемә итү институты
Мәскәү
2019

Тәүрат, Зәбур, Инҗил һәм Коръән: охшаш урыннар. – М.: ИПБ, 2018. – 268 бит.

Әлеге китап – мәсихчеләрнең (христианнарның) һәм яһүдләрнең Библия җыентыгын (Тәүрат, Зәбур, Инҗил) тәшкил иткән изге текстлары белән мөселманнарның изге язмасы булган Коръәнне чагыштырып, мәгънә ягыннан үзара охшаш урыннарны берләштерергә тырышуның нәтиҗәсе. Бу хезмәт Библия белән Коръән арасындагы охшашлык һәм аермалыклар турында күбрәк белергә теләүче укучыларга тәгаенләнә.

ISBN 978-5-93943-263-4
© Институт перевода Библии, 2018

# Кереш сүз

Хөрмәтле укучылар, кулыгызга алган әлеге китапта без мәсихчеләрнең (христианнарның) һәм яһүдләрнең Библия җыентыгын (Тәүрат, Зәбур, Инҗил) тәшкил иткән изге текстлары белән мөселманнарның изге язмасы булган Коръәнне чагыштырып, мәгънә ягыннан үзара охшаш урыннарны берләштерергә тырыштык. Әлеге китапны басмага әзерләгәндә без Изге Язманы тәрҗемә итү институты тарафыннан нәшер ителгән «Библия и Коран: параллельные места»* дип аталган рус телендәге хезмәттән файдаландык.

Тәгълимати яктан да, тарихи яктан да бер-берсеннән шактый аермалы булган, төрле диннәргә караган, шулай ук укучылар тарафыннан да төрлечә кабул ителә торган әлеге изге текстларны бер китапка туплап чыгарырга безне нәрсә этәрде соң?

Хәзерге вакытта Изге Китапны тәрҗемә итү институтында элеккеге СССР территориясендә көн күрүче, мөселман традицияләренә нисбәтле халыклар телендә Библияне тулысынча яки өлешчә тәрҗемә итү буенча 45 тән артык проект эшләп килә. Һәр халыкның мәдәниятенә, аның дөньяга үзенчәлекле карашына, гореф-гадәтләренә таянмыйча сыйфатлы тәрҗемә була алмаганны без яхшы аңлыйбыз. Шуңа күрә Библиянең тәрҗемәсе мөселманнарга мөмкин кадәр аңлаешлы булсын өчен, без һәрвакыт мәсихчеләр, яһүдләр һәм мөселманнарның изге текстлары арасындагы бәйләнешне күрсәтергә тырышабыз. Беренче тапкыр параллель рәвештә нәшер ителгән әлеге текстларны чагыштырып уку шул текстларның асылына төшенергә ярдәм итми калмас, дип уйлыйбыз. Ә тирәнтен аңлау, табигый ки, сыйфатлырак тәрҗемә итәргә мөмкинлек бирә.

Библиягә тарихи-тәнкыйди күзлектән чыгып карауучылар белән килешмәүче мәсихчеләр һәм «Коръән, Аллаһы Тәгалә кебек үк, дөнья яратылганчы булган инде» дип санаучы мөселманнар өчен әлеге изге текстларның төп чыганаклары һәм әдәби язмышы

* Библия и Коран: параллельные места. Составители М. Беерле-Моор, А. Десницкий, К. Казенин, Т. Майская. Москва: Институт перевода Библии, 2005, 2012.

турындагы сорау үзе үк хата кебек тоела. Алай да, изге язмалар турындагы тәгълиматны, аларның тарихи һәм әдәби яктан бер-берсенә бәйләнгән булу мәсьәләсен кузгатмыйча, Библия һәм Коръән белән кызыксынучылар текстлардагы үзара охшаш урыннарны өйрәнүдән файда гына табар дип уйлыйбыз.

Әлеге китап, тирән һәм колачлы анализга дәгъва итмәстән, Библия белән Коръәндәге охшаш урыннарны тикшерүдә бер тәҗрибә булып тора. Китапны төзегәндә без Библиядә урын алган вакыйгаларга Коръән битләрендә тәңгәл килүче текстларны сайлап алган идек. Биредә эш әлеге басманың Изге китапны (Библияне) тәрҗемә итү институтында әзерләнүендә генә түгел. Ни генә әйтсәң дә, Библия Коръәнгә караганда элегрәк иҗат ителгән, өстәвенә Коръән Библиядә тасфирланган вакыйгаларның күбесе белән инде таныш булган кешеләргә мөрәҗәгать итә.

Китапның эчтәлеген Библиядән һәм Коръәннән китерелгән, бүлекләргә салынган өзекләр тәшкил итә. Бүлекләрнең тематикасын, шулай ук өзекләрне сайлауда субъективлык катнашмый калмагандыр. Библиядә дә, Коръәндә дә Ибраһим, Йосыф, Муса, Гайсә – төп каһарманнар. Ә менә Библиядә телгә алынган Гедеон гаскәре Коръәндә Талут патша гаскәре дип бирелә. Укучы игътибар итми калмас: китапның күп кенә урыннарында Библиядә телгә алынган бер өзек белән Коръәннең төрле урыннарыннан китерелгән берничә өзек чагыштырыла. Моның сәбәбе шунда ки, Библиянең күпчелек китаплары тарихи хикәяләү рәвешендә бирелгән, ә Коръән аятьләрен исә, кагыйдә буларак, сюжет сызыгы түгел, ә бәлки рухи тематика берләштерә. Хәер, шуның киресе дә очрый: мәсәлән, Йосыфка багышланган урыннарны без Библиядәге Яратылыш китабының берничә бүлегеннән укып беләбез, ә Коръәндә исә Йосыф кыйссасы тулысынча 12 нче сүрәдә бирелә.

Изге китапның һәр икесендә очраган каһарманнар турындагы мәгълүматтан тыш, әлеге җыентыкта Аллаһы һәм галәм, азатлык һәм җаваплылык, ир һәм хатын арасындагы мөнәсәбәтләр, тынычлык һәм сугыш мәсьәләләренә кагылышлы параллель урыннар да бар. Шушы темаларга багышланган өзекләрнең барсысын да әлеге кечкенә китапта китерү мөмкин түгел – без иң мөһим саналганнарына тукталып үтәргә тырыштык.

Сүз дә юк, яһүдләр, мәсихчеләр һәм мөселманнар диненә кагылышлы башка чыганакларны чагыштыру да күп кенә кызыклы материал бирә алыр иде. Мәсәлән, яһүдләрнең мидрашларында һәм таргумнарында без «Сөләйман патшага җеннәр буйсынган» дип укыйбыз, Коръәндә дә шулай ук диелә. Әмма бар нәрсәне колачлап бетерү мөмкин түгел, шуңа күрә бу китапта без Коръән һәм Библияне чагыштыру белән генә чикләндек. Киләчәктә бу эшне башкалар дәвам итәр, тулыландырыр дип өметләнәсе килә.

Мәгълүм булганча, Коръән китабын тәрҗемә итүне ислам дине бик өнәп бетерми. Әмма әлеге басмада Коръән текстларын гарәп телендә бирү үзен акламас иде. Изге язмалар текстын чагыштыруда арадашчы ролен биредә татар теле башкара. Коръәннән алынган өзекләр – XIX нчы гасырда Ногмани тәрҗемә иткән «Коръән тәфсире»ннән*, Библиядән алынган өзекләр 2015 нче елда нәшер ителгән «Изге Язма» китабыннан китерелә.

Әлеге басманың азагында Коръәндә очраган гарәп алынмалары сүзлеге бирелә.

Барлыкка килгән көненнән үк изге дип кабул ителгән Коръән белән Библия арасындагы охшашлык һәм аермалыклар турында күбрәк белергә теләүче укучылар өчен бу хезмәт файдалы һәм кызыклы булыр дигән өметтә калабыз.

*Изге Язманы тәрҗемә итү институты*

* Коръән тәфсире. Казан: Татарстан китап нәшрияты, 1992.

# Тәүрат, Зәбур, Инҗилдән алынган китапларның тулы һәм кыскартылган исемнәре

## Тәүрат

| | |
|---|---|
| Яратылыш | Яратылыш |
| Чыгыш | Чыгыш |
| Левиләр | Левиләр |
| Саннар | Саннар |
| Канун | Канун |
| Хөкемчеләр | Хөкемчеләр |
| Патшалар (беренче китап) | I Патшалар |
| Патшалар (икенче китап) | II Патшалар |
| Патшалар (өченче китап) | III Патшалар |
| Патшалар (дүртенче китап) | IV Патшалар |
| Елъязма (беренче китап) | I Елъязма |
| Әюб | Әюб |
| Сөләйман патшаның гыйбрәтле сүзләре | Гыйбрәтле сүзләр |
| Ишагыйя пәйгамбәр | Ишагыйя |
| Иремия пәйгамбәр | Иремия |
| Яхәзкыл пәйгамбәр | Яхәзкыл |
| Йоил пәйгамбәр | Йоил |
| Амос пәйгамбәр | Амос |
| Юныс пәйгамбәр | Юныс |
| **Зәбур** | Зәбур |

# Инҗил

| | |
|---|---|
| Маттай бәян иткән Яхшы хәбәр | Маттай |
| Марк бәян иткән Яхшы хәбәр | Марк |
| Лүк бәян иткән Яхшы хәбәр | Лүк |
| Яхъя бәян иткән Яхшы хәбәр | Яхъя |
| Ягъкубтан хат | Ягъкубтан хат |
| Петердән беренче хат | I Петердән хат |
| Петердән икенче хат | II Петердән хат |
| Яхъядан беренче хат | I Яхъядан хат |
| Паулдан римлыларга хат | Римлыларга хат |
| Паулдан көринтлеләргә беренче хат | I Көринтлеләргә хат |
| Паулдан көринтлеләргә икенче хат | II Көринтлеләргә хат |
| Паулдан гәләтиялеләргә хат | Гәләтиялеләргә хат |
| Паулдан эфеслеләргә хат | Эфеслеләргә хат |
| Паулдан филиппуйлыларга хат | Филиппуйлыларга хат |
| Паулдан көлессәйлеләргә хат | Көлессәйлеләргә хат |
| Паулдан тессалуникәлеләргә беренче хат | I Тессалуникәлеләргә хат |
| Паулдан Тимутәйгә беренче хат | I Тимутәйгә хат |
| Паулдан Тимутәйгә икенче хат | II Тимутәйгә хат |
| Паулдан Титуска хат | Титуска хат |
| Гыйбриләргә хат | Гыйбриләргә хат |

## Дөньяның яратылышы

**Яратылыш 1**

1 Әүвәл Аллаһы күкне һәм җирне яратты.

2 Җир йөзе әле сурәтсез, буп-буш — төпсез упкын, караңгылык эченә чумган; Аллаһының рухы-сулышы сулар өстендә гизә иде.

3 Аллаһы: «Яктылык булсын!» — дип боерды, һәм яктылык булды.

4 Аллаһы яктылыкның яхшы булуын күрде һәм аны караңгылыктан аерды.

5 Яктылыкны «көн» дип, караңгылыкны «төн» дип атады. Кич булды, иртә булды — бер көн кичте.

6 Аллаһы: «Суларның уртасында бер гөмбәз булсын, суларны бер-берсеннән аерсын!» — дип боерды.

7 Нәкъ шулай булды: Аллаһы гөмбәзне яратты. Гөмбәз астындагы суларны гөмбәз өстендәге сулардан аерды.

8 Аллаһы гөмбәзне «күк» дип атады. Кич булды, иртә булды — икенче көн кичте.

9 Аллаһы: «Күк астындагы сулар бер урынга җыелсын да, коры туфраклы ялан калкып чыксын!» — дип боерды, һәм нәкъ шулай булды.

10 Аллаһы коры туфрак яланын «җир» дип, җыелган суларны «диңгез» дип атады.

ТӘҮРАТ

## Дөньяның яратылышы

**16 сүрә**

3 Аллаһ җир вә күкләрне хак төзү белән төзеде, Ул — Аллаһ — мөшрикләр сыйфатлаган тиңдәшлек сыйфатларыннан пакь.

**3 сүрә**

190 Дөреслектә, җир вә күкләрнең төзелешендә һәм төн илә көннең бер-берсенә хилаф булышында гакыл ияләренә Аллаһуның барлыгына һәм берлегенә ышанырга, әлбәттә, көчле дәлилләр бар.

**21 сүрә**

16 Без җир вә күкне һәм араларында булган нәрсәләрне уйнап, бушка гына төземәдек.

**46 сүрә**

3 Без җир вә күкләрне һәм аларның араларында булган нәрсәләрне һәрьяклап дөресләп төзедек, кыяматкә хәтле торсыннар өчен.

**11 сүрә**

7 Аллаһ җир вә күкләрне алты көндә төзеде, аңа хәтле Аллаһуның гарше су өстендә иде...

**21 сүрә**

30 ...җир вә күкләр бергә кушылган иделәр, Без аларны аердык вә һәр терек мәхлукны судан халык кылдык. <...>

32 Без күкне түшәдек мәхкәм сакланмыш түбә итеп...

КОРЪӘН

Аллаһы боларның яхшы булуын күрде.

11 Аллаһы: «Туфрактан яшеллекләр үсеп чыксын, төренә күрә орлык бирә торган төрле үләннәр, җимешендә үз төренең орлыгын өлгертә торган җимеш агачлары үссен!» — дип боерды, һәм нәкъ шулай булды.

12 Җир өстендә яшеллекләр, төренә күрә орлык бирә торган үләннәр, җимешендә үз төренең орлыгын өлгертә торган җимеш агачлары үсеп чыкты.
Аллаһы моның яхшы булу-
ын күрде. 13 Кич булды, иртә
булды — өченче көн кичтә.

14-15 Аллаһы: «Күк гөмбәзендә җир йөзен яктырта торган, көнне төннән аера торган яктырткычлар булсын! — дип боерды. — Алар вакыт, ел фасылы һәм көн исәбе галәмәтләрен күрсәтеп торсыннар». Һәм нәкъ шулай булды.

16 Аллаһы ике бөек күк җисемен — зурысы көн белән, кечесе төн белән идарә итүче яктырткычларны һәм йолдызларны яратты.

17-18 Җир йөзен яктыртып, көн вә төн белән идарә итсеннәр һәм яктылыкны караңгылыктан аерып торсыннар өчен, Аллаһы аларны күк гөмбәзенә урнаштырды. Һәм моның яхшы булуын күрде.



**2 сүрә**

29 Ул — Аллаһ — җирдәге барча нәрсәне сезнең өчен халык кылды, соңра күкне төзергә теләде һәм күкне җиде кат итеп тергезде.

**27 сүрә**

61 Җирне селкенми торган итеп яраткан Аллаһ хәерлеме, дәхи җир өстендә күп елгалар кылды һәм җир өстенә бөек таулар кылды һәм диңгездә ике төрле су арасына пәрдә кылды — бер-берсенә аралашмаслар. Әйә Аллаһудан башка тагын бер илаһ бармы? Бәлки мөшрикләр Аллаһуның бер генә икәнен белмиләр.

**67 сүрә**

3 ...Аллаһ халык кылган нәрсәләрдә үлчәүсезлекне күрмәссең. Күзеңне күтәреп күккә карагыл: анда берәр ярыкны, кимчелекне күрерсеңме?

**16 сүрә**

10 Аллаһы күктән яңгыр яудырып сезгә елгалар бар итте вә агачлар үстерде, вә шулардан хайваннарыгызны ашатыр вә эчертер булдыгыз.

11 Вә ул су белән безгә иген, зәйтүн агачы, хөрмә агачы, йөзем агачлары вә башка төрле җимешләрне үстерер; фикерле белгән кешеләр өчен бу әйтелгән нәрсәләр вә Аллаһуны тану өчен дәресләр бар.





19 Кич булды, иртә булды — дүртенче көн кичтә.

20 Аллаһы: «Сулар терек җан ияләре белән тулып ашсын, җир йөзе өстендә һәм күк гөмбәзе астында кошлар очып йөрсен!» — дип боерды.

21 Һәм Аллаһы зур диңгез җанварларын, төрләренә карап суда кайнашкан барлык җан ияләрен, барлык төр очар кошларны яратты. Моның яхшы булуын күрде.

22 Аллаһы аларга Үзенең фатихасын бирде: «Үрчегез, ишәегез, диңгез суларын тутырыгыз, җир йөзендә кош-корт үрчегәннән-үрчесен!» — диде.

23 Кич булды, иртә булды — бишенче көн кичтә.

24 Аллаһы: «Җир йөзе үзендә төрле токымдагы җан ияләрен — кыргый хайваннарны, терлек һәм хәшәрәтләрне булдырсын!» — дип боерды. Һәм нәкъ шулай булды.

25 Аллаһы җир йөзендә төрле токымдагы җан ияләрен — кыргый хайваннарны, терлек һәм хәшәрәтләрне яратты. Моның яхшы булуын күрде.

26 Аллаһы: «Кешене Үз сурәтебездә, Үзебезгә охшатып яратачакбыз, — диде. — Кеше диңгездәге балыклар, күктәге кошлар, җирдәге хайваннар — җирдә хәрәкәт итүче барлык тереклек һәм хәшәрәтләр өстеннән,



12 Вә сезнең файдагызга кичне вә көнне һәм ай вә кояшны бар кылды һәм хәрәкәтләндерде — сез алардан файдаланасыз, вә йолдызлар Аллаһ әмере буенча хәрәкәт итәләр; гакылын эшләтә белгән кешеләр өчен Аллаһуның бу эшләрендә, әлбәттә, тирән дәресләр бар.

**6 сүрә**

141 Аллаһу Тәгалә биек вә түбән агачлы җимеш бакчаларын вә хөрмә агачларын һәм игеннәрне төсләрен, тәмнәрен төрлечә итеп, дәхи зәйтүн, гранат агачларын бер-берсенә охшаган һәм охшамаган хәлләрендә халык кылды; өлгергәч һәрберсенең җимешләрен ашагыз һәм уңышларын алганда тиешле өлешен садака итеп бирегез! Аллаһ биргән ризыкларны бернинди юл белән әрәм-шәрәм итмәгез! Бит Аллаһ әрәм итүчеләрне һич сөйми.

**6 сүрә**

95 Шиксез, Аллаһу Тәгалә вак орлыкларны һәм җимеш төшләрен яручы, ягъни җиргә салган һәр орлыкны үстерүче, Ул үлектән терене чыгарыр вә теректән үлене чыгарыр; бу эшләрне эшләүче — Аллаһудыр...

**16 сүрә**

5 Вә хайваннарны халык кылды, ул хайваннардан сезгә

җир йөзе өстеннән хакимлек итсен!»

27 Шулай итеп, Аллаһы кешене Үз сурәтендә, Аллаһыга охшатып яратты. Кешеләрне ир-ат һәм хатын-кыз итеп яратты.

28 Аларга фатихасын бирде: «Үрчегез, ишәегез! – диде. – Җир йөзен тутырыгыз, аны буйсындырыгыз; диңгездәге балыкларга, күктәге кошларга, җир йөзендә хәрәкәт иткән барлык җан ияләренә хуҗа булыгыз!»

29 Аллаһы әйтте: «Менә, туфракта орлыктан үсә торган һәрбер үләнне, җимешендә орлыгы өлгерә торган һәрбер җимеш агачын сезгә тапшырам: алар сезгә ризык булсын! – диде. –

30 Җир йөзендәге һәрбер хайванга, күктәге һәрбер кошка, үзендә тереклек сулышын тойган һәрбер җанварга азык итеп яшел үлән насыйп итәм». Һәм нәкъ шулай булды.

31 Аллаһы Үзе яраткан нәрсәләрне күздән кичерде һәм, менә, һәр нәрсәнең гаять яхшы икәнлеген күрде. Кич булды, иртә булды – алтынчы көн кичте.

**Яратылыш 2**

1 Күкнең һәм җирнең, андагы бөтен нәрсәнең яратылышы әнә шулай тәмамланды.



сөт, йон вә башка файдалар бар, вә бугазлап итләрен ашыйсыз.

6 Ул хайваннарны иртә белән кырга чыгарганда вә кич белән өегезгә кайтарганда сезгә зиннәт вә шатлыктыр.

7 Вә ул хайваннарга йөкләр төяп ерак шәһәрләргә зур мәшәкать белән төрле әйберләр илтәсез; әлбәттә, Раббыгыз сезгә шәфкатьле вә рәхимле.

8 Янә сезгә зиннәт өчен вә атланыр өчен, йөк йөкләр өчен ат, качыр, ишәкләрне яратты һәм дә сез белмәгән нәрсәләрне халык кыла.

**67 сүрә**

15 Ул – Аллаһ – сезгә җирне йөрергә уңай кылды, ул җирнең җилкәсендә йөрегез, теләгән җирендә яшәгез вә ул җирнең хәләл ризыкларын ашагыз; вә үлгәннән соң терелеп бармак Аллаһу хозурынадыр.

**6 сүрә**

142 Янә хайваннардан йөкләр күтәрә торганын һәм йоннарыннан түшәк ясала торганын халык кылды, вә ашагыз-эчегез Аллаһ ризыкландырган хәләл-пакь ризыклардан вә шайтан эзенә иярмәгез! Ул сезгә – ачык дошман.

143 Аллаһу Тәгалә сезнең өчен дүрт пар – сигез женесне халык кылды, аларны сезгә хәләл итте: куй-сарыктан





ДӨНЬЯНЫҢ ЯРАТЫЛЫШЫ

2-3 Аллаһы Үз эшен җиденче көнгә бетерде. Җиденче көнне Ул мөбарәк кылды. Аны изге бер көн итәрәк аерды. Чөнки Аллаһы, бөтен эшлисе, башкарасы эшләрен тәмамлап, ул көнне ял итте.

ТӘҮРАТ

бер парны, кәҗәдән бер парны. Әйт: «Аллаһ куй вә кәҗә иркәкләрен һәм ана куйны вә ана кәҗәне хәрам кылдымы? Яки куй вә кәҗә карынындагы бәрәннәрне хәрам кылдымы? Әгәр боларны хәрам кылган булса, дәлилләрегезне миңа күрсәтегез дөрес сөйләүчеләрдән булсагыз», – дип.

144 Янә Аллаһ сезнең өчен ата дөяне вә ана дөяне һәм үгез белән сыерны халык кылды һәм хәләл итте. Әйт: «Ата дөяне вә үгезне һәм ана дөя белән сыерны яки аларның карыннарындагы балаларны Аллаһ хәрам кылдымы? Яки сез шаһит булдыгызмы Аллаһуның бу хакта васыять әйткән чагында...»

**32 сүрә**

4 Аллаһ җир вә күкләрне һәм араларында булган нәрсәләрне алты көндә яратты, соңра Аның әмере гарешкә беркетелде. Ий Коръән белән гамәл кылучылар, сезгә Аллаһудан башка файдалы хуҗа юк һәм шәфагать итәчәк аять тә юк, әллә вәгазьләнмисезме?

5 Аллаһ үзенең әмерен күктән җиргә индерер, соңра ул әмер яки тәдбир Аллаһуга менәр, сез саный торган дөнья еллары белән мең ел озынлыктагы бер көндә.

КОРЪӘН

6 Яратучы вә тәдбир итүче Аллаһ яшеренне дә, ачыкны да белүче, һәр эштә җиңүче вә рәхимледер.
7 Ул – Аллаһ – һәрнәрсәне күркәм итеп халык кылды...

**50 сүрә**

38 Тәхкыйк, Без җирне вә күкләрне вә аларның араларында булган нәрсәләрне алты көн эчендә төзедек, аларны төзегәндә Безгә мәшәкать вә авырлык ирешмәде.

**7 сүрә**

54 Тәхкыйк, Раббыгыз – Аллаһ – алты көн эчендә Җирне вә Күкләрне төзеде, соңра боерыгы гарешкә карарланды. Аллаһу Тәгалә төн караңгысы белән көнне каплар, ул төн көнне ашыгып өстәр, ягъни туктамыйча бер-бер артлы килеп торырлар; Кояш, Ай вә йолдызлар Аллаһ әмере буенча йөриләр, агаһ булыгыз! Халык кылмак, һәр эшкә әмер бирмәк Аллаһ эше түгелме? Барча галәмне тәрбия итүче Аллаһ бәрәкәт иясе булды.
55 Аллаһуга зарыйлык кылып хаҗәтләрегезне сорагыз! Сорауда чиктән чыгучыларны Аллаһ, әлбәттә, сөйми...
56 Пәйгамбәрләр җибәреп ислях кылганнан соң Җир өстендә бозыклык кылмагыз! Газабыннан куркып, рәхмәтен өмет итеп Аллаһуга гыйбадәт







кылыгыз һәм хаҗәтләрегезне сорагыз! Коръән юлы белән изге гамәлләр кылучыларга, әлбәттә, Аллаһуның рәхмәте якын.

# Кешене бар кылу

**Яратылыш 2**

4 Җир вә күкнең яратылышы менә шулайдыр. Раббы Алла җирне һәм күкне яратканда

5 җир йөзендә әле берниндн дә куаклык, чирәм-яшеллекләр юк, чөнки Раббы Алла җир өстенә яңгыр яудырмаган һәм җирне эшкәртер өчен кеше дә юк иде.

6 Шулай да җирдән булар күтәрелеп, бөтен туфрак өстен дымландырып тора иде.

7 Раббы Алла адәмне туфрактан яратты һәм аның борын тишекләренә тереклек сулышы өрде. Адәм әнә шулай җан иясе булды.

8 Раббы Алла көн чыгышы тарафында, Гадәндә, бер бакча булдырды һәм туфрактан яратылган адәмне шунда урнаштырды.

9 Раббы Алла бакчада тәмле җимешләр бирә торган төрле-төрле гүзәл агачлар, бакчаның уртасында тереклек агачы белән яхшылыкны һәм яманлыкны таныта торган белем агачы да үстерде.

10 Бакчадагы туфракны сугару өчен, Гадәннән бер елга агып чыга да дүрт ермакка аерыла иде. <...>

15 Раббы Алла, адәмне Гадән бакчасына урнаштырганда,

ТӘҮРАТ

# Кешене бар кылу

**32 сүрә**

6 Яратучы вә тәдбир итүче Аллаһ яшеренне дә, ачыкны да белүче, һәр эштә җиңүче вә рәхимледер.

7 Ул — Аллаһ — һәрнәрсәне күркәм итеп халык кылды вә Адәм г-мне балчыктан халык кыла башлады.

8 Соңра нәселен халык кылды бер тамчы судан.

9 Соңра Адәмне халык кылуны тәмам итте, соңра Адәмне җанлы итте үзе теләгән рухны аңа өрү белән; вә ишетмәк өчен сезгә колак яратты, вә күрмәк өчен күз яратты, вә аңламак өчен күңел яратты; бу әгъзаларның Раббысына аз шөкер итәсез.

**23 сүрә**

12 Тәхкыйк, Без Адәмне саф балчыктан яраттык.

13 Соңра Адәмнең нәселен ана карынында мәни кылдык.

14 Соңра мәнине каты кан итеп яраттык, соңра ул каты канны чәйнәлгән ит кеби кыйлдык, соңра ул итне сөяк иттек, соңра ул сөяккә ит кидердек, соңра аны икенче төрле халык иттек, ягъни аңа җан бирдек, яратучыларның күркәмрәге булган Аллаһ олугъ булды.

КОРЪӘН





аңа бакчаны саклап тору һәм эшкәртү хезмәтен йөкләде.

16 Аңа әйтте: «Бакчадагы теләгән һәр агачның җимешен ашарга рөхсәт,

17 әмма яхшылыкны һәм яманлыкны таныта торган белем агачыннан ашама, чөнки ул агачның җимешен ашаган көнне үк мотлак үләчәксең», — диде.

18 Соңра Раббы Алла: «Адәмне ялгызын калдыру әйбәт түгел, үзенә тиң бер ярдәмчене яратачакмын», — диде.

19 Раббы Алла җирдәге хайваннарның, күктәге кошларның барчасын туфрактан яраткан иде. Һәркайсына нинди исем кушылачагын күрү өчен, Раббы Алла аларның һәммәсен адәм хозурына китерде. Адәм кайсына нинди исем кушса, ул җан иясе шул исем белән танылды.

20 Күктәге кошларга, барлык кыргый хайван һәм терлекләргә адәм исем кушты. Әмма аның үзенә тиңдәш бер генә ярдәмчесе дә юк иде.

21 Раббы Алла адәмне каты йокыга талдырды. Адәм йоклап киткәч, аның кабырга сөякләреннән берсен суырып алып, урынын ит белән каплады.

22 Адәмнән алынган шул кабыргага сөягеннән Раббы Алла бер

ТӘҮРАТ

**38 сүрә**

71 Раббың фәрештәләргә әйтте: «Мин балчыктан Адәмне халык кылачакмын».

72 Аны халык кылып тәмам иткәч, аңа җан кертеп тергездем, фәрештәләр Адәмне зурлап сәҗдәгә бардылар.

73 Фәрештәләрнең барчасы берьюлы сәҗдә кылдылар.

74 Мәгәр Иблис сәҗдә кылмады. Тәкәбберләнде һәм кяферләрдән булды.

75 Аллаһы Тәгалә әйтте: «Ий Иблис, Мин Үз кодрәтем белән яраткан Адәмгә сәҗдә кылудан сине нәрсә тыйды? Тәкәбберләндеңме? Яки бөекләрдән булдыңмы?»

76 Иблис әйтте: «Мин Адәмнән хәерлерәкмен, чөнки мине уттан яраттың, Адәмне исә балчыктан яраттың».

77 Аллаһ әйтте: «Алай булса, җәннәттән чык, тәхкыйк, син рәхмәтемнән сөрелмешсең.

77 Әлбәттә, кыямәт көненә чаклы Минем сиңа ләгънәтемдер».

**2 сүрә**

35 Вә Адәмгә әйттек: «Үзең һәм хатының җәннәттә торыгыз һәм җимешләрен киңлек илә теләгәнчә ашагыз, мәгәр менә бу агачка якын бармагыз, әгәр шуны эшләсәгез, залимнәрдән булырсыз».

КОРЪӘН

хатын-кыз яратты һәм аны адәм хозурына китерде.
[23] Адәм әйтте: «Менә минем сөякләремнән алынган сөяк, менә минем итемнән алынган ит. Аңа „хатын-кыз“ диелер, чөнки ул „ир“дән алынды».
[24] Шуңа күрә ир кеше, атасын һәм анасын калдырып, хатынына кушылыр, һәм алар икесе бер тән булыр.

**Яратылыш 3**

[20] Адәм хатынга Һава дип исем кушты, чөнки ул барлык адәм балаларының анасы иде.

ТӘҮРАТ

**23 сүрә**

[19] Ул су белән сезгә хөрмә, йөзем бакчаларын кылдык, сезнең өчен ул бакчаларда күп җимешләр бар, аларны сез ашыйсыз.
[20] Дәхи Синай тавында үсә торган зәйтүн агачын кылдык, ашаучылар өчен ул агач – май һәм ризыкның төсен үзгәртә торган буяу чыганагыдыр.

**2 сүрә**

[31] Аллаһ Адәмгә һәрнәрсәнең исемнәрен өйрәтте дә фәрештәләргә әйтте: «Әгәр дөрес сөйләүчеләрдән булсагыз, Адәм белгән исемнәрнең барчасын әйтеп бирегез».
[32] Фәрештәләр әйттеләр: «Ий һәр кимчелектән пакь булган Раббыбыз! Бездә һич белем юк, мәгәр Син белдергәнне генә беләбез; Син, әлбәттә, һәр нәрсәне белүче, хикмәт белән эш кылучысың».
[33] Аллаһ Адәмгә әйтте: «Фәрештәләргә исемнәрнең барчасын әйтеп бир», – дип. Адәм исемнәрнең барчасын әйтеп биргәч, Аллаһ фәрештәләргә әйтте: «Мин сезгә әйтмәдеммени җирдәге вә күкләрдәге яшерен нәрсәләрне beләмен һәм сезнең ачык эшләгән вә яшерен эшләгән эшләрегезне дә беләмен дип?»

КОРЪӘН





**7 сүрә**

[189] Сезне бер Адәм г-мнән халык кылучы вә Адәмнең сул кабыргасыннан хатыны Һаваны бар итүче Аллаһ, шул Һава илә Адәмнең күңеле карар тапсын өчен. Кайчан Адәм Һавага якынлык кылды исә, Һава җиңел йөкле булды...

КОРЪӘН

## Күк белән җирне бар иткән Аллаһыга дан

**Зәбур 8**

2 И Хуҗабыз Раббы! Бөектән-бөектер исемең җир йөзендә, шөһрәтең күтәрелгәндер күкләрдән югары!

3 Сабый һәм имчәк балалар теленнән Син, Үзеңә мактаулар яудыртып, дошманның вә үчленең авызын томаладың.

4 Син бар иткән күкләр киңлегенә, күк гөмбәзенә Син утырткан Айга вә йолдызларга баксам,

5 үз-үземә сорау бирәм: «Син шулай игътибар күрсәткән инсан кем ул?! Син шулай кайгырткан адәм баласы кем?!»

6 Кешене Син илаһи затлардан әллә ни ким яратмадың, дан вә кадер-хөрмәт таҗын башына кигездең.

7 Тудырган бар нәрсәң өстеннән хаким иттең аны, бар нәрсәне аның аяк астына салдың:

8 сарыкларны, үгезләрне, дала-кыр киекләрен,

9 күктәге кошларны, диңгездәге балыкларны, диңгез юлларын айкаган барлык җан ияләрен.

10 И Хуҗабыз Раббы! Бөектән-бөектер исемең җир йөзендә!



## Күк белән җирне бар иткән Аллаһыга дан

**67 сүрә**

15 Ул – Аллаһ – сезгә җирне йөрергә уңай кылды; ул җирнең җилкәсендә йөрегез, теләгән җирегездә яшәгез вә ул җирнең хәләл ризыкларын ашагыз...

**24 сүрә**

41 ...дөреслектә, Аллаһу Тәгаләгә җирдә вә күкләрдә булган мәхлукатлар тәсбих әйтерләр, канатларын һавада җәйгәннәре хәлдә кошлар да тәсбих әйтерләр. Тәсбих әйтүчеләрнең барчасы үзләренең намазларын вә тәсбихләрен белер булырлар. Аллаһу Тәгалә ул мәхлукатның ни эшләгәннәрен белүче.

42 Җирдәге һәм күкләрдәге вә аларның араларында булган һәрнәрсә Аллаһ мөлкедер, вә ахирәттә кайту да Аллаһудадыр.

43 Әллә күрмисеңме: Аллаһ болытларны куар, соңра аларны бер-берсенә кушар, соңра аларны берсе өстенә икенчесен кылыр, һәм күрерсең, аларның араларыннан яңгыр чыгар вә Аллаһ шул болытлардан тау күплегендә боз индерер, ул боз белән теләгән кешесен һәлак итәр вә теләгән кешесен коткарыр, вә шул





**Маттай 6**

26 Кошларга карагыз: алар чәчмиләр дә, урмыйлар да, ашлыкны амбарларга да салмыйлар, шулай да аларны Күктәге Атагыз туендыра. Ә сез кошлардан кадерлерәк түгелме соң?

27 Кайсыгыз, кайгырганга карап, үз гомерен бер сәгатькә булса да озайта ала?

28 Кием өчен ник борчыласыз? Кыр чәчәкләренә карагыз, алар ничек үсәләр: эшләмиләр дә, эрләмиләр дә.

29 Әмма сезгә әйтәм: хәтта Сөләйман патша да, никадәр мәһабәт булмасын, аларның берсе кадәр дә киенә алмаган.

30 Бүген кырда үсеп утырган, ә иртәгә учакка ташланасы үләнне Аллаһы шулай киендерә икән, сезне ничек киендермәсен ди инде, сай иманлылар?

**Зәбур 104**

1 Раббыга рәхмәтләр укыгыз, исемен яд итегез, эш-гамәлләрен халыкларга җиткерегез!

2 Җырлагыз Аңа, мәдхияләр җырлагыз, бөтен могҗизаларын сөйләп бирегез!

3 Мөкатдәс исеме белән Аның мактаныгыз! Раббыга йөз тотучыларның йөрәкләре куансын!

4 Раббыга, Аның кодрәтенә сыеныгыз, Аның нурлы йөзен һәрчак эзләгез!



болыт яшененең яктылыгы күзләрнең нурын бетерергә якын булыр.

44 Аллаһ көндезне вә кичне алмаштырып берсен берсе артыннан китерү белән, Аллаһуның бу эшендә гакыллы вә күзле кешеләргә гыйбрәтләр бар.

45 Аллаһ җир йөзендә булган барча җан иясен судан халык кылды, ул хайваннарның кайберләре корсагы өстендә йөрер вә кайберләре ике аяк өстендә йөрер, Аллаһ Үзе теләгән мәхлукларны халык кылыр, бит Аллаһуның һәрнәрсәгә көче җитә.

**78 сүрә**

6 Әллә җирне аларга торырга яраклы кылмадыммы?

7 Дәхи селкенмәсен өчен тауларны җиргә кадак кылмадыммы?

8 Дәхи сезне ирле-хатынлы итеп халык кылдык.

9 Дәхи йокыны тәннәрегезгә истирахәт кылдык.

10 Дәхи төнне сезгә пәрдә кылдык.

11 Дәхи көндезне тереклегегез өчен кәсеп кылырга якты кылдык.

12 Дәхи өстегездә җиде кат мәхкәм күкләрне бина кылдык.

13 Дәхи бик яктыртучы һәм җылы бирүче кояшны халык кылдык.

5 Ул кылган гаҗәеп гамәлләрне, могҗизаларны, авызыннан чыккан хөкемнәрне хәтерегездә саклагыз,
6 әй сезләр, Аның колы Ибраһим токымы, Ул сайлаган Ягъкуб угыллары!
7 Ул – Раббы, безнең Аллабыз; Үзенең хөкем карарларын Ул бөтен җир йөзенә чыгара.
8 Үзе төзегән килешүне Ул һәрчак истә тота, меңнәрчә буыннарга биргән сүзен онытмый.
9 Бу килешүне Ул Ибраһим белән төзегән, ант эчеп Исхак белән ныгыткан,
10 Ягъкуб өчен – Канун, Исраил өчен мәңгелек Килешү итеп куйган.
11 Раббы әйткән: «Кәнган җирен сезгә бирәм: хакыгызга тигән милкегез булыр», – дигән.
12 Ул заман алар бик аз санлы кавем, Кәнган җирендә килмешәкләр,
13 бер халыктан – икенче халыкка, бер патшалыктан икенче патшалыкка күчеп йөрүчеләр иде.
14 Әмма Раббы аларны кыерсытырга бирмәгән, патшаларны ачуланып кисәткән:
15 «Кагылмагыз Мин май сөрткән кешеләргә, пәйгамбәрләремә дә зарар салмагыз!» – дигән.
16 Берзаман Ул алар җиренә кытлык җибәрде, ризыктан һичнәрсә калдырмады.



14 Дәхи болытлардан бере артыннан бере коелучы яңгыр суын индердек.
15 Ул су белән төрле икмәк орлыкларын вә төрле үләннәрне,
16 агачларны, бер-беренә уралып үскән җимеш бакчаларын үстермәклегебез өчен.

**79 сүрә**

27 Халык кылуда сезнең яратылуыгыз читенрәкме, әллә күкне ярату читенрәкме? Ул күкне Аллаһ бина кылды.
28 Ул күкнең бөеклеген бик югары кылды, ул күкне һич кимчелексез төзеп тәмам итте.
29 Ул күкнең кичен караңгы кылды вә аның көндезен якты кылды.
30 Моның соңында Аллаһ торырга яраклы итеп җирне түшәде.
31 Җирнең суын һәм хайваннар утлый торган үләннәрне чыгарды.
32 Дәхи тауларны мәхкәм, сабит кылды.
33 Сезгә вә сезнең хайваннарыгызга файда өчен.

**80 сүрә**

24 Кеше карасын ашаган ризыгына.
25 Тәхкыйк, Без аңа суны чын коюь белән койдык.
26 Соңра җирне чын яру илә ярдык та
27 ул җирдә иген бөртекләрен үстердек.



КҮК БЕЛӘН ҖИРНЕ БАР ИТКӘН АЛЛАҺЫГА ДАН

17 Әмма Ул алардан алда Йосыфны юллады – аны коллыкка сатып җибәрде.
18-19 Аның әйткәннәре раска чыкканчы, Раббының сүзе аның хаклыгын раслаганчы, Йосыфның аякларын – богау, муенын тимер муенса кысып тора иде.
20 Мисыр патшасы, халыклар хөкемдары, боерып, богавын чиштерде, азат иттерде,
21 шуннан аны үз иленә хуҗа кылды, булган бар милкенә идарәче итеп куйды:
22 түрә-башлыкларына фәрман бирү, өлкәннәренә акыл өйрәтү хокукын тапшырды.
23 Исраил шулай Мисырга керде, Ягъкуб гаиләсе Хам илендә җирләште.
24 Раббы анда Үз халкын ишәйтте, дошманнарыннан аларны көчлерәк кылды.
25 Үзенең колларына – халкына карата мисырлыларда нәфрәт уятты, мисырлылар күңеленә мәкерле уйлар салды.
26 Шуннан Раббы Үзенең колы Мусаны, һәм сайлаган бәндәсе Һарунны юллады,
27 алар аша Хам җиренә Үзенең могҗиза вә галәмәтләрен күндерде:
28 Хам җиренә караңгы индереп, аны дөм караңгылыкка батырды, һәм мисырлылар Аның сүзенә каршы тора алмадылар.



28 Йөземне вә җыеп алган коры җимешләрне,
29 дәхи зәйтүн, хөрмә агачларын үстердек.
30 Дәхи күп агачлы бакчаларны,
31 дәхи төрле җимешләрне вә печәннәрне үстердек.

**43 сүрә**

9 Әгәр син алардан «җирне вә күкләрне кем халык кылды» дип сорасаң, әлбәттә, алар «барчасына Газиз вә Галим булучы Аллаһ халык кылды» дип җавап бирерләр.
10 Ий кяферләр, Ул – Аллаһ – сезнең өчен җирне яшәргә вә йөрергә яраклы итеп халык итте вә җир өстендә сезгә күп юллар кылды, шаять сәфәрләрегездә уңышларга ирешерсез.
11 Вә Ул – Аллаһ – күктән чамалап яңгыр индерәдер, шул яңгыр белән үлгән җирне тергезеп һәрнәрсәне үстерәдер, үләннәр чыккан кеби сез дә каберләрегездән чыгарсыз.
12 Вә Ул – Аллаһ – һәр нәрсәне парлы итеп халык кылды вә сезгә утырып йөрү өчен көймәләр вә дүрт аяклы хайваннар халык кылды.
13 Ул көймәләргә вә хайваннарга сәүдә әйберләрегезне салып, үзегез дә менеп утырмаклыгыз өчен сезгә тапшырылдылар, соңра менеп утырып тынычлангач, Раббыгызның

29 Агымсуларны кан дәрьясына әверелдерде, балыкларын һәлакәткә дучар итте.
30 Бөтен җир өсте, патша сарайларына кадәр, гөберле бакалар белән шыгрым тулды.
31 Раббы әмере белән һәр тарафта чебен белән черки өере очып йөрде.
32 Раббы яңгыр урынына боз яудырды, җир өстендә ялкынлы яшеннәрен яшьнәтте.
33 Йөзем бакчаларын, инҗир куакларын, андагы бар агачны кырып бетерде.
34 Раббының әмере белән кырларны саранча чирүе басып алды.
35 Алар андагы бар үлән-чирәмне, басудагы бар игенне ашап бетерде.

ЗӘБУР

нигъмәтен зекер итәсез вә әйтәсез: «Бу нәрсәләрдән безне файдаландыручы Аллаһ һәр кимчелектән пакьтер, бу нәрсәләрне булдырырга үзебез, әлбәттә, кадир булмас идек.
14 Соңра без каберләребездән кубарылып, әлбәттә, Раббыбызга кайтачакбыз».
15 Мөшрикләр: җир вә күкләрне Аллаһ халык кылды, дигәннәреннән соң, мәхлукларның бәгъзесен Аллаһуга шәрик итәрләр, андый кешеләр Аллаһуның күренеп торган нигъмәтләрен инкяр итеп имансыз калучылар.

**30 сүрә**

11 Аллаһ башлап кешеләрне юктан бар итәр, соңра, үлгәч тергезеп, әүвәлге хәлләренә кайтарыр, соңра хөкем ителер өчен Аллаһуга кайтарылырсыз.
17 Аллаһ һәр эшендә кимчелектән пакь, кичкә кергәндә вә таңга кергәндә намазлар укып Аллаһуны мактап тәсбихләр әйтегез!
19 Ул — Аллаһы — терекне үлектән чыгарыр, ягъни үлекне тергезер, дәхи үлекне теректән чыгарыр, ягъни терене үтерер вә җирне, кышын үлгәннән соң, язын яңгыр белән терелтер, сез дә әнә шулай терелеп каберләрегездән чыгарылмыш булырсыз.

КОРЪӘН





20 Дәхи Аллаһының кодрәтенә дәләләт иткән нәрсәләрдән берсе — асылыгыз Адәм г-мне туфрактан халык итте, соңра сез кеше булып җир йөзенә таралдыгыз.
21 Дәхи Аллаһуның кодрәтенә дәлилләрдәндер сезнең өчен Аллаһуның үзегездән хатыннар яратмаклыгы, чөнки Һава Адәмнең кабыргасыннан халык ителде, ул хатыннар белән өлфәтләнеп бергә яшәвегез өчен, дәхи ир белән хатын арасында дуслык һәм мәрхәмәтлек кылды; Аллаһуның бу эшләрендә фикерли белгән кешеләр өчен гыйбрәт бардыр.
22 Җир вә күкләрнең төзелеше вә телләрегез, төсләрегез төрлечә булуы Аллаһуның галәмәтләреннәндер; әлбәттә, Аллаһуның бу эшләрендә белем ияләре өчен дәлилләр бардыр.
23 Дәхи Аллаһуның могҗизаларыннандыр кичләрен вә көндезләрен йоклап рәхәтләнүегез вә көндезләрен Аллаһуның фазылыннан дөнья ахирәтләрегезне кәсеп итүегез; әлбәттә, бу эшләрдә игътибар белән тыңлаучыларга Аллаһуның кодрәтенә дәлилләр бардыр.
24 Дәхи Аллаһуның могҗизасыннандыр сезгә яшенне күрсәтүе, яшеннән куркып,

КОРЪӘН

яңгырны өмет иткәнегез хәлдә, һәм күктән яңгыр индереп үлгән җирне тергезүе, Аллаһуның бу эшендә дә гакыллы кешеләргә дәлил бар.
25 Дәхи Аллаһуның могҗизасыннандыр җир вә күкнең терәүсез Аллаһуның кодрәте белән торулары; соңра Исрафил фәрештә «каберләрегездән чыгыгыз» дип бер мәртәбә әйтсә, шулвакыт һич кичекмичә чыгарсыз.

КОРЪӘН



## Беренче кешеләрнең гөнаһлануы

**Яратылыш 2**

25 Адәм дә, хатыны да шәп-шәрәләр, оялуның нәрсә икәнен белмиләр иде.

**Яратылыш 3**

1 Раббы Алла яраткан барлык кыр җанварларыннан иң мәкерлесе елан иде. Елан хатыннан: «Аллаһы чыннан да бакчадагы һичбер агачтан җимеш ашамагыз дидеме?» — дип сорады.
2 «Бакчадагы агачлардан җимеш ашарга безгә рөхсәт бар, — дип җаваплады хатын. —
3 Әмма Аллаһы әйтте, бакча уртасындагы агачның җимешләренә кагылмагыз, аларны ашамагыз, юкса үләрсез, диде».
4 Елан: «Юк, үлмисез, — диде. —
5 Чөнки Аллаһы белә: ул агачның җимешен ашаган көнне сезнең күзләрегез ачылачак, яхшылык белән яманлыкның ни икәнен белеп, Аллаһының Үзе кебек булачаксыз.
6 Хатын әлеге агачның карап торышка гүзәл, җимешенең ризык өчен хуш булуын күрде. Белем бирү хасиятенә ия булган агач хатынның нәфесен кузгатып, хатын агачтан җимеш өзеп алып ашады, иренә дә өзеп алып бирде — ул да ашады.

ТӘҮРАТ

## Беренче кешеләрнең гөнаһлануы

**7 сүрә**

19 Аллаһ әйтте: «Ий Адәм, үзең вә хатының Һава җәннәттә торыгыз вә теләгән урыннан ашагыз, әмма ошбу агачка якын бармагыз, әгәр якын барсагыз, залимнәрдән булырсыз».
20 Аларга шайтан вәсвәсә кылды аларның ябык гаурәтләрен ачмак өчен һәм әйтте: «Аллаһы сезнең фәрештә булуыгызны теләмәгәне яки җәннәттә мәңге калуыгызны теләмәгәне өчен сезне ошбу агачтан тыйды», — дип.
21 «Тәхкыйк, мин сезгә яхшылыкны телимен», — дип ант итте Иблис.
22 Алдап аларны агачка якын китерде. Алар агачтан ашадылар, гаурәтләре ачылды вә җәннәт яфраклары белән гаурәтләрен капларга ашыктылар; аларга Раббылары кычкырды: «Әллә Мин сезне ошбу агачтан тыймадыммы? Вә, тәхкыйк, шайтан сезгә ачык дошман, сакланыгыз, дип әйтмәдемме?» — дип.
23 Адәм вә Һава әйттеләр: «Ий Раббыбыз, үзебезгә золым кылдык, әгәр безне ярлыкамасаң һәм рәхмәт кылмасаң, әлбәттә, бәхетсезләрдән булачакбыз», — дип.

КОРЪӘН

7 Икесенең дә күзләре ачылды. Шәп-шәрә икәнлекләрен күрделәр. Инжир яфракларыннан үреп, үзләренә бил каплагычлары ясадылар.

8 Җиләс көн иде, алар бакчада йөргән Раббы Алланың тавышын ишеттеләр. Аңа күренмәс өчен, адәм һәм аның хатыны бакча агачлары арасына кереп постылар.

9 Раббы Алла адәмгә: «Син кайда?» — дип эндәште.

10 Адәм: «Бакчада тавышыңны ишеттем дә куркып калдым. Чөнки мин шәрәмен, шуңа яшерендем», — диде.

11 Раббы Алла: «Шәрә икәнеңне сиңа кем әйтте? — дип сорады. — Мин җимешен ашама дигән агачтан җимеш өзеп ашадыңмы әллә?»

12 Адәм: «Яныма Син куйган хатын, ул агачтан җимеш өзеп алып, миңа бирде, мин аны ашадым», — дип җаваплады.

13 Раббы Алла хатынга әйтте: «Моны син ничек эшли алдың?» Хатын әйтте: «Мине елан котыртты, шуңа ашадым», — диде.

14 Раббы Алла еланга болай диде: «Бу эшең өчен син җир йөзендәге барлык хайваннар, җәнлекләр каршында каһәр иеседер! Гомерең буе карының өстендә шуышып йөрерсең һәм туфрак ашап туенырсың.

24 Аллаһ әйтте: «Ий Адәм белән Иблис, бер-берегезгә дошман булганыгыз хәлдә Җиргә иңегез! Сезгә торачак урын һәм әҗәлегезгәчә файдаланачак җай Җирдә».

25 Аллаһ әйтте: «Җирдә тереклек итәрсез вә Җирдә үләрсез һәм Җирдән чыгарылырсыз».

26 Ий Адәм балалары! Без сезгә киемнәр яраттык, ул киемнәр гаурәтләрегезне каплар, янә мал яраттык һәм дә тәкъвалык киемен бирдек, ул тәкъвалык — саклану киеме хәерледер, ошбу зекер ителгән нәрсәләр Аллаһу Тәгаләнең галәмәтләре, шаять, кешеләр вәгазьләнерләр.

27 Ий Адәм балалары! Ата-анагызны җәннәттән чыгарган кеби, шайтан сезне фетнәгә салмасын, аларның киемнәрен салдырып гаурәтләрен үзләренә күрсәтер өчен (ул) аларны алдады. Тәхкыйк, шайтан һәм аның гаскәре сезне күрәләр, сез аларны күрмәгән урыннан; әлбәттә, шайтаннарны ышанмаучыларга дус кылдык.

**2 сүрә**

36 Иблис «бу агач җимешен ашасагыз, җәннәттә мәңге каласыз» дип аларны алдады, алар Иблис сүзенә ияреп җимешне ашап алдандылар. Иблис аларны җәннәттән чыгарып андагы нигъмәтләрдән

ТӘҮРАТ

КОРЪӘН





15 Синең белән хатын-кыз арасына, синең токымың белән аның нәселе арасына дошманлык җебе сузармын. Аның нәселе башыңны сугып ярыр, син исә аны үкчәсеннән чагарсың».

16 Хатынга исә Раббы Алла әйтте: «Сине чиктән тыш каты авыртуларга дучар итәчәкмен: баланы зур газаплар чигеп табачаксың. Күңелең иреңә тартылыр, ул исә синең өстеңнән хакимлек итәр», — диде.

17 Ә адәмгә Раббы Алла болай диде: «Менә синең аркада, хатыныңның сүзен тыңлап, Мин ашама дип кисәткән агачның җимешен ашаганың өчен, җир туфрагына Минем ләгънәтем төште. Гомерең буе тамагыңа ризыкны җәфа чигеп табарсың.

18 Туфрак сиңа тикән дә чүпүлән үстерер. Син кыргый үлән ашап туенырсың.

19 Яратылмыш туфрагыңа кире әйләнеп кайтканчыга кадәр, син ашар икмәгеңне маңгай тирен түгеп табарсың. Чөнки син үзең туфрак, туфрактан яратылдың һәм янә туфракка әверелерсең».

аерды. Моннан соң әйттек: «Ий Адәм һәм Иблис, бер-берегезгә дошман булганыгыз хәлдә җиргә иңегез! Сезгә җирдә торырлык урын һәм яшәү өчен кирәк нәрсәләр бар, әҗәлегез җиткәнче яшәгез».

37 Адәм гәләйһис-сәлам тәүбәгә ашыкты һәм Раббысы тарафыннан өйрәткән тәүбә-истигъфар сүзләренә юлыкты һәм тәүбә итеп Аллаһудан гафу сорады, Аллаһ, тәүбәсен кабул итеп, гөнаһын гафу итте. Аллаһ тәүбәләрне кабул итүче, рәхимле.

38 Без әйттек: «Барчагыз да җәннәттән чыгып җиргә иңегез! Әмма Минем сезгә туры юлга күндерүче сүзләр, әлбәттә, килер, Минем сүзләремә ияргән затка курку һәм кайгы булмас.

39 Имансызлар һәм аятьләребезне ялган диючеләр — ут әһелләредер, алар анда мәңге калырлар».

ТӘҮРАТ

КОРЪӘН

## Кабилнең үз кардәше Һабилне үтерүе

**Яратылыш 4**
2 Тагы да соңрак Кабилнең энесе
Һабилне тудырды. Һабил –
сарыклар көтүче, Кабил исә
игенче булды.
3 Берникадәр вакыт узгач, Кабил
җир җимешләре уңышыннан
Раббыга бүләк китерде.
4 Һабил дә үз көтүендә беренче
булып туган мал-туар үр-
чеменнән берничәсен һәм
куй мае алып килде. Раббы
Һабилне һәм аның бүләген
кабул итте,
5 Кабилне һәм аның бүләген исә
кире какты. Кабил бик нык
рәнҗеде, ачуыннан башын
түбән иде.
6 Раббы Кабилдән: «Нигә шу-
лай рәнҗисең? Ни өчен ба-
шыңны түбән идең? – дип
сорады. –
7 Яхшылык кылгач, башны тү-
бән ияргә димени?! Яхшы-
лык кылмыйсың икән, гөнаһ
ишек төбендә посып торыр,
сине сагалар. Ә син аңардан
өстен бул!»
8 Энесе Һабилгә Кабил: «Әй-
дә, кырга чыгабыз!» – диде.
Кырда чакта Кабил, энесе
Һабилгә һөҗүм итеп, аны
үтерде.
9 Раббы Кабилдән: «Энең Һабил
кайда?» – дип сорады. Кабил:
«Белмимен, энемнең җан
сакчысы түгел ич мин!» –
дип җавап бирде.
10 Раббы: «Син ни кылдың? –
диде. – Туфрактан кардә-
шеңнең кан ыңгырашуы
Миңа ишетелеп тора.
11 Инде син кардәшеңнең түк-
кән канын эчәргә авызын
ачкан туфракның каргышын
алдың.
12 Эшкәртә торган туфрагың
моннан соң сиңа көч-куәтен
бирмәс; җир йөзендә син го-
мерең буе сөрелеп һәм качак
булып яшәрсең.
13 Кабил Раббыга: «Җәзам кө-
чем җитмәс дәрәҗәдә авыр
җәзадыр, – диде. –
14 Бүген мине туган җиремнән
сөрәсең. Синең хозурыңнан
югалып, мин горбәттә ка-
чак булып яшәргә мәҗбүр.
Юлымда очраган теләсә кем
мине үтерә алачак.
15 Раббы әйтте: «Кем дә кем Ка-
билне үтерсә, аңардан жиде-
ләтә артык үч алыныр», –
диде. Шулай дип, Кабилне
беркем дә күреп үтермәсен
өчен, Раббы аны кисәтүле
галәмәт белән тамгалады.
16 Кабил, Раббысы хозурыннан
аерылып, Гадән бакчасының
көн чыгышы тарафындагы
Нод төбәгенә барып җир-
ләште.



## Кабилнең үз кардәше Һабилне үтерүе

**5 сүрә**
27 Ий Мөхәммәт г-м! Адәм
г-мнең угыллары хакында-
гы хәбәрне хаклык белән
укыгыл... Ике егет корбан
чалдылар, берсенеке, ягъ-
ни Һабилнеке, кабул булды,
икенчесе – Кабилнеке кабул
булмады. Кабилнең көнче-
леге артты һәм әйтте: «Ий
Һабил, мин сине, әлбәттә,
үтерәчәкмен», – дип. Һабил
әйтте: «Әлбәттә, Аллаһу Тә-
галә тәкъва кешеләрнекен
кабул итәдер», – дип.
28 Һабил Кабилгә әйтте: «Син
мине үтерергә кулыңны суза
торган булсаң да, мин сине
үтерергә кулымны сузачак
түгелмен. Мин бөтен галәм-
нәрне тәрбия итүче Аллаһ
газабыннан куркамын.
29 Әгәр мине үтерсәң, мин те-
лимен минем гөнаһымны
һәм үз гөнаһыңны йөкләп
Аллаһуга кайтуыңны, бу
золым эшеңне эшләсәң, ут
әһеленнән булырсың. Ут га-
забы – залимнәргә тиешле
җәзадыр», – дип.
30 Нәфесе аңа галиб булды, ягъ-
ни нәфесе Кабилне җиң-
де, Һабилне үтерергә аны
өстерәде, Кабил Һабилне
үтерде вә хәсрәтләнүчеләр-
дән булды.
31 Аллаһ Кабил янына бер карга
җибәрде, ул карга Кабил-
гә җирне казып күрсәтте,
ягъни Һабилнең гәүдәсен
күмәргә өйрәтте. Карганы
күргәч, Кабил әйтте: «Һай
миңа үкенеч! Каргадан да
көчсезрәк идем мәллә? Карга
белгәнне дә белмәдем, әгәр
белгән булсам, кардәшемнең
гәүдәсен ничә көннәр кү-
тәреп йөрмичә, үтерү белән
күмгән булыр идем», – дип.
Бу эшеннән соң үкенүчеләр-
дән булды.
32 Кешеләр бер-берсен үтергән-
нәре өчен бәни Исраилгә
хөкем иттек: «Әгәр берәү
кеше үтермәгән кешене яки
җир өстендә бозыклык кыл-
маган кешене үтерсә, бөтен
кешеләрне үтергән кеби бу-
лыр, бер кешене үлемнән
коткарса, бөтен кешеләрне
үлемнән коткарган кеби бу-
лыр», – дип.
36 Кяферләрнең кулында бөтен
дөнья байлыгы янә шуның
чаклы байлык була калса,
Аллаһ газабыннан котылу
өчен шул байлыкны бирсә-
ләр, кабул булмас иде. Алар-
гадыр рәнҗетүче газап.

## Нух һәм туфан сулары

**Яратылыш 6**
5 Раббы күрде ки, җир йөзен-
дә адәм баласын азгынлык
баскан, кешенең бөтен кү-
ңеле, уй-фикере һәрвакыт
явызлыкта.
6 Раббы кешене бар итүенә үкен-
де, бөтен йөрәге белән сыз-
ланды.
7 Әйтте: «Дөньяга Үзем ярат-
кан кешеләрне, хайваннар-
ны, сөйрәлүче хәшәрәтләр-
не, күктәге кошларны —
һәммәсен җир йөзеннән
юк итәм, чөнки аларны
яратуыма Мин үкенәм», —
диде.
8 Раббы күңеленә фәкать Нух
кына хуш килде.
9 Нухның яшәү рәвеше болай-
дыр: ул тугры, замандаш-
лары арасында саф, Алла-
һы юлында йөрүче кеше
иде.
10 Аның өч углы булды: Шем,
Хам вә Яфет.
11 Әмма Аллаһы хозурында җир
йөзе бозылган, явызлыкка
кереп баткан иде.
12 Аллаһы җир йөзен күзеннән
кичерде һәм һәр нәрсәнең
тәмам бозылганын күрде,
чөнки адәм балалары туры
юлдан читкә тайпылганнар
иде.
13 Аллаһы Нухка әйтте: «Бө-
тен кешелек дөньясын юк



## Нух һәм туфан сулары

**71 сүрә**
1 Тәхкыйк, Без Нухны кавеменә
пәйгамбәр итеп җибәрдек
«кавемеңне куркыт Аллаһу-
ның рәнҗетүче каты газабы
килмәс борын» дип.
2 Нух әйтте: «Ий кавемем, тәх-
кыйк, мин сезгә җибәрелгән
Аллаһ газабы илә ачык кур-
кытучы пәйгамбәрмен.
3 Аллаһуга гына гыйбадәт кы-
лыгыз вә Аллаһудан куркы-
гыз, гөнаһлардан сакланыгыз
һәм дә миңа итагать итегез,
дип боерамын.
4 Әгәр минем боерыкны кабул
итеп тәүбә итсәгез, Аллаһ
гөнаһларыгызны ярлыкар
һәм сезне яшәтер билге-
ләнгән әҗәлегезгә чаклы.
Тәхкыйк, Аллаһ билгеләә-
гән әҗәл әгәр килсә, һич
кичектерелмәс. Әгәр шуны
белсәгез!»
5 Нух әйтте: «Ий Раббым, ка-
вемемне ислам диненә кич-
ләрдә дә вә көндезләрдә дә
чакырдым.
6 Минем чакыруым аларга арт-
тырмады, мәгәр хактан, ис-
лам диненнән качуны гына
арттырды.
7 Ий Раббым, һәркайчан мин
аларны Синең ярлыкавыңа,
гафу итүеңә чакырсам, ми-
нем сүземне ишетмәс өчен
бармакларын колакларына







итәчәкмен! — диде. — Чөнки
кешеләр аркасында җир йөзе
явызлык белән тулды.
14 Гофәр агачыннан үзеңә көймә
ясa. Эчен-тышын сумалала,
көймәнең эчендә бүлмәләр
ясa. <...>
16 Көймәнең өске өлешендә бер
терсәк киңлегендә ачыклык
калдыр, ян ягыннан ишек
куй. Эчен аскы, урта, өске
катлы итеп ясa.
17 Шуннан соң Мин җир йөзен
туфан суына батырачакмын,
күк астындагы барлык җан
ияләрен юк итәчәкмен. Җир
йөзендә бернинди тереклек
калмаячак.
18 Әмма Мин синең белән ки-
лешү төзим. Угылларың, ха-
тының, киленнәрең белән
берлектә көймәгә кер.
19 Исән калсыннар өчен, һәрбер
токым җан иясеннән ата һәм
ана җенесле берәр парны үзең
белән көймәгә ал.
20 Төрле токымдагы кошлар,
хайваннар, җирдә сөйрә-
лүчеләр — һәр төрдән ике-
шәр-икешәр булып — исән
калу өчен, синең янга ки-
лерләр.
21 Син исә, үзең һәм башкалар
тукланыр өчен, төрлесеннән
кирәк кадәр азык ал, аны
яныңа тупла».
22 Нух Аллаһының барлык бое-
рыкларын җиренә җиткереп
үтәде.



тыктылар һәм киемнәренә
бөркәнделәр вә көферлек-
тә дәвам иттеләр һәм каты
тәкәбберләнү илә тәкәббер-
ләнделәр.
8 Моннан соң мин аларны бик
каты кычкырып чакырдым.
9 Соңра исламга чакыруымны
ачык игълан кылдым вә яше-
рен генә аулакта да өндәп
карадым.
10 Һәм әйттем аларга: «Тәүбә
итеп Раббыгыздан истигъ-
фар кылыгыз, гафу сорагыз,
шиксез, Ул — гөнаһларны
ярлыкаучы.
11 Вә сезгә күктән яңгырны коеп
яудырыр.
12 Вә сезгә мал белән ярдәм итәр
һәм балалар биреп куәтләр,
дәхи җимеш үстерә торган
бакчалар һәм елгалар би-
рер»...
13 «Ни булды сезгә, Аллаһуны
олугъ дип белмисез вә Аның
газабыннан курыкмыйсыз.
14 Тәхкыйк, Ул сезне халык (бар)
кылды, бер хәлдән икенче
хәлгә күчереп...
15 Әллә күрмисезме ничек халык
кылган Аллаһ кат-кат итеп
җиде күкне,
16 вә ул күкләрдә айны якты
итеп, вә кояшны яктылык
һәм җылылык бирүче ут
итеп.
17 Аллаһ сезне җирдән үстерде,
ягъни Адәм җирдән халык
итедe.

**Яратылыш 7**
1 Раббы Нухка: «Бөтен гаиләң
белән берлектә көймәгә
кер, – диде. – Чөнки бу бу-
ын кешеләре арасында син
Минем хозурымда тугры
булдың.
2-3 Җир йөзендә токымнары
сакланып калсын өчен,
чиста хайваннардан ата
һәм ана җенесле җиде пар-
ны, чиста булмаганнардан
шулай ук ата һәм ана җе-
несле берәр пар, кошлар-
дан исә җиде парны үз
яныңа ал.
4 Чөнки җиде көннән соң Мин
җир йөзенә кырык көн һәм
кырык төн буе тоташтан яң-
гыр яудырачакмын – Үзем
яраткан бар нәрсәне җир йө-
зеннән юк итәчәкмен».
5 Раббының барлык боерыкла-
рын Нух җиренә җиткереп
үтәде.
6 Җир йөзен туфан каплый баш-
лаган чакта, Нухка алты йөз
яшь иде.
7 Туфаннан котылып калу өчен,
Нух үзе, аның белән бергә
хатыны, угыллары, килен-
нәре көймәгә керделәр. <...>
10 Җиде көннән соң туфан
купты.
11 Нух гомеренең алты йөзенче
елында, икенче айда, айның
унҗиденче көнендә, нәкъ
шул көнне, күк капулары
ачылып, төпсез упкыннар



18 Соңра сезне шул җиргә кайта-
рыр вә сезне тергезеп җирдән
чыгарыр.
19 Аллаһ сезнең өчен җирне па-
лас кебек йомшак вә киң
кылды.
20 Ул җирнең олугъ вә киң юлла-
рында йөрмәклегегез өчен».
Нух г-мнең бу сүзләрен дә
кавеме инкяр иткәч, Аллаһу-
га ялварды һәм дога кылды.
21 Нух әйтте: «Ий Раббым, тәх-
кыйк, алар гасый вә дошман
булдылар һәм аларга малы
да, вә балалары да ярдәм
бирмәячәк, һич файданы
арттырмаячак залим кеше-
гә, ягъни үзләренең кяфер
хуҗаларына иярделәр, ул за-
лимнең малы вә балалары
хәсрәтне вә газапны гына
арттырыр.
22 Вә хәйлә-мәкер кылдылар,
олугъ булган мәкерне.
23 Вә олугълары әйттеләр: «Әл-
бәттә, сынымнарыгызга гыйб-
бадәт кылуны ташламагыз,
әлбәттә Вәд, Сүвагъ, Йәгус,
Йәгук, Нәсер исемле сыным-
нарыгызны ташламагыз», –
дип...
24 Ий Раббым, тәхкыйк, алар
күпләрне хак юлдан адаш-
тырдылар, бу залимнәргә
арттырма һичнәрсәне, мә-
гәр адашуны гына арттыр».
25 Алар зур хаталары сәбәпле
туфан суларына батырыл-
дылар вә утка кертелделәр,







эченнән җир йөзенә томалап
яңгыр коя башлады.
12 Ул кырык көн һәм кырык төн
тоташтан яуды.
13 Яңгыр башланган көнне Нух,
угыллары Шем, Хам, Яфет,
Нухның хатыны һәм өч ки-
лене көймәгә кереп урнаш-
тылар. <...>
16 Аллаһы кушканча, һәр пар-
ның берсе ата җенесендә,
икенчесе ана җенесендә иде.
Раббы көймәгә кергәннәр
артыннан ишекне япты.
17 Су күтәрелү кырык көн дәвам
итте. Сулар, тәмам ташып,
көймәне җир өстеннән юга-
ры күтәрде.
18 Су ташкыны артканнан арта
барды, бөтен җирне капла-
ды, көймә су өстеннән йөзеп
китте.
19 Шулкадәр артты ки, күк ас-
тындагы барлык биек-биек
таулар су астында калды.
20 Су, тауларны ташкын астын-
да калдырып, алар өстеннән
унбиш терсәк югары күтә-
релгән иде. <...>
23 Адәм баласыннан башлап
хайваннарга кадәр, сөйрә-
лүче хәшәрәтләрдән алып
очар кошларга кадәр бар-
лык җан ияләре үлемгә ду-
чар булды; җир йөзендәге
бар нәрсә юкка чыкты. Фә-
кать Нух һәм аның белән
бергә көймәдә булганнар
гына исән калды.



26 алар Аллаһ газабыннан ко-
тылырга үзләренә ярдәмче
тапмадылар.
26 Нух әйтте: «Ий Раббым, җир
өстендә һич калдырма, кя-
ферләрне һәммәсен һәлак ит!
27 Әгәр Син аларны җир өстендә
тере калдырсаң, алар Синең
бәндәләреңне адаштырыр-
лар һәм алар яхшы бала ту-
дырмаслар, мәгәр явызны вә
хакны инкяр итүчене генә
тудырырлар.
28 Ий Раббым, мине ярлыкагыл
вә мөэмин булган ата-анам-
ны ярлыкагыл һәм минем
өемә яки көймәмә мөэмин
булып кергән кешене ярлыка
һәм дә барча мөэмин ирләр-
не вә мөэминә хатыннарны
ярлыка! Залим кяферләргә
арттырма һичнәрсәне, мә-
гәр һәлак булуларын гына
арттыр!»
**11 сүрә**
25 Тәхкыйк, без Нухны үз ка-
веменә пәйгамбәр итеп җи-
бәрдек: әлбәттә, мин сезне
Аллаһ газабы белән ачык
куркытучымын.
26 «Башка һичкемгә түгел, фә-
кать Аллаһуга гына гыйбадәт
кылыгыз», – дип хәбәр бирә-
мен, тәхкыйк, мин куркамын
сезгә каты газаплы көннең
килүеннән.
27 Кавемнең кяфер булган олугъ-
лары әйтте: «Ий Нух, син
безнең кеби адәмсең, бездән

24 Су күтәрелү тагын йөз илле көн дәвам итте.

**Яратылыш 8**

1 Ахырда Аллаһы, Нухны һәм аның белән бергә көймәдә булган барлык хайваннарны исенә төшереп, җир өстенә җил истерде. Суның артуы бетте.

2 Күк капулары ябылып, төпсез упкыннар эченнән коеп яуган яңгыр туктады.

3 Йөз дә илле көн кичкәннән соң, җир өстендәге сулар кими башлады.

4 Җиденче айның унҗиденче көнендә көймә Арарат таулары түбәсенә утырды.

5 Суның кимүе унынчы айга кадәр дәвам итте. Унынчы айның беренче көнендә тау башлары күренде.

6 Кырык көн үткәч, Нух үзе ясаган көймәнең тәрәзәсен ачты.

7 Тәрәзәдән бер козгынны тышка очырды. Козгын, җир өсте сулардан арынганга кадәр, бер очып китеп, бер очып кайтып йөрде.

8 Җир өстеннән су китеп беткәнме-юкмы икәнен белер өчен, Нух күгәрченне очырды.

9 Күгәрчен, аякларына кунар җир тапмыйча, Нух янына көймәгә кире әйләнеп кайтты; чөнки җир өстеннән су китеп бетмәгән иде әле. Нух,

ТӘҮРАТ

артык җирең юк, дәхи сиңа ияргән кешеләр дә арабызда иң түбән кешеләрдер һәм безгә караганда сездә дә бернинди артыклык күрмибез, бәлки без сезне ялганчылар дип уйлыйбыз».

28 Нух әйтте: «Ий кавемем, беләсезме, әгәр сөйләгән сүзләремнең хаклыгына Аллаһудан куәтле дәлилләрем булса, янә Аллаһ сезгә бирмәгән нигъмәт вә рәхмәтне миңа бирсә, инде сез хак динне мәкрүһ күрә торып, мин аны сезгә көчләп кабул иттерергә кадир булырмынмы?

29 Ий кавемем, хак динне өйрәткәнем өчен мин сездән мал сорамыйм, сезгә исламны өйрәтүемнең әҗерен фәкать Аллаһу Тәгалә үзе бирәчәк, дәхи мин, иман китереп, миңа ияргән кешеләрне ташлаучы түгелмен, ул мөэминнәр Раббыларына юлыгачакларын, әлбәттә, беләләр, ләкин мин сезне бик надан кавемнәр дип күрәмен ки, хак динне дә, Аллаһуга кайтачагыгызны да белмисез.

30 Ий кавемем, әгәр мин фәкыйрьләрне янымнан кусам, ярдәм биреп Аллаһ газабыннан мине кем коткарыр, шуны уйлап вәгазьләнмисезме?

31 Мин сезгә әйтмимен „минем кулымда Аллаһ хәзинәләре

КОРЪӘН



НУХ ҺӘМ ТУФАН СУЛАРЫ

куллары белән тәрәзәдән сузылып, күгәрченне көймә эченә, үз янына алды.

10 Нух тагын җиде көн узганны көтеп торды да күгәрченне янә тышка очырды.

11 Кичен күгәрчен, томшыгына яшь зәйтүн яфрагы эләктереп, кире кайтты. Шуңардан Нух җир өстендәге суларның кимегәнлеген белде.

12 Җиде көн үткәннән соң, Нух күгәрченне тагын очырды. Бу юлы күгәрчен кире әйләнеп кайтмады. <...>

15-16 Аллаһы Нухка: «Хатының,
угылларың һәм киленнәрең
белән бергә көймәдән чык, —
диде. — 17 Синең белән бергә
янындагы барлык төр җан
ияләре: кошлар, хайваннар,
җир өстендә сөйрәлүче хәшәрәтләр — һәммәсе көймәдән чыксыннар; чыгып, җир йөзенә таралсыннар, үрчеп, ишәеп, җир өстен тутырсыннар».

18 Нух үзенең хатыны, угыллары һәм киленнәре белән бергә көймәдән чыкты.

19 Җир йөзендә хәрәкәт итүче төрле токымдагы барлык җан ияләре — хайваннар, кошлар, хәшәрәтләр көймәне ташлап чыктылар.

20 Раббы хөрмәтенә Нух бер мәзбәх корды һәм, чиста саналган хайван һәм кошлар арасыннан берничәсен

ТӘҮРАТ

бар вә яшертен эшләрне беләмен һәм мин фәрештәмен“ дип. Һәм „сезнең күзегезгә яман күренгән фәкыйрьләргә Аллаһ рәхмәт кылмас, нигъмәт бирмәс“ дип тә әйтмим, аларның күңелләрендәге иманны вә мәгърифәтне Аллаһ белә, әгәр мин фәкыйрьләрне кимсетсәм, әлбәттә, залимнәрдән булырмын».

32 Кяферләр әйттеләр: «Ий Нух, тәхдыйк, син безнең белән бәхәсләштең һәм безнең белән бәхәсләшүеңне бик күп кылдың, әгәр дөрес сөйләүчеләрдән булсаң, вәгъдә кылган газабыңны өстебезгә китер».

33 Нух әйтте: «Ул газапны әгәр теләсә, фәкать Аллаһ үзе китерер, газап килгәндә сез Аллаһуны гаҗиз кыла алмассыз».

34 Әгәр мин сезне вәгазь кылырга теләсәм дә, минем вәгазем сезгә һич файда бирми, әгәр Аллаһ сезне аздырырга теләсә — аздырыр. Ул сезнең Раббыгыз, ни теләсә — шуны эшләр, вә ахырда Аңа кайтарылырсыз».

35 Яки алар бу сүзләрне Мөхәммәт Аллаһуга ифтира кылып ялган сөйли диләрме? Ә син аларга әйт: «Әгәр ифтира кылып ялган сөйләсәм, бит гөнаһы да үземә булыр, ләкин

КОРЪӘН

сайлап алып, ут өстендә ян-
дырып корбан китерде. 21 Хуш
истән күңеле булган Раббы
үзалдына әйтте: «Кешеләр
аркасында җир йөзен бүтән
нәгълэтләмәячәкмен, – ди-
де. – Чөнки кешенең йөрә-
гендә туа торган явызлыклар
аның балачагыннан ук ки-
лә; инде терек дөньяны, бу
юлы эшләгәнем кебек, кабат
үлемгә дучар итмәячәкмен.
22 Дөньяның киләчәк яшәе-
шендә чәчү дә, уру да булыр,
суык та, эссе дә булыр, җәй
дә, кыш та булыр, көн дә,
төн дә булып торыр».

**Яратылыш 9**

1 Аллаһы Нухны һәм аның
угылларын мөбарәк кылып
әйтте: «Үрчегез, ишәегез, җир
йөзен тутырыгыз! – диде. –
2 Җирдәге хайваннар, күктәге
кошлар, җир өстендә сөй-
рәлүче барлык хәшәрәтләр,
диңгездәге балыклар – һәм-
мәсе сездән куркып-калты-
рап торсыннар. Барысын да
сезнең хөкемгә тапшырам.
3 Җирдә хәрәкәт иткән һәрбер
җанлы нәрсә, яшел чирәм
кебек үк, сезнең өчен ризык
булыр; аларның һәммәсен
сезгә бирәм.
4 Әмма канлы итне, ягъни җаны
бар итне ашамагыз!
5 Сезнең җаныгыз яшерелгән үз
каныгыз түгелсә дә, гаеплене
Мин җавапка тартачакмын.



мин сез эшли торган гөнаһлы
эшләрдән бизүчемен».
36 Дәхи Нухка вәхи булды: «Си-
нең кавемеңнән иман ките-
рәселәр иман китерделәр,
инде калганнары иман ки-
термәсләр, аларның кылган
кабахәт эшләре өчен кай-
гырмагыл!
37 Вә көймә яса, Безнең күз ал-
дыбызда һәм Безнең өйрәтү-
ебез белән, ләкин мөселман
булмаган кешеләр өчен Безгә
дога кылмагыл „аларны га-
заптан коткар“ дип, чөнки
ул залимнәр туфан суына
батып һәлак булачаклар».
38 Нух көймә ясый башлады,
һәркайчан олугълары Нух
янынннан үтеп китсәләр,
«пәйгамбәр балтачы булган»
дип төрлечә көлеп, мәсхәрә
кылып үтәләр иде. Нух әйт-
те: «Бүген сез безне мәсхәрә
кылсагыз, иртәгә без сезне
мәсхәрә кылырбыз, сез мәс-
хәрә кылган кеби.
39 Кемгә рисвай кылучы газап
килгәнен тиздән белерсез
һәм кемгә мәңгелек газап
булачагын белерсез!»
40 Безнең газап белән әмере-
без килеп, хәтта җирдән су
кайнап чыга башлагач, әйт-
тек: «Ий Нух, һәр хайваннан
ирле-хатынлы итеп берәр
пар һәм иман китергән ке-
шеләрне вә өй җәмәгатеңне
көймәгә алып кер, мәгәр алар





Һәр хайваннан хисап ала-
чакмын. Кешенең җанына
кул сузган һәр бәндәдән үч
алачакмын.
6 Кеше канын койган адәмнең
үз каны да кеше кулыннан
коелыр. Чөнки кешене Ал-
лаһы Үз сурәтендә яратты.



хакында Аллаһудан „алар
кяферлек кылдылар“ дигән
сүз булган бер хатынның илә
бер угълың көймәгә кермәс-
ләр». Әмма Нухка бик аз ке-
шеләр иман китерделәр.
41 Нух әйтте: «Көймәгә бисмил-
лаһ әйтеп керегез, бу көй-
мәнең йөреше һәм туктавы
Аллаһ теләге белән булыр,
дип әйтегез! Тәхкыйк, ми-
нем Раббым мөэминнәрне
ярлыкаучы вә рәхмәт итүче».
42 Ул көймә аларны күтәреп
таулар кеби зур дулкыннар
эчендә йөрер. Көймәгә кер-
мичә бер читтә торучы угъ-
лын чакырды: «Ий угълым,
безнең белән көймәгә кер,
кяферләрдән булмагыл».
43 Угълы әйтте: «Бу судан тау ба-
шына чыгып котылырмын».
Нух әйтте: «Бүген Аллаһ
газабыннан коткаручы юк,
сине тау да коткара алмас,
мәгәр Аллаһ рәхмәт кыл-
ган кешеләр генә көймәгә
менеп котылырлар», – дип.
Соңра араларына дулкын
төшеп аларны аерды вә ка-
рышкан угълы суга батып
һәлак булды.
44 Вә Аллаһ тарафыннан әйтел-
де: «Ий җир, суыңны кип-
тер вә күк, суыңны туктат-
гыл», – дип. Су кимеде, һәлак
буласы кешеләр тәмам һәлак
булып бетте вә көймә Җудий
тавына барып туктады, вә

әйтелде: «Залим кешеләргә Аллаһуның рәхмәтеннән ераклыктыр», – дип.
45 Нух нида кылып әйтте: «Ий Раббым, угълым минем җәмәгатемнән, „җәмәгатеңне коткарырмын“ дигән хак вәгъдәң бар вә Син хәкимнәрнең дә хәкимерәгесең».
46 Аллаһу Тәгалә әйтте: «Ий Нух, угълың синең җәмәгатеңнән түгел, тәхкыйк, угълыңны миннән соравың, ягъни аңа дога кылуың яхшы эш түгел, белмичә, дәлилсез миннән сорамагыл, әлбәттә, мин сине наданнардан булмаска өндимен».
47 Нух әйтте: «Ий Раббым, сиңа сыгынамын, мине саклагыл үзем белмәгән нәрсәне Синнән сораудан, әгәр Син мине ярлыкамасаң һәм рәхмәт кылмасаң, әлбәттә, мин һәлак булучылардан булырмын».
48 Әйтелде: «Ий Нух, Безнең тарафтан имин булып көймәдән төш вә сиңа һәм синең белән булган мөэминнәргә күп бәрәкәт булган хәлдә көймәдән төшегез, дәхи сезнең нәселдән булган бер өммәтне дөньяда файдаландырырбыз, соңрак, азганнары өчен, аларга Бездән рәнҗетүче газап ирешер».

**36 сүрә**

41 Янә Без адәм балаларын һәм аларның төрле әйберләрен







диңгезләрдә йөри торган корабларга йөкләдек, ягъни шулай тәкъдир кылдык.
42 Янә Без кешеләр утырып йөрсеннәр өчен корабка охшаган нәрсәләрне, суда, һавада һәм корыда йөри торган күп нәрсәләрне халык кылдык, ягъни тәкъдир кылдык.
43 Әгәр без кешеләрне суга батырырга теләсәк, әлбәттә, батырырбыз, аларны коткарырга ярдәмче табылмас һәм батып һәлак булудан коткарылмаслар.
44 Мәгәр Аллаһудан рәхмәт йөзеннән суга батырылмаслар, Аллаһ билгеләгән гомерләре беткәнче яшәсеннәр өчен.

**33 сүрә**

7 Без пәйгамбәрләрдән «өммәтләрегезгә шәригать хөкемнәрене ирештерегез»... дип гаһед алдык, шулай ук синнән, Нух, Ибраһим, Муса вә Мәрьям угълы Гайсәдән гаһед алдык, вә Без ул пәйгамбәрләрдән йөкләтелгән бурычларыгызны үтәүләре өчен каты антларын алдык.

**66 сүрә**

10 Аллаһ мисал итеп зекер итте хакны инкяр итүче кяферләргә Нух пәйгамбәрнең хатынын вә Лут пәйгамбәрнең хатынын. Бу ике хатын Безнең изге колларыбызның кул астында иделәр, бу ике хатын үзләренең ирләре

булган пәйгамбәрләргә хыянәт иттеләр, ирләренә зарар китерергә теләделәр. Бу ике хатыннан ирләре булган бу ике пәйгамбәр Аллаһ газабыннан һичнәрсәне җибәрә алмадылар, ягъни пәйгамбәр булсалар да, хыянәтче хатыннарын Аллаһ газабыннан коткара алмадылар. Вә аларга «утка керүчеләр белән бергә утка керегез» дип әйтелде.

**6 сүрә**

6 Әллә күрмиләрме? Алардан элек күпме кяферләрне һәлак кылдык...

КОРЪӘН



## Бабил манарасы

**Яратылыш 11**

1 Башлангычта бөтен кешеләр бер телдә, бер шивәдә сөйләшәләр иде.

2 Алар, көнчыгыштан хәрәкәт итеп, Шинар үзәнлегендә үзләренә урын табып, шунда җирләштеләр. 3 Бер-берләренә: «Әйдәгез, кирпеч сугып, утта яндырыйк! — диделәр. Таш урынына — кирпеч, известь урынына җир сумаласы куллана башладылар.

4 Соңра әйттеләр: «Җир йөзе буйлап сибелеп бетмик һәм исемебезне данга күмик дисәк, үзебезгә бер шәһәр төзеп, башы күкләргә тиярдәй биек манара торгызыйк!» — диделәр.

5 Раббы, адәм балалары төзи башлаган шәһәрне һәм манараны күрү өчен, күктән инде

6 һәм болай диде: «Менә, болар барысы да бер телдә сөйләшүчеләр, бер кавем кешеләре, әнә нәрсә эшли башлаганнар. Инде болар уйлаган эшләреннән кире кайтмаячак.

7 Шуңа күрә, түбән иңеп, телләрен буташтырыйк, сөйләшкәндә, берсе-берсен аңламас булсыннар».

8 Шулай дип, Раббы адәм балаларын җир йөзе буйлап

ТӘУРАТ

## Бабил манарасы

**40 сүрә**

36 Фиргавен үзенең вәзирләренә әйтте: «Ий Һәман, миңа бик биек манара яса, шаять, мин ул манара белән күкнең юлына вә ишекләренә ирешермен.

37 Һәм анда Мусаның Аллаһысына юлыгырмын, чөнки Мусаның „Аллаһ бер генә“ дигән сүзе ялган дип уйлыйм», — дип. Фиргавеннең явыз эшләре дә, явыз сүзләре дә зиннәтле күренде, кешеләрне хак туры юлдан тыйды. Фиргавеннең хәйлә-мәкере үзенә хәсрәттән вә һәлакәттән башка нәрсә булмады.

**28 сүрә**

38 Фиргавен әйтте: «Ий җәмәгать, сезнең өчен миннән башка илаһ бар дип белмимен, ий Һәман, кирпеч яндырып минем өчен бер биек манара төзе, шаять, мин югары менеп Мусаның Аллаһусын күрермен вә хәлен белермен, тәхкыйк, миннән башка Аллаһ бар дип әйтүеңдә мин Мусаны ялганчылардан дип уйлыйм», — дип.

**26 сүрә**

128 Әллә сез, мөшрикләр, һәр калку урынга тәкәбберләнеп файдасыз биналар төзисезме башкаларны кимсетер өчен.

КОРЪӘН

чәчте, алар бу шәһәрне тө-
зүдән туктадылар.
9 Шунлыктан шәһәр Бабил дип
аталды. Чөнки Раббы адәм
балаларының сөйләмә телен
шунда буташтырды, аларны
шуннан торып җир йөзе буй-
лап чәчте.



129 Янә дөньяда мәңге яшәү өме-
те белән төрле биек биналар
ясыйсызмы?
**46 сүрә**
24 Алар үзләренә газап алып ки-
лә торган болытны күргәч,
бу болыт безгә яңгыр алып
килә, диделәр. Һуд әйтте:
«Бәлки ул сез ашыктырып
сораган газабыгыздыр ки,
анда рәнҗетүче каты газап
бардыр.
25 Ул җил Аллаһуның әмере
белән һәрнәрсәне һәлак
итәр», – дип. Ул җил килеп
һәммәләрен вә һәрнәрсәне
һәлак итте, бу җилдән соң
карасаң, өйләреннән баш-
ка нәрсә күренмәс иде. Без
ышанмаган явызларга әнә
шулай җәза бирәбез.
**7 сүрә**
137 ...Фиргавен үзе вә кавеме тө-
зегән биналарны һәм күтә-
реп ясаган бакчаларын һәлак
иттек.
**10 сүрә**
19 Пәйгамбәр килгәнче дөнья-
дагы кешеләр бер генә төрле
иде, ягъни бар да мөшрик
иделәр, Мөхәммәт г-м кил-
гәч, берсе мөэмин, берсе
мөшрик – икегә бүленделәр.
Залимнәрне газап кылуда га-
запны кичектерү белән Раб-
бының вәгъдәсе булмаса
иде, Коръән хөкемнәрендә
ихтыйлаф кылышкан кеше-
ләрне Аллаһ һәлак итәр иде.



## Ибрам – Ибраһим

***Ибрамның ата-бабалар җирен ташлап китүе***

**Яратылыш 11**
27 Терахның нәсел шәҗәрәсе:
Терах – Ибрамның, Нахор-
ның һәм Һаранның атасы
иде. Һаранның Лут исемле
бер углы булды.
28 Һаран, атасы Терах исән чакта
ук, туган җирендә – кил-
даниләрнең Ур шәһәрендә
вафат булды.
29 Ибрам белән Нахор исә өйлә-
неп яшәделәр. Ибрам хаты-
нының исеме Сарая, Нахор
хатынынык Милкә иде.
Милкәнең һәм Искәнең ата-
сы – Һаран иде.
30 Сарая, кысыр калып, бала
тапмады.
31 Терах, үзенең углы Ибрамны,
оныгы Лутны (Һаранның
углын) һәм киленен – Иб-
рам хатыны Сараяны ияртеп,
Кәнган җиренә күчеп китү
нияте белән килданиләр шә-
һәре Урдан юлга чыкты. Әмма
Харанга җиткәч, тукталып,
алар шунда торып калдылар.
**Яратылыш 12**
1 Раббы Ибрамга әйтте: «Тор-
ган җиреңне, туганнарың-
ны, атаң йортын калдыр,
Мин күрсәтәчәк җиргә күчеп
кит! – диде. –
2 Синнән Мин бөек халык
тудырачакмын, сине мө-



## Ибраһим

***Ибраһимның ата-бабалар җирен ташлап китүе***

**19 сүрә**
41 Ибраһим г-мнең Коръәндәге
хәбәрен зекер ит! Ул гаять
дөрес сүзле изге пәйгамбәр
булды.
42 Ибраһим әйтте: «Ий атам, ни
өчен ишетми, күрми һәм си-
ңа файда да, зарар да иреш-
терә алмый торган нәрсәгә
гыйбадәт кыласың?
43 Ий атам, Аллаһудан миңа
гыйлем вә дәлилләр килде,
ул гыйлем вә дәлилләр син-
дә юк, миңа ияр, туры юлга
күндерермен!
44 Ий атам, шайтанга гыйбадәт
кылма, чөнки шайтан Алла-
һуга гөнаһкяр булды.
45 Ий атам, сине Аллаһ газабы
тотуыннан куркамын, ул ва-
кытта газап эчендә шайтанга
якын булырсың».
46 Ибраһимның атасы әйтте:
«Ий Ибраһим, син безнең
илаһларыбыздан баш тар-
тасыңмы? Әгәр ул эшеңне
туктатмасаң, әлбәттә, мин
сине ташлар белән атармын.
Мине ялгыз калдырып күп
вакытка кит!»
47 Ибраһим г-м әйтте: «Ярый,
алай булса, сәламәт вә ты-
ныч бул, мин сине мәҗбүр
итмәм, синең өчен Раббым-
нан гафу итүен сорармын,

барәк кылачакмын, исе-
меңне шөһрәтле итәчәк-
мен; син фатиха-бәрәкәт
иясе булачаксың.
3 Сиңа изгелек теләгәннәргә
Мин изгелек эшләячәк-
мен, сине каһәрләгәннәргә
ләгънәтемне яудырачакмын.
Җир йөзендәге халыкларның
һәммәсе синең аша фатиха
алачак».
4 Ибрам, Раббысы боерганча,
юлга чыкты. Лут та аның
белән китте. Хараннан
чыгып киткән вакытын-
да, Ибрамга җитмеш биш
яшь иде.
5 Хатыны Сарая һәм бертуган
энесенең углы Лут белән бер-
гә Ибрам, Харанда тупла-
ган бар мал-мөлкәтен алып
һәм кул астындагы барлык
хезмәтчеләрен ияртеп, юлга
чыкты һәм Кәнганга барып
җитте.
6 Ул, илне буйга кичеп, Шәкем-
дәге Мөре имәнлеге дигән
җиргә килеп туктады. Ул
заманда анда кәнганиләр
яши иде.
7 Раббы, Ибрамның каршысын-
да пәйда булып: «Менә бу
җирләрне Мин синең токы-
мыңа бирәм», — диде. Раб-
бысы пәйда булган төшкә
Ибрам мәзбәх ясады.

**Яратылыш 17**

5 Моннан соң синең исемең
дә Ибрам түгел, ә Ибраһим



чөнки Ул догаларымны ка-
бул итә иде.
48 Инде үзегезне вә Аллаһудан
башка мәгъбудләрегезне
ташлап китәмен. Мин Раб-
быма дога кыламын, Раббы-
ма кылган догаларымның
кире кайтарылмавын өмет
итәмен».
49 Ибраһим г-м мөшрикләрдән
вә Аллаһудан башканы тот-
кан мәгъбудләреннән аеры-
лып киткәч, Без аңа Исхакны
вә аның угълы Ягъкубны
бирдек вә барын да пәйгам-
бәр кылдык.
50 Вә Без аларга рәхмәтебез-
дән мал вә балалар һәм
пәйгамбәрлек бирдек, дә-
хи аларга һәрбер дин әһеле
каршында яхшы вә дөрес
сөйләүче тел бирдек, һәр
дин әһеле аларны мактап
сөйли.

**21 сүрә**

71 Ибраһим белән Лутны үзебез
бөтен галәм өчен бәрәкәтле
кылган Шам җиренә күче-
реп залим кавемнәреннән
коткардык.





булыр. Чөнки Мин сине
күп халыкларның нәсел
атасы итәчәкмен.

### *Кунакларының Ибраһимга улы туасын хәбәр итүләре*

**Яратылыш 18**

1 Көндезге челлә бер вакытта
Мәмре имәнлегендәге үзенең
чатыры ишеге төбендә утыр-
ган Ибраһимның алдында
янә Раббы пәйда булды.
2 Ибраһим, башын күтәреп,
күзләрен йөртте һәм кар-
шысында өч ир басып тор-
ганын күрде. Күргәч тә,
чатыр ишеге төбендәге
урыныннан җәһәт торып,
тегеләрнең каршыларына
ашыкты һәм, башын җиргә
кадәр иеп:
3 «И хуҗа әфәндем! Әгәр кү-
ңеләңә хуш килсәм, колың
яныннан читләтеп үтмә, —
диде. —
4 Бераз су китереп, аяклары-
гызны юарлар; шушы агач
күләгәсендә ял итеп алыгыз.
5 Ә мин ашарыгызга икмәк
алып килермен, йөрәклә-
регезгә дәрман булыр, сез —
мин колыгызның кунакла-
рыдыр. Аннан юлыгызны
дәвам итәрсез». Юлчы адәм-
нәр: «Ярый, шулай эшлә,
әйткәнеңчә булсын», — ди-
деләр.
6 Ибраһим чатырга таба — Са-
расы янына ашыкты. Аңа:



### *Кунакларның Ибраһимга улы туасын хәбәр итүләре*

**51 сүрә**

24 Сиңа ирештеме Ибраһим пәй-
гамбәрнең хөрмәтле кунак-
ларының хәбәре?
25 Ул кунаклар Ибраһим хозу-
рына кергәч сәлам бирделәр,
Ибраһим да аларга сәлам
бирде һәм күңеленнән, болар
ят кунаклар, танымыймын,
диде.
26 Ибраһим, кунакларга кайда
барганын белдермичә, ха-
тыны янына аш хәзерләргә
китте, бераз вакыт үткәч,
симез бозау итен китерде.
27 Ул итне кунакларның алла-
рына якын куйды, кунаклар
исә ашамадылар, чөнки алар
фәрештә иделәр, ләкин Иб-
раһим белми иде. Ибраһим
кунакларга, ашамыйсызмы,
диде.
28 Кунаклар ашамагач, Ибра-
һимның күңеленә курку
төште, ихтимал, бу кеше-
ләр начар ният белән кил-
гәннәрдер, дип уйлады. Ку-
наклар үзләренең фәрештә
икәнне белдереп Ибраһимга,
курыкма, диделәр һәм зур
галим буларак бер ир ба-
ла белән Ибраһимга сөенеч
бирделәр.

«Өч үлчәм сыйфатлы оннан
тиз генә камыр куй да төче
икмәк пешер», – диде.
7 Аннан үзе сыер көтүенә таба
китте, симез-көр һәм яхшы
бер бозауны сайлап алып,
хезмәтчесенә тапшырды.
Хезмәтче адәм ашыга-ашыга
бозау итеннән табын ашы
әзерләде.
8 Әзерләнгән азыкны Ибраһим
сөт һәм май белән берлектә
кунаклар алдына табынга
китереп куйды. Кунаклар
ашаганда, үзе аларның ян-
нарында агач күләгәсендә
басып торды.
9 Кунаклар Ибраһимнан: «Ха-
тының Сара кайда соң?» –
дип сорадылар. Ибраһим: «Ул
монда, чатыр эчендә», – дип
җавап бирде.
10 Кунаклардан берсе әйтте:
«Киләсе елны нәкъ шушы
вакытта яныңа кабат килә-
чәкмен, – диде. – Ул вакыт-
ны инде хатының Сараның
бер углы булыр». Ә Сара
арткы якта, чатыр ишеге
ышыгында, моның сүзлә-
рен ишетеп торды.
11 Ибраһим белән Сара кар-
тайганнар, инде олы яшьтә
иделәр. Сарада күрем килү
гадәте тукталган иде.
12 Сара үзалдына көлеп: «Карт-
лык көнемдә кая инде миңа
андый бәхет-юаныч насыйп
булсын?! – дип уйлады. –



29 Кунакларның сүзен ишетеп,
Ибраһимның хатыны Сара
кунаклар алдына тавышла-
нып чыкты вә йөзенә сугып
әйтте: «Мин бала тапмый
торган карчыкмын, мин-
дә кайдан бала булсын», –
дип.
30 Фәрештәләр әйттеләр: «Без
әйткәнчә, Раббың Аллаһ
әйтте, тәхкыйк, Ул – Ал-
лаһ – эшне белеп эшләүче вә
һәрнәрсәне белүче», – дип.

**15 сүрә**

52 Кунаклар Ибраһим янына
кергәч сәлам бирделәр, алар
фәрештәләр иде, Ибраһим:
«Мин сездән куркамын», –
диде.
53 Фәрештәләр әйттеләр: «Син
бездән курыкма, без сиңа
шатлыклы хәбәр китердек,
сездән бер галим бала ту-
ачак».
54 Ибраһим г-м әйтте: «Гаҗәп,
сез миңа карт көнемдә ба-
ла белән сөенеч бирәсезме?
Нинди гаҗәп нәрсә белән
хәбәр бирәсез!»
55 Фәрештәләр әйттеләр: «Без
сиңа булачак хак хәбәр бе-
лән сөенеч бирәбез, син өмет
өзүчеләрдән булма!»
56 Ибраһим әйтте: «Әлбәттә,
мөэмин бәндә Раббысының
рәхмәтеннән өмет өзмәс, мә-
гәр адашкан кешеләр генә
өмет өзәрләр».







Хуҗам-әфәндем дә андый
яшьтән узган».
13 Раббы Ибраһимнан: «Сара
ни өчен: „Картлык көнемдә
кая инде миңа бала табу?!“ –
дип көлеп җибәрде? – дип
сорады. –
14 Раббы өчен мөмкин булма-
ган нәрсә бармыни?! Киләсе
елны билгеләнгән вакытка
Мин синең яныңа әйләнеп
килгәндә Сараның бер углы
булыр».
15 Сара куркып калган иде. Ул:
«Мин көлмәдем», – дип ак-
ланып маташты. Әмма Раббы
әйтте: «Юк, көлдең», – диде.
16 Кунаклар, урыннарыннан то-
рып, Сәдүмгә таба юл алды-
лар. Ибраһим аларны озата
китте.

***Ибраһимның Сәдүм шәһәренә Аллаһыдан мәрхәмәт соравы***

17 Раббы әйтте: «Эшләргә җы-
енган эшемне нигә Миңа
Ибраһимнан яшерергә?! –
диде. –
18 Ибраһим нәселеннән һич-
шиксез бөек һәм куәтле ха-
лык яралачак һәм җир йөзен-
дәге халыкларның һәммәсе
аның аша фатиха алачак.
19 Үзенең угылларына һәм өй җә-
мәгатенә Раббы юлын күн-
дерсен дип, аларны тугры
һәм гадел булырга өйрәтсен
дип, һәм аңа биргән вәгъ-



***Ибраһимның Сәдүм шәһәренә Аллаһыдан мәрхәмәт соравы***

**11 сүрә**

74 Ибраһим г-мнән курку беткәч
һәм аңа бала булачагы белән
шатлыклы хәбәр дә булгач,
Лут кавеме хакында безнең
белән бәхәсләшәдер...
75 Тәхкыйк, Ибраһим шәфкатьле
вә Аллаһудан куркып әһ-вәһ
итүче һәм тәүбә белән Алла-
һуга кайтучы.
76 Җәбраил г-м әйтте: «Ий Иб-
раһим! Лут кавеме турында
бәхәсләшүдән туктагыл,
тәхкыйк, Раббыңнан аларга

дәмне үтәр өчен, Ибраһимны сайладым Мин».

20 Ахырда Раббы әйтте: «Сәдүм белән Гамура явызлыкка баткан, гөнаһлары бик авырдыр.

21 Шунда иңеп, Миңа килеп ирешкәннең дөресме-түгелме, гөнаһлары бармы-юкмы икәнен беләчәкмен».

22 Юлчылар, кузгалып китеп, Сәдүмгә таба юнәлделәр. Әмма Ибраһим Раббының хозурында калды.

23 Ибраһим, Аңа якынлашып: «Син тәкъваны да яман белән бергә юк итәрсеңме? – дип сорады. –

24 Бәлки, бу шәһәрдә илле тәкъва кеше бардыр. Шул илле тәкъвага мәрхәмәт күрсәтмичә, алар яшәгән җирне юк итәрсеңмени?

25 Мондый эш Синнән ерак торсын. Яманны да, тәкъваны да бер тиң күреп, тәкъваны яман кеше белән бергә һәлак итүең мөмкин түгел! Бөтен дөньяның Хөкемчесе мондый гаделсезлеккә юл куймас!»

26 Раббы әйтте: «Әгәр Сәдүм шәһәрендә тәкъва илле адәм табылса, Мин бу урынны исән-имин калдырачакмын», – диде.

27 Ибраһим: «Менә мин, туфрак вә көл бер адәм, Син Хуҗа-Хакимем белән сөйләшеп сүз әйтергә җөрьәт итәм, – диде. –

газап белән әмер килде, шиксез, аларга газап килүчедер, инде ул килүче газап алардан һич тә кире китмәс.

**29 сүрә**

31 Җибәрелгән фәрештәләр Ибраһимга шатлык хәбәре илә килгәч, ул фәрештәләр әйттеләр: «Без бу Лут шәһәренең халкын һәлак итүчебез, тәхкыйк, ул шәһәрнең халкы имансыз залим булдылар», – дип.

32 Ибраһим әйтте: «Бит ул шәһәрдә Лут пәйгамбәр бар». Фәрештәләр әйттеләр: «Без ул шәһәрдә кемнәр барлыгын яхшы беләбез, әлбәттә, без Лутны вә аңа ияргән мөэминнәрне коткарачакбыз, мәгәр хатынын коткармабыз, чөнки ул газапта калучылар җөмләсеннән булды».

**15 сүрә**

57 Ибраһим фәрештәләрдән сорады: «Миңа сөенеч бирүдән башка тагын нинди эшегез бар, ий илчеләр!?»

58 Фәрештәләр әйттеләр: «Азган, чиктән чыккан кяфер халыкны һәлак итәр өчен җибәрелдек Без.

59 Мәгәр Лутны өй җәмәгате белән һәлак итмәбез, барчасын коткарырбыз.

60 Мәгәр Лутның хатыны азгыннардан, шуның өчен кяферләр белән бергә һәлак булачак».



ИБРАМ – ИБРАҺИМ

28 Бәлки, тәкъвалар иллегә тулып җитмәс, биш кешегә кимрәк булыр. Шул биш кешегә ким булган өчен, бөтен шәһәрне харап итәрсеңме?» Раббы: «Әгәр анда кырык биш тәкъва кешене тапсам, шәһәрне харап итмәячәкмен», – дип җавап бирде. <...>

31 «Инде менә янә Син Хуҗа-Хакимемнән сорарга җөрьәт итәм, – диде Ибраһим. – Әгәр анда егерме генә тәкъва кеше табылса?» Раббы: «Егерме генә кеше булганда да, шәһәрне харап итмәячәкмен», – дип җавап бирде.

32 «Тагын бер мәртәбә авыз ачып сүз әйткәнем өчен ачуланма, Хуҗа-Хакимем, – диде Ибраһим. – Бәлкем, анда тәкъвалардан ун гына кеше табылыр?» Раббы: «Унау гына булганда да, шәһәрне юк итмәячәкмен», – диде.

33 Шулай дип, Раббы Ибраһим белән әңгәмәсен тәмамлады да китеп барды. Ибраһим да чатырына кире кайтты.

***Лутның Сәдүм шәһәреннән качып котылуы***

**Яратылыш 19**

1 Кичке якта әлеге ике фәрештә Сәдүмгә килеп җитте. Бу вакыт Лут шәһәр капкасы янында утыра иде. Юлчыларны күргә, ул каршыларга дип аягүрә басты

**51 сүрә**

32 Фәрештәләр: «Без бозыклык кылучы кавемне һәлак итәр өчен җибәрелдек,

33 алар өстенә балчыктан ясалган ташларны яудырмак өчен,

34 ул ташлар Раббың хозурында чиктән чыгып азган кавемнәрне үтерү өчен хәзерләнгән», – диделәр.

35 Без чыгардык ул шәһәрдән Лут кавеме эченнән мөэмин булган кешеләрне.

36 Лут пәйгамбәр кавеме шәһәрләрендә бер генә мөселман йортын таптык, ягъни Лут пәйгамбәр йорты гына мөселман йорты иде».

***Лутның Сәдүм шәһәреннән качып котылуы***

**11 сүрә**

77 Илче фәрештәләребез Лут хозурына килгәч, Лут фәрештәләр хакында кайгыга калды, чөнки фәрештәләр бик чибәр егетләр кыяфәтендә килделәр. Лут аларның

һәм җиргә кадәр башын иеп
сәлам бирде.
2 Аннары: «Әфәнделәрем, ко-
лыгызның өенә рәхим ите-
гез, – диде. – Аякларыгызны
юарсыз, бездә төн кунып,
иртәгесен янә юлыгызны дә-
вам итәрсез». Фәрештәләр:
«Юк, без урамда төн куна-
чакбыз», – диделәр.
3 Ләкин Лут бик нык кыстагач,
алар өйгә керделәр. Лут та-
бын җәйде, төче камырдан
икмәк пешерде. Фәрештәләр
ашадылар.
4 Кунаклар йокларга әле ятма-
ганнар да иде, шулвакыт Сә-
дүмнең бөтен тарафыннан
җыелган ир халкы, олысын-
нан алып кечесенә кадәр,
Лутның өен чолгап алды.
5 Лутны чакырып, алар: «Сиңа
төн кунарга кергән адәмнәр
кайда? – дип сорадылар. –
Чыксыннар, нинди икәннә-
рен татып белик».
6 Лут, алар янына чыгып, үз ар-
тыннан өенең ишеген бикләп
куйды.
7 «Кардәшләрем, зинһар, яман-
лык эшләмәгез, – диде ул. –
8 Менә, минем ир күрмәгән ике
кызым бар; яныгызга шу-
ларны чыгарам, алар белән
теләгәнегезне эшләгез; әмма
бу адәмнәргә тимәгез, чөнки
алар минем өй кунакларым».
9 Ләкин сәдүмлеләр аңа: «Мон-
дарак кил! – диделәр. Әйтте-

ТӘҮРАТ

фәрештә икәнлекләрен бел-
мәде, хәтта алар хакында
күкрәге кысылды, күңеле
сынды вә әйтте: «Бу көн авыр
көн, ни булыр инде». Лутның
бер явыз хатыны: «Лутка бик
чибәр кунак егетләре килде,
барып файдаланыгыз», – дип
залимнәр арасына хәбәр та-
ратты.
78 Әлеге азган халык Лут өенә
йөгерешеп килде, моннан
элек тә алар яман эшләрне
кылдылар. Аларның яман
эшләре шул: яшь егетләр-
не кызлар итеп кулланыр-
лар иде. Лутның кунаклары
янына йөгерешеп килүләре
шуның өчен иде. Лут аларга
әйтте: «Ий кавемем, менә
минем сезгә кызларым, ни-
кахлап алыгыз да якынлык
кылыгыз, алар сезне гөнаһ-
тан пакьләрдер. Аллаһудан
куркыгыз, хәләл бар чагында
хәрамнан сакланыгыз, мине
кунакларым хакында рис-
вай кылмагыз! Әллә сезнең
арагызда бу яман эшнең
кабахәтлеген белүче бер ир
юкмы? Әгәр арагызда гакыл-
лы ир булса, сезне бу эштән
тыяр иде».
79 Әйттеләр: «Ий Лут, үзең бе-
ләсең, синең кызларыңда
безнең хаҗәтебез юк, дәхи
безнең нәрсә теләгәнебезне
дә беләсең ки, без синең ку-
накларыңны телибез».

КОРЪӘН





ләр: – Бу адәм бирегә читтән
килгән бер килмешәктер, ә
үзен әнә нинди хуҗа итеп
саный! Хәзер без сине кунак-
ларыңа караганда да яманрак
эшкә дучар итәрбез». Шулай
дип, Лутка таба якынлашты-
лар һәм өйгә бәреп кермәкче
булдылар.
10 Әмма ишектән кунак адәм-
нәрнең куллары сузылып,
Лутны өй эченә тартып керт-
теләр дә ишекне эчтән бик-
ләп куйдылар,
11 ә ишек каршына җыелганнар-
ны, олысыннан алып кече-
сенә кадәр, һәммәсенең күз-
ләрен сукырайтып, ишекне
таба алмастай хафалы хәлгә
төшерделәр.
12 Әлеге ике кунак Лутка әйт-
теләр: «Синең монда тагын
кемнәрең бар? Киявеңме,
угылларың, кызларыңмы –
кем генә булса да, якын ти-
ешле һәммә кешеңне шәһәр-
дән читкә алып чык!
13 Чөнки без бу шәһәрне юк
итәчәкбез. Бу шәһәр хал-
кының явызлыклары Раб-
быга ишетелде. Раббы без-
не шәһәрне юк итәргә дип
җибәрде».
14 Лут, өеннән чыгып, үзенең
кызларын хатынлыкка ала-
сы кияү егетләргә: «Торы-
гыз, бу җирне ташлап ките-
гез! – диде. – Чөнки Раббы
бу шәһәрне юк итәчәк». Әмма

ТӘҮРАТ

80 Лут әйтте: «Әгәр минем сезгә
куәтем җитсә иде, яки бер
куәтле җәмәгатькә мөрәҗә-
гать итәргә көчем булса иде,
әлбәттә, мин сезне ни эш-
ләргә белер идем».
81 Фәрештәләр әйттеләр: «Ий
Лут, без Раббыңның илче-
ләребез, кавемең сиңа һич
зарар кыла алмас, син кич-
нең бер вакытында өй җә-
мәгатеңне алып чыгып кит,
сездән һичберегез аерылып
калмасын, мәгәр залимнәр
ягына авышкан хатыныңны
алып чыкма, тәхкыйк, кя-
ферләргә килә торган газап
хатыныңа да ирешер. Дөрес-
лектә, бу кяферләрнең газап
кылынырга вәгъдәләре таң
вакытыдыр, әллә таң якын
түгелме?» Җәбраил г-м шә-
һәрләрен канаты белән кү-
тәреп аннары әйләндереп
җиргә ташлады, һәммәсе
һәлак булдылар.

**27 сүрә**

54 Лутны хәтерләгез, кавеме-
нә ул әйтте: «Әйә сез бик
яман фәхеш эшне кыла-
сызмы, җитмәсә, яшерми-
чә бер-берегезгә күрсәтеп
эшлисез.
55 Әйә сез хатыннарны куеп
күп ирләргә якынлык кы-
ласыз, бәлки сез эшегезнең
ахыры ничек булачагыны
уйламый торган җаһил ка-
вемсез».

КОРЪӘН

кияү егетләргә Лутның сүзләре шаярту булып тоелды.

15 Таң беленгәч, фәрештәләр Лутны ашыктыра башладылар: «Хатыныңны һәм яныңдагы ике кызыңны ал да тизрәк моннан кит! – диделәр. – Юкса гөнаһлы шәһәр белән бергә син дә һәлак булырсың».

16 Лут акрын кыймылдады. Шуңа күрә әлеге адәмнәр, Раббының Лутка булган миһербанлылыгына таянып, аны һәм хатыны белән ике кызын култыклап алдылар да шәһәр читенә алып чыктылар.

17 Шәһәр читенә чыгып җиткәч, адәмнәрнең берсе Лутка әйтте: «Җаныңны коткарыйм дисәң, тизрәк кач моннан, артыңа борылып карама, бер җирдә дә тукталыш ясама! – диде. – Таулар арасына качып, җаныңны коткарып кал». <...>

25 бу шәһәрләрне, анда яшәүчеләрне, бөтен тирә-юньне туфрактагы үсемлекләре белән бергә юк итте.

26 Лутның хатыны исә, юлда барганда, артына борылып карады да шундук тоз баганасына әверелде.

27 Ибраһим, таң белән торып, өнендә Раббы хозурында басып торган урынга китте.

56 Лут кавеменең җавабы булмады, мәгәр Лутның җәмәгатен шәһәрегездән чыгарыгыз, тәхкыйк, алар ирләрнең артына якынлык кылудан пакь адәмнәрдер, дигән сүзләре булды.

57 Без Лутны вә аның әһелен коткардык, мәгәр хатынын коткармадык, бәлки газапта калучылардан итеп тәкъдир иттек. Чөнки ул хатын азган кавемгә яшерен ярдәм итүче иде.

58 Аларның өстенә яңгыр урынына таш яудырдык, пәйгамбәр җибәреп Аллаһ газабы белән куркытып та курыкмаган кавемнәрнең яңгыры нинди яман яңгырдыр.

**51 сүрә**

32 Фәрештәләр: «Без бозыклык кылучы кавемне һәлак итәр өчен җибәрелдек,

33 алар өстенә балчыктан ясалган ташларны яудырмак өчен,

34 ул ташлар Раббың хозурында чиктән чыгып азган кавемнәрне үтерү өчен хәзерләнгән», – диделәр.

35 Без чыгардык ул шәһәрдән Лут кавеме эченнән мөэмин булган кешеләрне.

36 Лут пәйгамбәр кавеме шәһәрләрендә бер генә мөселман йортын таптык, ягъни Лут пәйгамбәр йорты гына мөселман йорты иде.





28 Сәдүм белән Гамураны, бөтен тирә-юньне күзеннән кичереп, шуны күрде: җир өстеннән һавага мич моржасыннан чыккан сыман төтен күтәрелә иде.

29 Шулай булды ки, бөтен бу тирә шәһәрләрен юк итәргә җыенганда, Аллаһы Ибраһимны хәтерендә тотты һәм һәлак ителәсе шәһәрдә яшәгән Лутны һәлакәт мәйданыннан читкә чыгарды.

### *Ибраһимның Аллаһыга корбан китерүе*

**Яратылыш 22**

1 Шулай булды ки, бу вакыйгалардан соң Аллаһы Ибраһимны сынап карарга теләде һәм аңа: «Ибраһим!» – дип өн салды. «Мин тыңлыйм!» – дип җавап бирде Ибраһим.

2 Аллаһы әйтте: «Бердәнбер сөекле углыңны Исхакны ал да Мориа җиренә юл тот, Мин сиңа күрсәткән тауга барып җиткәч, корбанлык учагы өстендә углыңны корбанга китер!» – диде.

3 Ибраһим иртән таң белән торды, ишәген иярләде, корбанлык учагы өчен утын ярды да, углы Исхакны һәм үзенең ике колын ияртеп, Аллаһы күрсәткән җиргә карап, юлга чыкты.

**11 сүрә**

82 Аларга газап белән әмеребез килгәч, шәһәрләрен астын өскә әйләндердек һәм алар өстенә таш яудырдык, ул ташлар кыздырылган булыр.

### *Ибраһимның Аллаһыга корбан китерүе*

**37 сүрә**

99 Вә ул әйтте: «Раббым әмер иткән урынга күчеп китәмен, әлбәттә, Раббым мине барасы җиремә җиткерер...

100 Ий Раббым, миңа бер изге бала биргел, миңа ярдәмче булсын!»

101 Без Ибраһимга бер ир бала белән шатлык хәбәрен бирдек, ул бала кечкенә чагында галим, олугъ хәлендә йомшак күңелледер.

102 Ул бала җиде яшенә җитеп атасы илә йөри башлагач, Ибраһим әйтте: «Ий угълым, мин төшемдә Аллаһ тарафыннан сине корбан итеп чалырга боерыламын, уйлап күр – бу эшкә ничек карыйсың? Угълы... әйтте: «Ий атам, ни белән боерылган

4 Сәфәрнең өченче көнендә Иб-
раһим ерактан ук билгелән-
гән тауны күрде.
5 Ибраһим үзе белән килгән
колларга: «Сез шушында
ишәк янында калып торы-
гыз, без исә малаем белән
тауга барып сәҗдә кылып
киләбез», – диде.
6 Шулай дип, корбанлык учагы
өчен әзерләнгән утынны уг-
лы Исхакка күтәртте дә, ку-
лына пычак һәм утлы чыраг
алып, икәве бергә тауга таба
киттеләр.
7 Исхак, атасына сүз катып:
«Әтием!» – диде. «Әйе, уг-
лым!» – диде Ибраһим. Ис-
хак: «Менә утын да, ут та бар,
ә корбанлык бәрәне кайда
соң?» – дип сорады.
8 «Углым, корбанлык бәрәнен
Аллаһы Үзе боерыр», – диде
Ибраһим. Алар шулай икәве
бергә юлларын дәвам иттер-
деләр.
9 Аллаһы күрсәткән тауга килеп
җиткәч, Ибраһим корбанлык
учагы өчен урын әзерләде,
шул урынга утын агачларын
тезеп өйде дә кул-аяклары
бәйләнгән Исхакны утын
өеме өстенә сузып яткырды
10 һәм, углын суяр өчен дип,
пычаклы кулын алга таба
сузды.
11 Әмма шулчак Раббының фә-
рештәсе күкләрдән өн салып:
«Ибраһим! Ибраһим!» – дип

ТӘҮРАТ

булсаң, шуны эшлә, мин Ал-
лаһ хөкеменә ризамын, бу
эштә мине, Аллаһ теләсә,
сабыр итүчеләрдән табар-
сың», – дип.
103 Безнең әмерне икесе дә риза
булып кабул иттеләр, һәм
(Ибраһим аны) яны белән
яткызды.
104 Кулына пычак алуга Без кыч-
кырдык: «Ий Ибраһим,
105 төшендә күргән Безнең әмер-
не тасдыйк кылдың, үтәгән
хөкемендә булдың». Әнә
шулай үзебезгә итагать ит-
кән яхшы мөэминнәрне из-
ге җәзалар белән нигъмәт-
либез.
106 Аллаһуның «изге балаң-
ны корбан итеп чал» дигән
әмере, әлбәттә, зур һәм авыр
сынаудыр.
107 Без аңа... корбан итеп бугаз-
лар өчен җәннәттән бер зур
тәкә бирдек.
108 Яхшылыгы белән искә алу
өчен дөньяга соңыннан кил-
гәннәргә Ибраһимның яхшы
әсәрләрен калдырдык.
109 Ул Ибраһимга барча галәм
сәлам әйтер.
110 Яхшы эшләрне кылучыга без
шулай изгелек итәбез.
111 Ибраһим Безнең хак мөэмин
колларыбыздандыр.
112 Дәхи Исхакны бирәчәгебез
белән шатлыклы хәбәр бир-
дек, Ул Исхак изгеләрдән вә
пәйгамбәрләрдән булды.

КОРЪӘН





эндәште. «Әйе, тыңлыйм!» –
дип җавап бирде Ибраһим.
12 Фәрештә әйтте: «Сузылган
кулыңны кире ал, углыңа
берни дә эшләмә! – диде. –
Инде Мин белдем: син Алла-
һыдан куркасың, Аны хөрмәт
итәсең, Минем хакка үзең-
нең бердәнбер углыңны да
корбан итәргә әзерсең икән».
13 Ибраһим, башын күтәреп,
тирә-ягына күз ташлады һәм
арткы яктагы әрәмәлектә мө-
гезе эләгеп чәбәләнгән бер
сарык тәкәсен күрде. Ибра-
һим, барып, сарык тәкәсен
алып килде дә углы урынына
корбанга китерде.
14 Шуннан соң Ибраһим бу
урынга «Аллаһы Үзе боерыр»
дип исем кушты. Хәзер әйте-
лә торган «Аллаһы тавында
боерылыр» дигән гыйбарә
шуннан килә.
15 Раббының фәрештәсе, күк-
ләрдән янә өн салып, Иб-
раһимга икенче мәртәбә
эндәште.
16 Әйтте: «Раббы белдерде ки,
Үз Затымнан ант итәм, диде,
үзеңнең бердәнбер углыңны
кызганмыйча, бу эшкә бар-
ганың өчен,
17 Мин сиңа фатиха өстенә фа-
тиха бирәчәкмен, нәсел ва-
рисларыңны күктәге йол-
дызлар һәм диңгез ярында-
гы ком бөртекләре санынча
ишәйтәчәкмен. Синең нәсел

ТӘҮРАТ

113 Ибраһимга вә Исхакка эш-
ләрендә вә нәселләрендә бә-
рәкәт бирдек, вә аларның
нәселләреннән килгән кеше-
ләрнең бәгъзеләре көферлек
вә бозыклык белән үзләренә
ачык золым итүчеләрдер.

КОРЪӘН

варисларының дошманнарының шәһәр-калаларын үзләренә милек итәчәк.

18 Минем өн-авазымны ишетеп, Мине тыңлаганың өчен, җир йөзендәге халыкларның һәммәсе синең токымың аша фатиха алачак», — диде.

19 Шуннан соң Ибраһим кол хезмәтчеләре янына килде. Алар белән бергә кайтыр юлга чыгып, Беер-Шебага юнәлде һәм шунда яшәргә калды.

### *Ибрам һәм Изге җир*

**Яратылыш 14**

17 Кедорлагомерны һәм аның яклы патшаларны тар-мар итеп кайтып килгәндә, хәзер Патша үзәне дип йөртелгән Шаве җирендә Ибрамны Сәдүм патшасы каршылады.

18 Аллаһы Тәгаләнең рухание булган Салим патшасы Мәлик-Садыйк та Ибрамны икмәк һәм шәраб белән каршы алды.

19 Изгелек теләп әйтте: «Җирне-күкне бар иткән Аллаһы Тәгалә бәндәсе Ибрамны мөбарәк кылсын!

20 Дошманнарыңны кулыңа тапшырган Аллаһы Тәгаләгә мактау-шөкерләр яусын!»

Ибрам үзендә булган бар мал-мөлкәтнең уннан бер өлешен Мәлик-Садыйкка бүлеп бирде.



### *Ибраһим һәм Изге җир*

**2 сүрә**

125 Янә хәтерләгез! Кәгъбәтулланы кешеләргә кайтачак урын итеп кылдык... Шулай ук Кәгъбәтулланы кешеләргә имин урын итеп кылдык. Инде Ибраһим г-м аяк баскан урынны намаз укый торган урын итеп алыгыз!..

126 Янә хәтерләгез Ибраһим г-мнең әйткәнен: «Ий Раббым, бу Мәккә шәһәрен имин кыл һәм Аллаһуга вә ахирәт көненә ышанучыларны төрле җимешләр белән ризыкландыр...»

127 Ибраһим илә Исмәгыйль Кәгъбәтулланың нигезен күтәргәч: «Ий Раббыбыз! Эшебезне кабул ит! Син ишетүче һәм күңелләрне белүчесең», — дип дога кылдылар.





21 Сәдүм патшасы Ибрамга:
«Адәмнәрне миңа калдыр,
мал-мөлкәтне үзеңә ал», —
диде.
22 Ләкин Ибрам Сәдүм патша-
сына әйтте: «Раббыга, җир-
не-күкне бар иткән Аллаһы
Тәгаләгә кулымны күтәреп
ант итәм: 23 синеке булган
мөлкәттән бер нәрсәне, хәтта
җепне яки аяк киеме каe-
шын да алмаячакмын. Син
кемгәдер: „Мин Ибрамны
баеттым!“ — дип әйтерлек
булмасын. 24 Ләкин угланнар
ашаган өлеш моңа керми.
Шулай ук минем белән бар-
ган адәмнәр — Анер, Эшкүл
һәм Мәмре — үз өлешләрен
алсыннар».



128 Ий Раббыбыз! Икебезне дә Үзеңә итагать итүче мөселманнардан кыл һәм нәселебездән дә мөселман булган җәмәгатьне насыйп ит һәм безгә хаж гамәлләрен өйрәт вә тәүбәләребезне кабул итеп гөнаһларыбызны гафу ит! Син, әлбәттә, тәүбәләрне кабул итүче, рәхимлесең.

129 Ий Раббыбыз! Бездән соң нәселебезгә үзләре арасыннан пәйгамбәр күндер! Ул пәйгамбәр өйрәтер аларга Синең китабыңны һәм... бөтен хөкемнәрен һәм пакьләр аларны мөшриклектән, бидгать гамәлләрдән һәм хәрам нәҗесләрдән. Ий Раббыбыз! Шиксез, Синә тиңдәш юк, көч-кодрәт иясесең һәм һәр эшне мәслихәтле кылучысың.

130 Ибраһим г-м тоткан ислам диненнән һичкем баш тартмас, мәгәр үз-үзенә ахмаклык кылган җаһил кеше генә баш тартыр. Шиксез, Ибраһим г-мне Үзебез дөньяда Имамга һәм пәйгамбәрлеккә сайладык, һәм ул ахирәттә изгеләр белән җәннәттә булыр.

131 Ибраһим г-мгә Раббысы әйтте: «Аллаһуга итагать итеп чын мөселман бул!» Ибраһим г-м әйтте: «Бөтен галәмнәрне тәрбияләүче Аллаһуга итагать итеп чын мөселман булдым», — дип.

132 Ибраһим г-м угылларына васыять әйтте һәм әмер бирде: «Ий угылларым, шиксез, Аллаһ сезгә ислам динен ирекле итте. Дөрес һәм ныклап Аллаһ динен тотыгыз! Динегез була торып, кяфер булмагыз, мөселман булып яшәп, мөселман булып үлегез!» Ягъкуб г-м дә угылларына шул ук сүзләрне әйтте...

КОРЪӘН



## Йосыф

### *Йосыфның төшләре*

**Яратылыш 37**

2 Ягъкубның яшәү рәвеше болайдыр. Унҗиде яшьлек углы Йосыф атасының хатыннары Билһа һәм Зилпәдән туган агалары белән берлектә көтү көтә һәм агаларының кырын эшләре турында аталары Исраилгә хәбәрләр җиткереп тора иде.
3 Исраил Йосыфны бүтән барлык угылларыннан артыграк ярата, чөнки Йосыф аның картлык көнендә туган баласы иде. Ул аңа төрле төстәге тукымадан затлы кием ясаткан иде.
4 Аталарының Йосыфны үзләренә караганда артыграк яратуын күргәч, Исраилнең өлкән угыллары Йосыфка нәфрәт белән карый башладылар, хәтта аның белән дустанә сөйләшмәс булдылар.
5 Бервакыт Йосыф төш күрде һәм төшен агаларына сөйләде. Шуннан соң агаларының нәфрәтләре тагы да көчәйде.
6 Йосыф әйтте аларга: «Тыңлагыз, мин сезгә күргән төшемне сөйлим, – диде. –
7 Имеш, без барыбыз да кырда көлтә бәйлибез икән. Шулчак мин бәйләгән көлтә җир өстенә туп-туры калкып утырды, ә сез бәйләгән

ТӘҮРАТ

## Йосыф

### *Йосыфның төшләре*

**12 сүрә**

3 Ий Мөхәммәт г-м! Без сиңа Коръәнне вәхи итеп кыйссаларның күркәмрәген хикәять кылабыз, гәрчә башта ул кыйссалардан хәбәрсез булсаң да.
4 Йосыф атасына әйтте: «Ий атам, мин төшемдә күрдем: унбер йолдыз һәм ай белән кояш көлеп миңа сәҗдә кылдылар».
5 Атасы әйтте: «Ий угълым, син төшеңне агаларыңа сөйләмә! Әгәр аларга сөйләсәң, хөсетләнеп сине һәлак итәр өчен хәйлә корырлар, чөнки шайтан адәмнәргә ачык дошман, агаларыңны хәйләгә котыртыр.
6 Раббың сиңа яхшы төш күрсәткән кеби, сине пәйгамбәрлеккә дә сайлыйдыр вә сиңа төш юрауны өйрәтәдер вә сиңа һәм Ягъкубның башка балаларына да нигъмәтләрен тәмам итеп бирер, моннан элек бабаларың Исхак белән Ибраһимга нигъмәтен тәмам итеп биргән кеби, әлбәттә, синең Раббың кемгә нәрсә бирергә икәнлекне белүче вә кирәгенчә эш кылучы».

КОРЪӘН

көлтәләр, минем көлтәне уратып алып, аның алдында сәҗдә кылдылар».

8 Агалары Йосыфка: «Син безнең өстән хаким булмакчы, безне үзеңә буйсындырмакчымы?!» – дип ризасызлык белдерделәр. Күргән төше, сөйләгән сүзләре өчен Йосыфны тагы да ныграк күрәлмый башладылар.

9 Йосыф, тагын бер төш күреп, аны да агаларына һәм атасына сөйләде: «Менә, мин тагын бер төш күрдем, – диде. – Имеш, кояш, ай һәм унбер йолдыз, сәҗдә кылып, миңа баш иделәр».

10 Төшен атасына һәм агаларына сөйләгәч, атасы ачуланып әйтте: «Нәрсәне аңлата синең күргән бу төшең? Мин, анаң һәм агаларың синең алдыңа килеп баш ияргә тиешләр дисеңмени?!» – диде.

11 Агаларының Йосыфтан зарланулары арта бара иде. Аталары исә боларның барысын күңеленә салып куйды.

***Йосыф агаларының хәйлә коруы***

12 Беркөнне Йосыфның агалары аталарының көтүен көтәргә Шәкемгә киттеләр.



***Йосыф агаларының хәйлә коруы***

7 Тәхкыйк, сораучыларга Йосыф вә аның кардәшләренең кыйссаларында, әлбәттә, гыйбрәтләр бар.





ЙОСЫФ

13 Исраил Йосыфка: «Агаларың Шәкемгә көтү карарга киткәннәр иде, – диде. – Син дә алар янына барып кайт». Йосыф: «Ярый», – дип җавап бирде. <...>

18 Йосыфның якынлашып килүен ерактан ук күреп алгач, агалары, аны үтерү өчен, үзара киңәш-табыш итә башладылар.

19 Бер-берләренә: «Әнә төш хастасы килә, – диештеләр. –

20 Үтерик тә мәетен берәр чокырга илтеп ташлыйк. Әйтербез, аны ерткыч хайван ашады, диярбез. Шуннан күрербез: күргән төшләреннән нәрсә килеп чыгар икән», – диделәр.

21 Рубин, бу сүзләрне ишетеп: «Юк, җанына тимибез!» – дип, Йосыфны кардәшләренең кара ниятләреннән йолып калырга тырышты.

22 «Кан коймагыз! – диде ул. – Аны чүлдәге берәр чокырга ташлап калдырыгыз, әмма үзенә кул тидермәгез». Рубиннең теләге – Йосыфны кардәшләре кулыннан коткарып калу, аны исән-имин хәлдә атасына кайтарып тапшыру иде.

23 Яннарына Йосыф килеп житүгә, агалары аның өстенә кигән төсле-чуар киемен салдырып алдылар да,



8 Йосыфның олугъ кардәшләре әйттеләр: «Әлбәттә, Йосыфны вә аның кардәше Биняминне атабыз бездән артыграк сөя, без кәсепче вә хезмәтчеләрбез, атабызны да тәрбиялибез; Йосыфлардан бер файда күрмәсә дә, аларны бездән артык күрәдер. Тәхкыйк, атабыз безнең хакта ачык ялгышадыр».

9 Агалары җыелып сөйләштеләр вә бәгъзеләре әйтте: «Йосыфны үтерегез яки билгесез бер урынга илтеп ташлагыз, аннары атагызның йөзе сезгә генә калыр, башкага һич карамас, шуннан соң тәүбә итеп, яхшы кешеләрдән булырсыз».

10 Араларыннан берсе әйтте: «Йосыфны үтермәгез! Аны кое төбенә салыгыз! Бәгъзе мөсафирләр аны табып алырлар вә ерак җиргә алып китәрләр, үзегез дә тынарсыз, әгәр шул эшне кылыр булсагыз, шуннан да яхшысы булмас». Бу киңәшкә бар да риза булып Йосыфны сорарга аталары янына килделәр.

11 Әйттеләр: «Ий атабыз, Йосыф хакында ни өчен безгә ышанмыйсың? Без аңа фәкать яхшылык телибез.

12 Йосыфны иртәгә безнең белән сахрага җибәр, төрле җимешләр ашап, уйнап йөрер, без

[24] култыгыннан тотып, су-
сыз-коры бер коега төртеп
төшерделәр.

***Йосыфны коллыкка сату***

[25] Шуннан соң үзләре ашар-
га дип утырдылар. Шулчак
Гилыгад тарафыннан бер
кәрван якынлашып килгә-
не күренде. Дөяләренә агач
сагызы, бәлзәм һәм ладан
төяп, Мисырга баручы ис-
мәгыйлиләр кәрваны иде бу.
[26] Кардәшләренә Яһүдә болай
диде: «Энекәшебезне үтереп,
аның канын яшереп калудан
безгә ни файда?!
[27] Без аны кәрванчы исмәгыйли-
ләргә сатып җибәрик, жаны-
на кул сузмыйк. Ул бит без-
нең энекәшебез, кан кардә-
шебез». Бүтәннәр Яһүдәнең
бу сүзләренә риза булдылар.
[28] Мидьян сәүдәгәрләре якын-
лашкач, Йосыфны коедан
чыгарып, егерме көмеш бә-
һасенә энеләрен Мисырга



аны, әлбәттә, саклырбыз, аңа
бер зарар да ирешмәс».
[13] Аталары әйтте: «Йосыфны
алып китүегез мине кайгы
вә хәсрәткә төшерә, мин
аңардан башка сабыр итә
алмыйм, аннары аны бүре
ашаудан да куркамын, вә сез
Йосыфтан гафил йөрерсез».
[14] Әйттеләр: «Әгәр без шул хәт-
ле күп була торып аны бүре
ашаса, ул вакытта без, әл-
бәттә, хәсрәттә булырбыз,
Йосыфны бүредән ашатмак
безгә зур кимчелек булыр».

***Йосыфны коллыкка сату***

[15] Кайчан Йосыфны алып кит-
теләр, аны кое төбенә салыр-
га иттифак кылдылар һәм
күлмәген салдырып үзен кое
төбенә төшерделәр, күлмәген
сорагач: «Унбер йолдыз, ай
вә кояш бирсеннәр», – дип
көлделәр. Без Йосыфка вә-
хи кылдык: «Бу җәфалар-
дан, әлбәттә, бер көнне ко-
тылырсың да сиңа кылган
явызлыкларын үзләренә
сөйләрсен», – дип; ләкин
алар Йосыфка вәхи кылга-
ныбызны сизмиләр.
[16] Вә шул көнне кич белән ела-
шып аталары янына кил-
деләр.
[17] Әйттеләр: «Ий атабыз, без Йо-
сыфны әйберләребез янын-
да калдырып үзебез йөгерү
ярышына киткән идек, без





баручы исмәгыйлиләргә са-
тып җибәрделәр.
[29] Рубин чокыр янына кабат ки-
леп басты, карый – чокырда
Йосыф юк, һәм ул өстен-ба-
шын ертып өзгәләнергә то-
тынды.
[30] Аннары, кардәшләре янына
килеп: «Энебез чокырда юк!
Инде мин нишлим? Кая ба-
рыйм?» – диде.
[31-32] Шуннан соң алар, көтү-
дән бер кәҗә тәкәсе тотып,
аны суеп, канына Йосыфның
парча киемен манчыдылар
да «Без менә нәрсә таптык.
Кара әле, бу синең углың-
ның киеме түгелме икән?
Әллә юкмы?» дигән сүзләр
белән бергә канга манчыл-
ган шул киемне аталарына
күндерделәр.
[33] Ягъкуб, киемне танып: «Бу –
минем углымның киеме, –
диде. – Йосыфымны ерткыч
хайван ботарлаган булса ки-
рәк!»
[34] Ягъкуб хәсрәттән өстен-ба-
шын ертты, ертык-портык-
ка төренеп, углы өчен озак
көннәр кан-яшь түкте.
[35] Барлык угыллары, кызла-
ры, җыелып, аны юатырга
тырышсалар да, ул тынычла-
ланырга теләмәде: «Углым
янына, үлеләр аймагына
хәсрәтем белән бергә китә-
чәкмен», – дип, углы өчен
күз яше коюдан туктамады.



әйләнеп килгәнче Йосыфны
бүре ашаган, ий атабыз, син
безгә ышанмыйсың, гәрчә
без дөрес сөйләсәк тә».
[18] Йосыфның күлмәген ял-
ган канга буяп аталарына
китереп бирделәр. Атала-
ры әйтте: «Юк, Йосыфны
бүре ашамагандыр, бәлки
нәфесегез бер хәйләне сез-
гә яхшы итеп күрсәткәндер
дә сез аны кылгансыз, ин-
де миңа күркәм сабырлык
кирәк! Сезнең хәйләгезгә
каршы Аллаһудан ярдәм со-
рыймын».
[19] Йосыфны салган коега якын
җиргә кәрван килде, су та-
шучыларын коега су алырга
җибәрделәр, сучы чиләген
коега төшерде вә Йосыф,
чиләккә ябышып, коедан
чыкты, су ташучы юлдашла-
рына әйтте: гаҗәп бер матур
угылдыр, нинди сөенеч без-
гә. Бу бала сатлык мал, үзебез
сатарбыз, дип сөйләштеләр,
ягъни коедан табылганлы-
гын бөтен кәрванга әйтми-
чә: «Кое янындагы кешеләр
Мисырга алып барып сатар
өчен бирделәр», – диделәр,
аларның кылган эшләрен
Аллаһ белүче.
[20] ...Кәрванчылар Йосыфны Ми-
сырга алып барып саттылар.
Йосыфны Мисыр патшасы-
ның беренче вәзире Газиз
күп акчага сатып алды.

36 Йосыфны исә Мидьян сәүдәгәрләре, Мисырга алып килеп, фиргавеннең сарай хезмәтчесенә – җансакчылар башлыгы Потифарга коллыкка саттылар.

*Йосыф Мисырда; Потифар хатыны*

**Яратылыш 39**

1 Йосыф Мисырга китерелде. Мисыр фиргавененең сарай хезмәтчесе, җансакчылар башлыгы Потифар, аны исмәгыйлиләр кулыннан сатып алды.
2 Раббы Йосыфны ташламады. Йосыфның бөтен эшләре уңышлы чыга иде. Ул үзенең мисырлы хуҗасы өендә яши башлады.
3 Өй хуҗасы Йосыфка Раббысы химая итүен, ни генә эшләсә дә, аның һәр эшен уңышлы кылуын күрә иде.
4 Йосыф шулай, хуҗасы күңеленә хуш килеп, аның хезмәтчесе булып китте. Ахырда



21 Мисыр вәзире – Газиз – хатыны Зөләйхәгә әйтте: «Бу баланың урынын күркәм кыл, яхшы тәрбиялә, шаять, без аңардан файда күрербез, яки аны үзебезгә бала итәрбез». Сатып алучы Газизгә сөекле күрсәткәнебез кеби, Йосыфны Мисыр җиренә урнаштырдык, анда вәзир кылмак вә төш юрау белемен өйрәтмәк өчен, Аллаһ Үз эшендә галибдер, җиңүчедер, теләгәнчә эш кылыр; ләкин күбрәк кешеләр белмиләр Аллаһу Тәгаләнең затын вә сыйфатын.

*Йосыф Мисырда; вәзир хатыны*

22 Йосыф үсеп бәлягатькә ирешкәч, Без аңа хикмәт вә белем бирдек; әнә шулай яхшы эшне эшләүчеләргә изге җәза бирәчәкбез.
23 Вәзир хатыны Зөләйхә үз өендә Йосыфтан ялынып вә ялварып нәфесе теләгәнне үтәвен таләп итте вә барча ишекләрне бикләде һәм «ий Йосыф, кил минем яныма, мине мәхрүм итмә» диде. Йосыф әйтте: «Бу эштән Аллаһуга сыгынамын, тәхкыйк, тәрбиячем Газиз миңа хөрмәт күрсәтте, торачак җиремне күркәм кылды, инде мин аңар ничек хыянәт итим! Бу эшне кылсам, залимнәрдән





Потифар үзенең өе белән идарә итүне, барлык хуҗалык эшләрен Йосыф кулына тапшырды.
5 Хуҗалык эшләре, өй белән идарә итү вазифасы Йосыф кулына тапшырылганнан соң, Йосыф хакына Потифарның өен Раббы мөбарәк кылды, аның йортында һәм кырларында башкарылган барлык эшләргә бәрәкәт насыйп итте.
6 Потифар үз хуҗалыгындагы бар нәрсәне шулай Йосыф хөкеменә калдырды, ашаган ризыгыннан башка бер нәрсә турында да кайгыртып уйламады. Йосыф зифа буйлы, төскә-биткә чибәр егет иде.
7 Потифар хатынының Йосыфка күзе төшеп: «Минем белән йокла», – дип, аңа тәкъдим ясады.
8 Әмма Йосыф баш тартты, хуҗабикәгә: «Менә, мин монда булганга, хуҗа әфәндемнең үз өендәге эшләрдән бернинди кайгысы юк, ул бөтен эшләрне минем кулга тапшырды, – дип җавап бирде. –
9 Бу өйдә мин дә аның кебек үк хуҗамын, – диде Йосыф. – Чөнки ул синнән кала бар нәрсәне минем ихтыярыма куйды. Әмма син – аның хатыны! Ничек инде мин, шундый яманлык эшләп,



булырмын бит, әлбәттә, залимнәр Аллаһ газабыннан котыла алмаслар».
24 Тәхкыйк, Йосыфны үзенә якынлык кылырга теләде Зөләйхә, вә Йосыф та Зөләйхәгә касд кылган булыр иде, әгәр Раббысының галәмәтләрен күрмәгән булса, ягъни шул вакытта Аллаһ аңа атасын күз алдына китерде, әнә шулай галәмәт күрсәттек Йосыфтан яман вә фәхеш эшне җибәрмәк өчен, чөнки ул безнең ихлас колларыбыздан.
25 Икесе дә ишекләргә таба йөгерделәр. Йосыф Зөләйхәдән котылыр өчен йөгерде, Зөләйхә Йосыфны чыгармас өчен артыннан йөгерде, Йосыфның күлмәген артыннан тотып үзенә тартты, күлмәк ертылды. Йосыф ишекләргә килгәндә бикле ишекләр Аллаһ кодрәте белән ачыла бардылар. Шулай куышып ишегалдына чыксалар, Зөләйхәнең ире Газизгә очрадылар. Зөләйхә үзенең иренә әйтте: «Синең хатыныңа яман касд кылган кешегә җәзасы нәрсә булыр? Әлбәттә, төрмәгә бикләү яки рәнҗетүче газап булыр».
26 Йосыф әйтте: «Зөләйхә үзе теләде минем аңа якынлык кылуымны. Йосыфның сүзен дөресләп, Зөләйхәнең

Аллаһы каршында үз өстемә зур гөнаһ алыйм?!»

10 Хуҗабикә һәркөн үзе белән йокларга, якынлык кылырга чакырса да, Йосыф аның сүзен тыңламады.

11 Шулай булды ки, беркөнне Йосыф үз эшләре белән өйгә керде. Бу юлы өй эчендә хуҗабикәдән башка беркем дә юк иде.

12 Хуҗабикә янә: «Минем белән йокларга ят!» — дип, кулы белән Йосыфның киеменнән эләктереп алды. Әмма Йосыф, өске киемен хуҗабикәнең кулында калдырып, тиз генә өйдән чыгып йөгерде.

13 Хатын, Йосыфның, өс киемен ташлап калдырып, өйдән чыгып качуын күргәч,

14 кычкырып, йорт хезмәткәрләрен чакырды һәм аларга: «Менә, күрегез! Бу гыйбри адәм безне мыскыл итәр өчен алып кайтылган, — диде. — Минем белән йокларга дип килгән булган, ләкин мин әче тавыш белән кычкырып җибәрдем.

15 Шулай ачыргаланып, әче тавыш белән кычкыруымны ишеткәч, менә, киемен ташлап калдырып, өйдән чыгып йөгерде».

16 Хуҗабикә, ире Потифар өйгә кайтканга кадәр, Йосыфның өс киемен үз янында саклап тотты.



кардәшләреннән бер сабый шәһадәт бирде вә ул сабый әйтте: «Әгәр Йосыфның күлмәге ал яктан ертылган булса, Зөләйхә сүзе дөрес булыр, Йосыф сүзе ялган булыр.

27 Әгәр Йосыфның күлмәге арт яктан ертылган булса, Зөләйхә сүзе ялган булып, Йосыф сүзе дөрес булыр».

28 Кайчан Зөләйхәнең ире Йосыф күлмәгенең арттан ертылганын күргәч, Зөләйхәгә әйтте: «Бу эш синең хәйләң икән, әлбәттә, сез хатынларның хәйләсе олугъ».

29 Газиз әйтте: «Ий Йосыф, бу эштән баш тарт, халыкка фаш итмә. Син, Зөләйхә, тәүбә ит, миннән гафу сора гөнаһың өчен! Тәхкыйк, син хаталанучылардан булгансың». Бу эш Мисырга җәелде, хатыннар бик күп сөйләделәр.

30 Мисырда бер төрле хатыннар әйттеләр: «Газизнең хатыны үзенең колыннан якынлык кылуын үтенгән вә аңа мәхәббәте чиктән ашкан икән, без ул Зөләйхәне ачык азгынлыкта күрәбез, чөнки Газизне ташлап, колны сөя башлаган».

31 Зөләйхә, ул хатыннарның гаепләп сөйләгәннәрен ишеткәч, аларны кунакка чакырып кешеләр җибәрде вә алар өчен яхшы урыннар вә хуш





ЙОСЫФ

17 Кайткач, аңа баягыча сүзләр белән хәлне сөйләп бирде: «Монда син алып кайткан гыйбри колың мине мыскыл итәргә теләде,

18 әмма мин әче тавыш белән кычкыргач, өс киемен монда калдырып, өйдән чыгып качты», — диде.

19 Үзенең колы өстеннән хатынының зарлануын ишеткәч, Потифарның ачуы тәмам соң чиккә житте.

20 Йосыфны ул тоткын итеп патшаның мәхбүсләре ята торган зинданга яптырды.



тәгамнәр әзерләде, кунаклар килеп ашарга утыргач, һәрберсенә үткен пычаклар бирде вә әйтте: «Ий Йосыф, ул хатыннар янына чык», — дип. Хатыннар Йосыфны күргәч бик олугъ эш санадылар вә яннарына утыртырга теләделәр һәм, Йосыфтан күзләрен ала алмыйча, тәгам кисәбез дип кулларын кискәләп бетерделәр вә әйттеләр: «Аллаһ пактьер, бу — кеше түгелдер, бу — һичкем түгел, мәгәр хөрмәтле фәрештәдер», — дип.

32 «Мине шуның хакында гаеп вә шелтә кылган кол — шул колдыр, дөрес, мин аның белән якынлык кылырга эстәдем, ләкин ул теләмәде, сакланды. — Соңра Зөләйхә хатыннардан үтенде, — миңа якынлык кылырга өндәгез», — дип, ләкин хатыннар бар да Зөләйхә теләгәнне теләделәр. Зөләйхә әйтте: «Әгәр мин әмер кылганны эшләмәсә, ягъни якынлык кылмаса, әлбәттә, зинданга салдырырмын, хурлыкка төшкән кешеләрдән булыр».

33 Йосыф әйтте: «Ий Раббы! Мине чакырган зинага караганда миңа зиндан яхшырак, әгәр ул хатыннарның хәйләләрен миннән үзең бетермәсәң, ул вакытта мин аларга авышырмын вә ярамаган

*Йосыфның төшләрне юравы*

20 Йосыф зинданга ябылса да,
21 Раббы аның янында булды,
мәрхәмәтен ирештереп, зин-
данбашы күңелендә Йосыф-
ка карата рәхимле караш
уятты.
22 Зинданбашы Йосыфны төрмә-
дәге барлык тоткыннар өс-
теннән карап торучы назыйр
итеп куйды. Тоткыннарның
зиндандагы бөтен эшләре
белән Йосыф җитәкчелек
итә иде.
23 Зинданбашы үзе Йосыф кул
астында эшләнә торган эш-
ләрнең һичберсе белән кы-
зыксынмады, чөнки Йосыф-
ның янында Раббы булып,
Раббы аның һәрбер эшен
уңышлы кыла иде.

**Яратылыш 40**

1 Бу вакыйгалардан соң бер-
вакыт Мисыр патшасының
шәрабчысы белән икмәкчесе
үзләренең хуҗалары алдында
гаепле булдылар.
2 Шунлыктан фиргавеннең
шул сарай хезмәтчеләре-
нә – баш шәрабчы белән баш



эшне эшләп җаһилләрдән
булырмын».
34 Йосыфның догасын Раббысы
кабул кылды һәм Йосыфтан
ул хатыннарның хәйләсен
җибәрде, дөреслектә, Ул –
сүзләрне ишетүче вә хәлләр-
не белүче.

*Йосыфның төшләрне юравы*

35 Йосыфның күлмәге арттан
ертылганлыгын вә сабый
баланың шәһадәт биргәнен
һәм хатыннарның кулларын
кискәннәрен күргәч, Йосыф-
ның гаебе юклыгы барчала-
рына да ачыкланды, шулай
булса да, азга гына Йосыфны
зинданга салырга булдылар.
36 Вә аның белән бергә ике егет
тә зинданга керде. Берсе –
хәмер ясаучы, икенчесе ик-
мәкче иде, алар төш күрде-
ләр. Аларның берсе әйтте:
«Мин төшемдә хәмер сык-
канымны күрдем». Вә икен-
чесе әйтте: «Мин төшемдә
икмәк күтәреп йөргәнемне
күрдем, ул күтәргән икмә-
гемнән кошлар ашый имеш.
Ий Йосыф, ул төшнең тәгъ-
бире нәрсә, безгә сөйләп бир.
Тәхкыйк, без сине яхшы ке-
ше дип беләбез».
37 Йосыф әйтте: «Мин сезгә
башта, ашый торган ризык-
ларыгыз алдыгызга килмәс
борын, ул ризыкларның
нинди ризык икәнлеге белән





икмәкчегә – бик тә нык ачуы
чыкты,
3 һәм ул аларны сак астына ал-
дырды: үзенең җансакчылар
башлыгы өе карамагындагы,
Йосыф яткан зинданга ябар-
га кушты.
4 Җансакчылар башлыгы бу ике
тоткынга хезмәт күрсәтү ва-
зифасын Йосыфка йөкләде.
Алар шулай берникадәр ва-
кыт сак астында бергә бул-
дылар.
5 Мисыр патшасының зинданга
ябылган әлеге шәрабчысы
белән икмәкчесе һәр икесе
бер төндә үзенә аерым мәгъ-
нәдәге төш күрделәр.
6 Иртән Йосыф, алар янына
кергәч, боларның бик нык
аптырашка калуын күрде.
7 Шуннан Йосыф үзенең ху-
җасы Потифар өе зин-
данында үзе белән бергә
тоткынлык кичерүче бу
ике фиргавен сарае түрә-
сеннән: «Бүген сезнең ни-
гә чырайларыгыз бик бо-
ек?» – дип сорады.
8 Алар әйттеләр: «Без төш күр-
дек, тик төшләребезне юрау-
чы кеше генә юк», – диделәр.
Йосыф: «Төш юрау Аллаһы
иркендә түгелме?! – диде. –
Миңа сөйләгезче!»
9 Баш шәрабчы күргән төшен
Йосыфка сөйләп әйтте: «Тө-
шемдә мин бер йөзем агачы
күрдем.



хәбәр бирермен, бу эшем вә
төшкә тәгъбир ясавым Раб-
бымның өйрәтүе беләндер,
тәхкыйк, мин Аллаһуга һәм
дә ахирәткә ышанмаган ке-
шеләрне ташладым, алардан
киселдем.
38 Вә мин кердем ата-бабала-
рым Ягъкуб, Исхак, Ибра-
һимнар диненә, Аллаһуга
берәр мәхлукны тиңдәш итү
безнең өчен һич тә дөрес вә
лаек түгел. Ошбу хак диндә
булуыбыз безгә вә башка ке-
шеләргә Аллаһуның юмарт-
лыгы вә рәхмәте, ләкин күп
кешеләр бу зур нигъмәт дип
белмиләр һәм Аллаһуга шө-
кер итмиләр».
39 Йосыф әлеге төш күрүче ике
егетне башта вәгазьләргә
теләде һәм аларга әйтте:
«Ий зиндандагы ике иптә-
шем! Ясалма күп илаһларга
гыйбадәт кылу хәерлеме?
Яки һич тиңдәше булмаган
бөтен мәхлукның хуҗасы
вә кодрәт иясе бер генә Ал-
лаһуга гыйбадәт кылу хә-
ерлеме? Әлбәттә, бер генә
Аллаһуга гыйбадәт кылу
хәерле.
40 Сез бер Аллаһуга гыйбадәт
кылмыйсыз, мәгәр үзегез вә
аталарыгыз Илаһ дип исем
биргән, һичнәрсәгә ярамый
вә файда бирми тор-
ган сынымнарга гыйбадәт
кыласыз, ул сынымнарга

10 Аның өч ботагы бар иде. Агач үсеп чәчәк атты, аннары тәлгәш-тәлгәш җимешләр өлгерде.

11 Мин фиргавеннең касәсен кулыма тотканмын имеш. Агачтан йөзем тәлгәшен алып касәгә сыктым да касәне фиргавенгә бирдем».

12 Йосыф шәрабчының төшен юрап әйтте: «Төшеңнең тәгъбире болайдыр: өч ботак — өч көн ул;

13 өч көннән фиргавен сине югары күтәрәчәк — элеккеге урыныңа кире кайтарачак. Электә фиргавеннең шәрабчысы булгандагы кебек, син янә фиргавен касәсен аның кулына биреп тора башлаячаксың.

14 Тик сиңа бер үтенеч! Эшләрең җайлангач, мине дә хәтереңә төшер: игелек күрсәтеп, минем хакта фиргавенгә сүз җиткер һәм мине бу йорттан чыгарырга булыш.

15 Мин — гыйбриләр иленнән урлап кителгән кеше! Мин бу илдә дә зинданга ябып куярдай бернинди яман эш эшләмәдем!»

16 Баш икмәкче, Йосыфның төшне яхшы юравын күреп, аңа: «Мин дә бер төш күрдем, — диде. — Баш түбәмә өсте-өстенә өч үрмә кәрзин куйганмын имеш.



гыйбадәт кылуның дөреслеге өчен Аллаһ һич дәлил индергәне юк, бу хакта хөкем итмәк фәкать Аллаһуга гына хастыр, башка затның хөкеме хөкем түгелдер, Ул — Аллаһ — Үзеннән башкага гыйбадәт кылмаска әмер кылды, бу ислам дине — хак дип, ләкин күп кешеләр белмиләр.

41 Ий зиндагы ике иптәшем, инде күргән төшегезгә тәгъбир кылам: әмма берегез зинданнан чыгып әүвәлге урынында хәмер ясаучы булыр, әмма икенчегезне асарлар вә башын кошлар ашар». Егетләр: «Без төш күрмәдек, уйнап кына әйткән идек», — диделәр. Йосыф әйтте: «Сез сорадыгыз — мин җавап бирдем, әлбәттә, эш мин тәгъбир кылганча булыр».

42 Егетләрдән берсе котыла дип зан кылганына, ягъни хәмерчегә Йосыф әйтте: «Зинданнан чыккач, патшага минем хаксыз зинданда ятканымны сөйлә, мине чыгарсын». Йосыфны патшасына әйтергә егеткә шайтан оныттырды, янә Йосыф ничә еллар зинданда калды.





17 Иң өстәге кәрзиндә фиргавен өчен төрле нигъмәтләр, икмәкче пешергән ризыклар. Менә шул ризыкларны башым өстендәге кәрзиннән, чукып-чукып, кошлар алып китәләр иде».

18 Йосыф икмәкчегә җавап биреп әйтте: «Төшнең тәгъбире болай: өч кәрзин — өч көн ул;

19 өч көннән фиргавен сине дә югары күтәрәчәк — сине агачка асып куячак, күк кошлары исә, чукып-чукып, синең тәнеңдәге итне ашаячаклар».

20 Өч көннән, үзенең туган көнендә, фиргавен барлык сарай түрәләре өчен зур мәҗлес җыйды һәм алар алдында баш шәрабчы белән баш икмәкчене югары күтәрде —

21 баш шәрабчыны элекке урынына кайтарды, һәм ул әүвәлгечә фиргавен кулына касәсен биреп тора башлады,

22 ә баш икмәкчене, Йосыф аларга юраганча, дарга асты.

23 Йосыфның тик үзен генә хәтергә төшерүче булмады, баш шәрабчы аны тәмам оныткан иде.

### *Фиргавен күргән төшләр*

**Яратылыш 41**

1 Ике ел вакыт кичкәннән соң, фиргавен дә бер төш күрде. Ул Нил елгасы ярында басып тора имеш.



### *Патша күргән төшләр*

43 Бервакыт дусларына патша әйтте: «Мин төшемдә җиде симез сыер күрдем, аларны җиде арык сыер ашый имеш, дәхи җиде кипкән башак вә

[2] Менә, елга суыннан көр-симез
бәдәнле җиде сыер чыкты да
яр буе камышлыгында утлап
йөри башлады.
[3] Ул да булмады, алар артын-
нан судан янә җиде сыер
чыкты. Болары гәүдәгә бик
тә арык-ябык сыерлар иде.
Алар яр буенда утлап йөргән
көр-симез сыерлар янына
килеп бастылар да
[4] тегеләрне ашарга керештеләр.
Арык-ябык җиде сыер көр
һәм симез җиде сыерны ашап
бетергәндә, фиргавен йокы-
сыннан уянды.
[5] Аннан ул тагын йоклап китте
һәм бу юлы башка бер төш
күрде. Имеш, бер сабактан
тук-симез орлыклы җиде ба-
шак үсеп чыкты.
[6] Шуның артыннан ук ач орлык-
лы, көнчыгыш җилләреннән
тәмам куырылып беткән янә
җиде башак үсеп чыкты да
[7] тук-симез орлыклы җиде ба-
шакны йотып-ашап бетерде.
Фиргавен, уянып, үзенең төш
күргәнлеген аңлады.
[8] Иртән аның бөтен җаны-ру-
хы тынычсыз иде. Ул, чап-
кыннар җибәреп, Мисыр-
ның барлык акыл ияләрен,
тәгъбирчеләрне чакыртып
алды һәм аларга үзенең күр-
гән төшләрен сөйләп бирде.
Ләкин аңа төшләренең мәгъ-
нәсен юрардай кеше табыл-
мады.



җиде яшел башак күрдем. Ий
җәмәгать, әгәр төш юрый
белсәгез, минем төшемне
юрагыз, тәгъбир итегез!»
[44] Патшаның дуслары әйттеләр:
«Бу төш – саташу гына, без
андый саташу төшләрнең
тәгъбирен белмибез».
[45] Зинданнан чыккан хәмер-
че, аңардан патшага әйтергә
үтенеп калган Йосыфның
сүзен күп еллардан соң исе-
нә төшереп, патшага әйтте:
«Мине зинданга җибәрегез,
аннан кайтып бу төшнең
тәгъбирен сезгә сөйләрмен».
Җибәрделәр, Йосыф янына
барды.
[46] «Ий дөрес сөйләүче Йосыф!
Син безгә җиде симез сыер
хакында җавап бир, ул симез
сыерларны җиде арык сыер
ашый, дәхи җиде яшел ба-
шак вә җиде кипкән башак
хакында безгә җавап бир.
Шаять, мин Мисыр хал-
кына кайтып җавабыңны
сөйләрмен, шаять, алар да
кадереңне белеп зинданнан
чыгарырлар».
[47] Йосыф әйтте: «Җиде ел тоташ-
тан иген чәчегез, җиде елда
уңыш яхшы булыр, алган
уңышны сукмыйча башагы
вә саламы белән кибәндә
сакларсыз, мәгәр үзегез ашар
хәтле генә сугып алырсыз.
[48] Моның соңында җиде ач-
лык еллары килер, уңышлы







[9] Шулчак баш шәрабчы, сүз со-
рап, фиргавенгә әйтте: «Мин
бүген үткәндәге гөнаһымны
хәтергә алырга мәҗбүрмен, –
диде. –
[10] Без колларына ачуы чыгып,
фиргавен мине һәм баш ик-
мәкчене җансакчылар баш-
лыгы йортындагы зинданга
яптырган иде.
[11] Бер үк төнне без икебез дә –
мин дә, ул да – һәркайсыбыз
үзенә аерым мәгънәдәге төш
күрдек.
[12] Зинданда безнең белән бергә
җансакчылар башлыгының
кол хезмәтчесе – бер гыйбри
егет утыра иде. Без күргән
төшләребезне аңа сөйләдек,
һәм ул һәркайсыбызның тө-
шен үзенчә юрап бирде.
[13] Аның юраганнары барысы да
дөрескә чыкты: мин әүвәлге
хезмәтемә кайтарылдым, ә
теге икмәкче дарга асылды».
[14] Фиргавен, Йосыфны тизлек
белән зинданнан чыгарып,
аны үз янына китертте. Са-
кал-чәчен алдырып, киемен
алыштыргач, Йосыф фирга-
вен хозурына килде.
[15] Фиргавен аңа болай диде:
«Мин бер төш күрдем, әм-
ма аны юрап аңлатырдай
кеше юк. Ә синең турыда:
„Төшләрне ишетүгә үк юрый
белә“, – диләр».
[16] Йосыф фиргавенгә җавап
биреп әйтте: «Бу минем



җиде елда җыйган игеннә-
регез җиде ачлык елларында
ашалып бетәр, мәгәр орлык
өчен саклаган аз гына иген-
нәрегез калыр.
[49] Соңра ачлык еллардан соң
бер ел килер, ул елда яңгыр-
лар явар, кешеләргә иген-
нәр вә җимешләр үсәр, һәр
җәһәттән иркен булыр, җи-
мешләр сыгып, шәраблар
ясарлар».
[50] Патша әйтте: «Ул төш юраучы
кешене зинданнан чыгарып
миңа китерегез!» Чакыручы
илче Йосыф янына килгәч,
Йосыф илчегә әйтте: «Баш
патшаңа кайтып әйт, ми-
не күреп кулларын кискән
хатыннарның миңа карата
фикерләрен белсен. Хатын-
нарның хәйләсе вә минем
хаксыз рәнҗетелгәнем ачык-
лансын өчен! Тәхкыйк, ми-
нем Раббым аларның хәйлә-
ләрен белә».
[51] Патша әйтте хатыннарны
җыеп: «Йосыф хакында фи-
керегез ничек, аның белән
якынлык кылырга теләгән
вакытыгызда гаеп аңардамы
яки сездәме?» Хатыннар әйт-
теләр: «Аллаһ сакласын, без
Йосыфта бер явызлык та күр-
мәдек, ул пакьтер. Газиз ха-
тыны Зөләйхә әйтте, менә
хәзер хаклык өскә чыкты,
Йосыфның миңа якынлык
кылуын мин үзем эстәдем,

кодрәтемдә түгел. Фиргавенгә хәерле җавапны Аллаһы Үзе ирештерер... <...>

26 Җиде симез сыер — ул җиде ел димәктер; җиде тук башак та — җиде ел ул. Мәгънәләре бер үк.

27 Соңыннан пәйда булган җиде ач-арык сыер һәм көнчыгыш җилләреннән куырылып беткән ач орлыклы җиде башак шулай ук җиде елны белдерә һәм җиде ел кытлык буласын хәбәр итә.

28 Менә шуның өчен мин: „Аллаһы фиргавенгә алда ни кыласын күрсәтеп бирде“, — дип әйттем дә.

29 Шулай, бөтен Мисыр җирендә җиде ел бөек муллык чоры булачак.

30 Аннан соң җиде еллык кытлык чоры башланачак, һәм Мисыр иле тәмам бөлгенлеккә төшеп, элекке муллык еллары онытылачак.

31 Кытлык чоры шулкадәр авыр булыр ки, ачка интегүдән илдәге элекке муллык бөтенләй хәтердән чыгачак.

### ***Йосыфның югары дәрәҗәгә ирешүе***

32 Төшнең фиргавенгә ике тапкыр кабатлануы исә Аллаһының әмере хак булуны күрсәтә. Тиздән Ул аны гамәлгә ашырачак.



әмма Йосыф хыянәт итмәде, аның сүзләре хак».

52 «Ул хатыннарның минем дөреслегем белән шәһадәт бирүләре — үзе юк чагында хатынына хыянәт итмәгәнлегемне Газиз белсен өчендер һәм хыянәтчеләрнең хәйләсен Аллаһ юлга салмаганлыгын белсеннәр өчен.

53 Әмма шулай булса да, нәфесемне дөресләмим, чөнки нәфес явызлыкка өндидер, мәгәр нәфес өндәгән явыз эшләрдән котылыр Раббым рәхмәт кылган кешеләр генә. Әлбәттә, минем Раббым ярлыкаучы вә рәхимле».

### ***Йосыфның югары дәрәҗәгә ирешүе***

54 Патша әйтте: «Китерегез миңа ул Йосыфны, үземә юлдаш итәргә аны төрмәдән чыгарырмын. Патша Йосыф белән сөйләшкәч, хакыйкать





33 Шунлыктан фиргавенгә, зирәк акыллы бер адәм табып, аны Мисыр җирләре өстеннән идарәче итеп кую мәслихәттер.

34 Фиргавен мәмләкәтнең бөтен өлкәләренә назыйрлар куйсын. Алар уңдырышлы җиде ел дәвамында Мисыр җирендә җитештерелгән бар азык-төлекнең биштән бер өлешен җыеп барсыннар.

35 Шул муллык елларында һәртөрле икмәктән җыелган азык-төлек нәрсәсе шәһәрләргә — фиргавен карамагындагы саклык урыннарына туплансын.

36 Бу азык-төлек, саклык мал буларак, Мисыр җирләренә ябырылачак җиде еллык кытлык чоры ихтыяҗына, ягъни мәмләкәтне ачлык һәлакәтеннән коткару өчен калдырылсын».

37 Бу мәслихәт фиргавенгә вә аның барлык хезмәтчеләренә хуш килде.

38 Фиргавен үзенең барлык хезмәтчеләренә: «Аллаһының Рухын үзендә йөрткән мондый кешене тагын кайдан табарга мөмкин?!» — дип әйтеп куйды.

39 Йосыфка исә фиргавен: «Аллаһы сиңа боларның һәммәсен ачып биргән икән, димәк, синдәй зирәк акыллы адәм бүтән юктыр, — диде. —



хәлне белгәч әйтте: «Бүген син имин булганың хәлдә безнең янда торырсың».

55 Йосыф әйтте: «Мине игенчелек эшләренә хуҗа итеп куй, әлбәттә, мин игеннәрне үстерә һәм саклый беләмен, яхшы саклармын».

57 Әнә шулай Йосыфка Мисыр җирендә иркенлек бирдек, ул җирдә кайда теләсә шунда урнашыр. Рәхмәтебезне теләгән кешеләребезгә шулай бирәбез, изге гамәлләр кылучыларның әҗерен һич җуймабыз.

40 Син минем ил-йортымның
идарәчесе булырсың. Бөтен
халкым синең сүзне тыңлап
эш итәр. Синнән тик минем
тәхетем генә бөегрәк булыр.
41 Менә, мин сине бөтен Мисыр
җирләре өстеннән идарәче
итеп куям!» — дип, сүзен бе-
терде фиргавен.
42 Шулай дип, фиргавен, үзенең
бармагыннан мөһер йөзеген
салып, аны Йосыфның бар-
магына кигезде; аңа нәфис
җитеннән тегелгән киемнәр
бирде, муенына алтын чыл-
быр муенса такты.
43 Аны үзенең икенче дәрәҗә
арбасына утыртырга кушты.
Юлда барганда, Йосыфны
«Юл бирегез!» дигән сүзләр
белән каршылап һәм озатып
калырга тиешләр иде. Шул
рәвешчә, фиргавен Йосыфны
бөтен Мисыр җирләре өс-
теннән идарәче итеп куйды.
44 Йосыфка фиргавен: «Мин
фиргавеннең сүзе: бөтен
Мисыр мәмләкәтендә синең
рөхсәтеңнән башка һичкем
кулын да, аягын да селкет-
мәс!» — диде.
45 Фиргавен Йосыфка Саф-
нат-Панеах дип исем кушты,
аңа Он шәһәренең каһине
Поти-Пераның кызы Асенат-
ны хатынлыкка алып бирде.
Йосыф шулай бөтен Мисыр
җирләре буйлап сәяхәтен
башлады.







46 Мисыр патшасы фиргавен
хозурына килгәндә, Йо-
сыф утыз яшьтә иде. Фир-
гавен хозурыннан киткәч,
ул бөтен Мисыр җирлә-
рен аркылыга-буйга йөреп
чыкты.
47 Җиде ел муллык чорында туф-
ракка чәчелгән һәр орлык
бөртегеннән кушучлап уңыш
алынды.
48 Җиде ел эчендә Йосыф,
Мисыр җирендә җитеш-
кән һәртөрле игеннән мул
уңыш җыеп, шәһәрләр-
нең саклык урыннарына
азык-төлек туплады; аерым
шәһәр тирәсендәге басулар-
дан җыелганны шул шәһәр
эчендәге амбарларга сал-
дырды.
49 Тупланган ашлык диңгез ко-
мыдай шулкадәр күп иде ки,
ахырда Йосыф аның исәбен
үк югалтты. <...>
56 Ачлык бөтен җирләрне биләп
алгач, Йосыф, азык-төлек
амбарларын ачтырып, ми-
сырлыларга икмәк сата баш-
лады. Әмма кытлык Мисыр
төбәкләрендә дә көчәйгән-
нән-көчәя барды.
57 Менә, бөтен илләрдән кеше-
ләр Йосыфтан икмәк сатып
алырга Мисырга агыла баш-
лады. Чөнки ачлык афәте
бөтен җир йөзен каплап ал-
ган иде.

**Яратылыш 42**

1 Ягъкуб, Мисырда икмәк барлыгын белеп, угылларына: «Сез нәрсә бер-берегезгә карашып торасыз? – диде.

2 Аннары: – Мисырда, әнә, икмәк бар дип ишеттем. Исән калыйк, үлмик дисәк, шунда барып, икмәк сатып алып кайтыгыз», – дип өстәде.

3 Шулай итеп, Йосыфның ун кардәше, икмәк сатып алыр өчен, Мисырга юнәлде.

4 Әмма Ягъкуб Йосыфның энесе Беньяминне агалары белән бергә җибәрмәде, ул-бу булмагае дип курыкты.

### *Йосыф белән агаларының очрашуы*

5 Мисырга икмәк сатып алырга килүчеләр арасында әнә шулай Исраилнең угыллары да бар иде. Чөнки Кәнган җирендә дә ачлык хөкем сөрә иде.

6 Йосыф исә, Мисырның баш түрәсе сыйфатында, килгән бар халыкка икмәк сата иде. Йосыфның хозурына килгәч, ун кардәше итагать белән аңа баш иделәр.

7 Йосыф үзенең агаларын бер күрүдә үк таныды, әмма таныганлыгын сиздермәде һәм алар белән бик кырыс сөйләште. Сорады: «Сез кайдан килдегез?» – диде. Тегеләр: «Без Кәнган җиреннән,



### *Йосыф белән агаларының очрашуы*

58 Ачлык еллары башлангач, Йосыфның агалары Кәнган шәһәреннән Мисырга ашлык алырга килделәр, ашлык сорар өчен Йосыф янына керделәр, Йосыф аларны таныды, әмма агалары Йосыфны танымадылар...

59 Йосыф аларга сәфәр җиһазларын хәзерләп һәрберсенә бер дөя йөге ашлык биргәч әйтте: «Атагыз янында калгач кече кардәшегезне миңа алып килегез. Күрәсез бит, мин үлчәүне хыянәтсез, гадел үлчимен һәм мөсафирләрне кабул итүчеләрнең хәерлесемен.





икмәк сатып алырга килдек», – диделәр.

8 Йосыф үзе агаларын таныса да, тегеләр аны танымадылар.

9 Йосыф, агалары турында төшендә күргәннәрне хәтеренә төшереп, аларга: «Сез – шымчылар! Сез монда мәмләкәтнең шәрә урыннарын карарга килгәнсез!» – диде.

10 «Юк, әфәндебез, – диделәр кардәшләре. – Без, синең колларың, монда икмәк сатып алырга дип килдек.

11 Без – бер ата балалары, намуслы кешеләр, без колларыңның беркайчан шымчылык иткәннәре юк!»

12 Йосыф: «Түгел! – дип кисте. – Сез монда мәмләкәтнең шәрә нокталарын күзәтергә килгәнсез!»

13 Кардәшләре: «Без, синең колларың, Кәнган җирендәге бер кешенең угыллары булабыз, абыйлы-энеле уникe туган. Иң кече энебез әтиебез янында калды, ә бер энебез инде юк», – диделәр.

14 «Әйтәм бит, сез монда шымчы булып килгәнсез! – дип кабатлады Йосыф. –
15 Шуңа күрә сез сынау үтәргә тиеш. Фиргавеннең гомере белән ант итәм: кече энегез монда китерелгәнгә кадәр, сез моннан беркая да китә алмаячаксыз!



60 Әгәр ул кардәшегезне алып килмәсәгез, миндә сезнең өчен ашлык булмас һәм миңа якын да килмәгез!»

61 Әйттеләр: «Ярый, атасыннан сорарбыз аны, әлбәттә, без ул эшне эшли алабыз вә эшләрбез».

62 Йосыф үзенең хезмәтчеләренә әйтте: «Боларның ашлык өчен биргән акчаларын үзләренә белдермичә йөкләренә яшереп куегыз, өйләренә кайткач ул акчаларны, шаять, табып һәм танып алырлар һәм шул акчалары белән, шаять, янә минем яныма ашлык алырга килерләр». Һәм хезмәтчеләр шулай эшләделәр.

16 Арагыздан берегез, өегезгә кайтып, энегезне монда алып килсен. Калганнарыгыз монда тотык булып калыр. Сөйләгән сүзләрегез хакмы, түгелме икәне менә шунда ачыкланыр. Энегезне алып килмисез икән, ул чакны, фиргавеннең гомере белән ант итәм, сез чыннан да шымчылар булып чыгасыз!»
17 Шулай дип, Йосыф аларны өч көнгә сак астына куйды.
18 Өченче көнендә аларга әйтте: «Исән каласыгыз килсә, мин әйткәнне эшләрсез, чөнки мин Аллаһыдан куркам.
19 Әгәр намуслы кешеләр икәнсез, арагыздан кем дә булса берегез тотык булып монда калсын, ә башкаларыгыз ачлыктан иза чиккән гаиләләрегез өчен моннан икмәк алып китәр.
20 Ә инде сүзегезнең хаклыгын исбатларга һәм үлемнән котылып калырга теләсәгез, кече энегезне минем хозурыма китерегез». Кардәшләр күнделәр. <...>
25 Аннан соң тагын әмер биреп, кардәшләренең йөк капчыкларына икмәк тутыртты, юлда ашарларына өлеш чыгарып, икмәк бәһасе өчен алынган көмешне һәркайсының капчыгына кире салып куярга кушты. Барысы да Йосыф кушканча эшләнде.







***Йосыф кардәшләренең өйләренә кайтып китүе; аларның кабат Мисырга әйләнеп килүе***

26 Кардәшләр, үзләренең икмәкләрен ишәкләргә төяп, кайтыр юлга чыктылар.
27 Төн кунарга туктаган җирдә кардәшләрнең берсе, ишәгенә азык бирү өчен, капчыгын чиште һәм, капчык авызында ук үзенең икмәк сатып алганда түләгән көмеш акчаларын күреп,
28 кардәшләренә: «Менә, минем көмешем үземә кире кайтты, капчыгымның авызында ята!» – диде. Курку-аптыраудан һәммәсенең йөрәге кысылып килде. Тетрәнә-тетрәнә, алар бер-беренә: «Аллаһының безгә күрсәткән бу хикмәтләре нәрсәне аңлата икән?» – диештеләр.
29 Кәнган җиренә, Ягъкуб янына кайткач, алар үз башларыннан үткән барлык бу хәлләрне аталарына сөйләп бирделәр. <...>
35 Капчыкларны бушата башлагач, гаҗәп хәл: аларның һәркайсының капчыгыннан көмеш акча янчыгы килеп чыкты. Үзләренең бу көмеш акчалы янчыкларын күргәч, һәммәсе – угыллар да, аталары Ягъкуб та – тәмам куркуга төштеләр.



***Йосыф кардәшләренең өйләренә кайтып китүе; аларның кабат Мисырга әйләнеп килүе***

63 Аталарына кайткач әйттеләр: «Ий атабыз, безгә хәзер Мисырдан ашлык сатып алу тыелды, ягъни ашлык хуҗасы, кече кардәшегез Биняминне алып килмәсәгез, сезгә ашлык бирмим, диде. Биняминне безнең белән җибәр, ашлык алып кайтырбыз һәм Биняминне сакларбыз».
64 Аталары әйтте: «Бинямин хакында мин сезгә ничек ышаныйм? Моннан элек Йосыф хакында ышандым да, ә нәрсә эшләдегез? Шуның өчен аны сезгә бирмим, саклау йөзеннән Аллаһ хәерледер, Аңарга тапшырдым вә Ул – шәфкать итүчеләрнең иң шәфкатьлерәге».
65 Йөкләрен ачкач, ашлык өчен биргән акчаларын йөкләрендә таптылар – үзләренә кире кайтарылган. Әйттеләр: «Ий атабыз, ялган сөйләмибез, ошбу акча – ашлык өчен биргән акчабыз кире үзебезгә кайтарылган, Биняминне безнең белән җибәр, Мисырга барыйк, өй җәмәгатьләребезгә ашлык алып кайтырбыз һәм Биняминне дә сакларбыз, әгәр Бинямин дә барса, бер дөя йөге

36 Аталары Ягъкуб угылларына әйтте: «Сез мине угылларымнан мәхрүм иттегез: Йосыф юк, Шимун юк! Инде менә Беньяминне дә алып китәргә телисез. Моның бар авырлыгы минем башка төшәчәк!» – диде.

37 Атасы Ягъкубка җавап биреп, Рубин әйтте: «Беньяминне кире алып кайтмасам, минем ике углымны үтер! – диде. – Беньяминне миңа ышанып тапшыр, мин аны сиңа һичшиксез кире алып кайтачакмын!»

38 Ләкин Ягъкуб:
«Углымны сезнең белән җибәрмәячәкмен! – диде. – Абыйсы үлгәч, ул минем берүзе калды. Әгәр барыр юлыгызда бер-бер хәл була калса, хәсрәт-кайгыдан сез минем чал башымны гүргә кертәчәксез бит!»

**Яратылыш 43**

1 Илдә ачлык көчәйгәннән-көчәя барды.

2 Мисырдан алып кайткан икмәк тотылып беткәч, Ягъкуб үзенең угылларына: «Мисырга барып, аннан тагын бераз икмәк сатып алып кайтыгыз», – диде. <...>

ашлыкны артык алырбыз, ашлык хуҗасы вәзир өчен бер дөя йөге бик аз нәрсә, авырсынмас – бирер».

66 Аталары әйтте: «Әлбәттә, Биняминне сезнең белән җибәрмен, сәламәт кайтарып үземә тапшырырга Аллаһ исеме белән ант итеп вәгъдә биргәнегезгә чаклы». Биняминне сәламәт алып кайтып тапшырырга вәгъдәләрен биргәч аталары әйтте: «Безнең сөйләшкән сүзләребезне Аллаһ күзәтүчедер».

67 Аталары әйтте: «Ий угылларым, Мисырга җиткәч барыгыз да бер капкадан кермәгез, төрлегез төрле капкалардан керегез! Аллаһудан килгән бәла-каза хакында берни белергә дә, сезгә ярдәм итәргә дә хәлемнән килмидер, һәр эш өстеннән хөкем йөретмәк Аллаһуга хастыр, шуңа баш июдән башка чара юк, мин Аллаһуга тәвәккәл иттем һәм тәвәккәл итүчеләр Аллаһуга гына тәвәккәл итсеннәр!»

68 Алар Мисырга житеп, аталары әйткәнчә, төрлесе төрле капкадан кергән заманда аталары Ягъкубның сүзе аларга Аллаһудан килгән каза хакында һич файда бирмәде, мәгәр Ягъкубның күңелендәге теләге генә үтәлде, тәхкыйк, ул – Без өйрәткән нәрсәләрне белүче, шуның





***Йосыфның агаларны сынавы***

15 Ягъкубның угыллары, әлеге бүләкләрне төяп һәм кулларына икеләтә күбрәк көмеш акча алып, Беньямин белән бергә Мисырга таба юл чыктылар һәм, Мисырга барып житкәч, Йосыф хозурына килделәр.

16 Араларында Беньяминне дә күргәч, Йосыф үз өенең мөдиренә: «Бу кешеләрне минем өйгә алып кайт. Аяклы малдан кирәк кадәр хайван суеп, табын әзерлә, чөнки төшкелекне мин бүген бу кешеләр белән бергә ашармын», – диде.

17 Мөдир, хуҗасы кушканча, кардәшләрне Йосыфның өенә алып китте.

18 Кардәшләр үзләрен Йосыфның өенә алып китүләреннән тәмам каушап калганнар иде. «Теге чакны без түләгән көмеш акчаны капчыкларыбызга кире салып җибәрү белән бәйле эш инде бу! – диештеләр алар. – Йортына алып кайткач, безгә һөҗүм итеп, бездән кол ясарга, ишәкләребезне алып калырга тели, күрәсең!»

өчен балаларын шулай вәгазь кылды, ләкин күп кешеләр белмиләр эшнең яшерен серләрен.

***Йосыфның агаларны сынавы***

69 Бар да җыелып Йосыф янына керделәр... һәм Йосыф Бинямингә үзен танытты, мин синең кардәшең Йосыфмын, дип кочаклады вә, кардәшләрең безгә кылган начарлыклары өчен кайгырмагыл, Аллаһ безне ташламады, диде.

70 Агаларының нәрсәләрен хәзерләгәч, ягъни ашлыкларын үлчәп дөяләргә йөкләгәч, Йосыф Биняминнең йөгенә бер алтын савытны яшереп куйдырды, вә шул хәлдә юлга чыгып киттеләр, соңра Йосыфның хезмәтчеләреннән берсе артларыннан барып: «Ий кәрван кешеләре! Сез патшаның савытын урлагансыз», – дип кычкырды.

71 Йосыфның агалары кычкыручыга каршы килеп: «Нәрсә югалттыгыз?» – дип сорадылар.

72 Әйттеләр: «Патшаның савытын югалттык, аны табып китергән кешегә бер дөя йөге ашлык бирелә вә ул ашлыкны тапшырырга мин өстемә аламын».

19 Йосыфның өй капкасы янына килеп җиткәч, туктап, алар мөдиргә сүз куштылар.

20 Әйттеләр: «Хуҗабыз әфәнде, — диделәр, — без инде элек тә монда икмәк сатып алырга бер килгән идек.

21 Кайтыр юлда төн кунарга туктап, капчыкларыбызны чишеп җибәрсәк, күрдек ки, без түләгән көмеш акча һәркайсыбызның капчыгы авызында ята. Без бу көмеш акчаларны тулысы белән сезгә кире алып килдек.

22 Кулыбызда тагын икмәк сатып алыр өчен алып килгән башка көмешебез дә бар. Теге юлы капчыкларыбызга көмешне кем салган булгандыр, без белмибез».

23 Мөдир әйтте: «Тыныч булыгыз: куркырга урын юк, — диде. — Капчыкларыгызда табылган ул хәзинәне сезгә, мөгаен, үз Аллагыз, атагызның Алласы насыйп иткәндер. Теге юлы сез түләгән көмешне мин тулысынча алдым». Шулай дип, мөдир алар янына Шимунны алып чыкты.

24 Аннан соң кардәшләрне Йосыфның өенә алып керде, аякларын юарга су китерде, ишәкләренә азык бирде.

25 Кардәшләр өйлә вакытына Йосыф кайтышка үзләренең бүләкләрен әзерләп



73 Әйттеләр: «Үзегез беләсез, валлаһи, без Мисыр җиренә бозыклык кылырга килмәдек һәм без караклар да түгелбез».

74 Артларыннан килүчеләр әйттеләр: «Әгәр, урламадык, дигән сүзегез ялган булса, ягъни савыт сездән табылса, урлаучының җәзасы нинди булыр?»

75 Әйттеләр: «Аның җәзасы шул булыр ки, савыт кем йөгеннән табылса, шул кеше үзе патшага кол булыр. Залимнәргә без, мөселманнар, шундый җәза бирәбез. Йөкләрен тентү өчен барын да борып Йосыф алдына алып килделәр.

76 Йосыф Биняминнән башка кардәшләренең йөкләреннән башлады тентүне, соңра савытны Бинямин йөгеннән табып алды. Шулай итеп Бинямин, урлаган исемен күтәреп, Йосыф кулында калды. Кардәшен алып калыр өчен Без Йосыфка шулай хәйлә кылдырдык, Мисыр патшасының дине хөкеменчә, Йосыф кардәшен алып калырга кадир түгел иде... Үзебез теләгән кешене гыйлем вә хикмәт белән дәрәҗәләргә күтәрербез, һәр белем иясе кешедән өстен белемле кеше булыр.







куйдылар. Төшкелекне ашау монда булачагын аларга инде хәбәр иткәннәр иде.

26 Йосыф кайткач, алар аның янына керделәр һәм, башларын җиргә кадәр иеп, алып килгән бүләкләрне Йосыфка тапшырдылар.

27 Кардәшләреннән хәл-әхвәл белешкәннән соң, Йосыф: «Сез сөйләгән карт әтиегез исән-иминме, сәламәт яшиме әле?» — дип сорады.

28 «Атабыз, синең колың, сау-сәламәт, исән-имин яши», — дип җавап бирделәр Йосыфның кардәшләре һәм, янә сәҗдәгә китеп, башларын җиргә ордылар.

29 Күзләрен йөртеп һәм үзенең бертуган энесенә, әнисенең төпчек углы Беньямингә тукталып, Йосыф: «Сез миңа сөйләгән кече энегез шушымы инде? — дип сорады, аннары өстәп: — И углым, Аллаһы сиңа карата миһербанлы булсын!» — диде.

30 Туган энесенә булган мәхәббәт хисләреннән күңеле тулып, Йосыфның күзләренә яшь тыгылды, һәм ул, эчке бүлмәгә кереп, шунда күз яшьләрен түкте.

31 Аннары, күзен-битен юып һәм ныгаеп, янәдән туганнары янына чыкты да: «Ашарга китерегез!» — дип боерды.



77 Кардәшләре әйттеләр: «Бинямин урласа урлар шул, аларда ул гадәт бар, моннан элек аның кардәше Йосыф та урлаган иде». Йосыф аларның сүзләренә җавап бирмичә күңелендә саклады вә күңеленнән әйтте, сез Йосыфка караганда яманраксыз, сезнең миңа ялган ялалар япканыгызны Аллаһу Тәгалә белә.

32 Йосыфның аш табыны үзе-
нә аерым, кардәшләренеке
үзләренә аерым, шулай ук
Йосыф хезмәтендәге мисыр-
лыларның да ашау табыны
аерым куелган иде. Чөнки
мисырлыларга гыйбриләр
белән бергә утырып ашарга
ярамый, мисырлылар өчен
бу мәкруһ санала иде.
33 Йосыф каршысында кардәш-
ләре яшь буенча — өлкәнен-
нән кечегә таба тезеп утыр-
тылганнар иде. Алар тирән
бер гаҗәпсенү белән бер-бер-
сенә карашып алдылар.
34 Йосыф аларга ризык артын-
нан ризык җибәрттерә тор-
ды. Беньямин алдына ку-
елган азык абыйларының
һәркайсыныкына караганда
биш өлеш артыграк иде. Шу-
лай ашап-эчеп, алар Йосыф
хозурында хуш вакыт ки-
черделәр.

**Яратылыш 44**

1 Йосыф үзенең йорт мөдиренә
әмер биреп әйтте: «Бу адәм-
нәрнең капчыкларына үзлә-
ре күтәрә алган кадәр икмәк
тутыр, — диде. — Түләгән
көмешләрен дә һәркайсы-
ның капчыгы авызына са-
лып куй.
2 Ә иң кечесенең капчыгына,
икмәк өчен түләгән акчасы
белән бергә, минем менә бу
көмеш касәмне дә урнаш-
тыр». Мөдир үз хуҗасының







әмерен җиренә җиткереп
үтәде.
3 Иртәгесен, яктыргач, кардәш-
ләргә, ишәкләрен алып, юлга
чыгарга рөхсәт ителде.
4 Алар шәһәрдән чыгып җи-
тәр-җитмәс, Йосыф үзенең
мөдиренә: «Бар, артларына
төш! — диде. — Куып җитеп,
аларга әйт: „Ни өчен сез ях-
шылыкка яманлык белән
җавап бирдегез? 5 Хуҗа әфән-
демнең шәраб эчә торган,
шул ук вакытта фал да ача
торган касәсен урлап кит-
кәнсез? Бик тә начар эш бу!“»
6 Мөдир, юлчыларны куып җи-
теп, әлеге сүзләрне кабат-
лады.
7 Аңа җавап биреп, юлчылар
әйттеләр: «Хуҗабыз әфәнде
нигә әле безгә шундый сүз-
ләр сөйли? — диделәр. — Юк,
без, синең колларың, андый
нәрсәне эшли алмыйбыз.
<...>
9 Без колларыңның берәрсендә
урланган нәрсә табылса, аңа
үлем булсын, калганнарыбыз
исә хуҗабыз әфәндегә кол
булып калыйк!»
10 Мөдир: «Яхшы, сез әйткәнчә
булсын, — диде. — Касә кем-
дә табылса, ул кеше — миңа
кол, калганнарыгыз исә азат
булыр».
11 Юлчылар йөкләрен тиз генә
җиргә төшереп, һәркайсы үз
капчыгының авызын чиште.

12 Мөдир кардәшләрнең өлкәненнән башлап кечесенә кадәр һәммәсенең капчыгын тикшереп чыкты. Касә Беньямин капчыгыннан табылды.

13 Кардәш туганнар кайгыдан өс-башларын ерттылар һәм, йөкләрен ишәкләренә төяп, шәһәргә кире әйләнеп кайттылар.

### *Беньяминны тоткын итеп калдыру*

14 Яһүдә үзенең кардәшләре белән бергә Йосыфның өенә килеп кергәндә, Йосыф өйдә иде әле. Кардәшләр аның каршысында йөзтүбән җиргә капландылар.

15 «Сез үзегезнең ни кылганыгызны беләсезме? — диде Йосыф аларга. — Миндәй кешеләрнең фал ачу белән дә шөгыльләнгәнен сез, әлбәттә, белергә тиеш идегез».

16 «Син әфәнде алдында акланыр өчен, без ни әйтә алыйк та, нәрсә аңлата алыйк?! — диде Яһүдә. — Аллаһы синең колларыңда гаеп тапты. Инде менә капчыгында касә табылган кардәшебез дә, аның белән бергә без дә — һәммәбез синең колларың булабыз».

17 Ләкин Йосыф: «Юк, мин андый эшкә бармаячакмын, — диде. — Капчыгында касә табылган кеше миндә кол



### *Йосыфның кече туганы — тоткын*

78 Йосыфка әйттеләр: «Ий газиз, аның өйдә карт атасы бар, аның урынына безнең берebезне алып кал, аны җибәр! Тәхкыйк, без сине игелек кылучы дип беләбез».

79 Йосыф әйтте: «Аллаһ сакласын урламаган кешене алып калудан, савытны кем йөгеннән таптык, фәкать шул кешене генә алып калабыз, башка кешене алып калсак, залимнәрдән булырбыз».

80 Биняминне алудан өметсез булгач, аулакта киңәш итәр өчен аерылып чыктылар. Олугълары әйтте: «Беләсезме, Биняминне сәламәт кулына тапшырырга атагыз сездән Аллаһ исеме белән гаһед алды, вә моннан элек Йосыф хакында чиктән тыш кылган идегез инде, ни күзебез белән вә ни битебез белән атабызга кайтып күренербез? Мисыр







булып калыр, ә калганнарыгыз исән-имин килеш атагыз янына кайтып китәрсез».

18 Яһүдә, Йосыфка таба якынрак килеп: «Әфәндем, колыңа сүз әйтергә рөхсәт ит! — диде. — Сүзем өчен колыңа ачуың кабармасын, чөнки син үзең дә фиргавендәй кешесең.

19 Син әфәндем теге чакны без колларыңнан: „Атагыз яки тагын берәр кардәшегез бармы?“ — дип сорадың.

20 Син әфәндегә без сөйләп бирдек: „Карт атабыз белән аның картлык көнендә туган тагын бер углы — безнең иң кече энебез бар, — дидек. — Кече энебезнең бер анадан туган абыйсы да бар иде, тик ул үлде дә, кече энебез берүзе калды. Атабыз аны бик тәярата“, — дидек.

21 Син исә без колларыңа әйттең: „Аны минем янга алып килегез, үз күзләрем белән күрим“, — дидең. <...>

30 Хәзер синең колың, безнең атабыз янына әйләнеп кайтып, яныбызда кече энебез булмаса, кече углының җаны белән үз җанын бер күреп яшәгән

31 атабыз, төпчек углының юклыгын абайлап, шундук егылып үләчәк, һәм без шулай итеп атабызның кайгылы чал башын гүргә илтеп тыккан булабыз.



җиреннән бер адым да атламыймын, ягъни кайтмыймын атамнан кайтырга рөхсәт булганга чаклы яки Бинямин хакында Аллаһудан бер хәерле хөкем булганчы, Ул — Аллаһ — хәкимнәрнең хәерлесе»...

81 Йосыф әйтте: «Атагыз янына кайтыгыз, аңа әйтегез: ий атабыз, угълың бер савыт урлады, без фәкать белгәнебез һәм күргәнебез белән шәһадәт бирәбез ки, Биняминнең йөгеннән бер алтын савыт чыкты, без гаепне белә алмыйбыз.

82 Безгә ышанмасаң, без булган Мисыр шәһәре кешеләреннән сорагыл һәм безгә очраган вә хәлләребезне күргән кәрван кешеләреннән сорагыл! Без, әлбәттә, бу сүзләрне дөрес сөйлибез».

83 Аталары әйтте: «Юк, дөрес сөйләмисез, бәлки нәфесегез бер яман эшне яхшы итеп күрсәткәндер дә, ә сез ул эшне Биняминга япкансыз, инде миңа күркәм сабырлык лязимдер. Аларның барчасын Аллаһ миңа китерер дип өмет итәмен. Шиксез, Аллаһу Тәгалә аларның кайда икәнен белә һәм белеп хөкем йөртә».

84 Ягъкуб г-м ачуланып алардан китте вә әйтте: «Йосыфым өчен ни олугъ хәсрәт!» Вә

32 Мин, синең колың, кече энемне исән-имин сакларга атам каршында үз өстемә җаваплылык алдым, атама: „Әгәр аны сиңа кире алып кайтмасам, мин гомерем буе синең алда гаепле булырмын“, — дидем.
33 Шуңа күрә мин, синең колың, үтенәмен: энем урынына кол итеп монда мине калдыр, ә ул үзенең абыйлары белән берлектә атабыз янына кайтсын.
34 Юкса энемнән башка миңа атам янына ничек кайтмак кирәк?! Аның афәтле язмышын күрер өченме?»

*Агаларына Йосыфның үзен танытуы*

**Яратылыш 45**
1 Йосыф, күңелендә ташыган уй-хисләрдән үз-үзен тыя алмыйча, янында басып торган чит кешеләргә: «Чыгып китегез моннан!» — дип кычкырды. Шунлыктан, үзен кардәшләренә танытканда, аның янында читләрдән инде бер кеше дә юк иде.
2 Ул каты тавыш белән елап җибәрде, аның елаган тавышын хәтта мисырлылар да ишеттеләр, хәбәре исә шундук фиргавен йортына да барып җитте.
3 «Мин — Йосыф! — дип белдерде ул кардәшләренә. — Әтием

каты хәсрәт белән Йосыф өчен елап, ике күзенә ак төшеп сукыраймыш иде, шулай булса да, һичкемгә зарланмады, сабыр итте.
85 Әйттеләр: «Ий атабыз, валлаһи, син һаман Йосыфны сөйлисең, болай булсаң аның өчен сырхау булырсың яки һәлак булырсың!»
86 Аталары әйтте: «Тәхкыйк, мин кайгымны вә сагышымны Аллаһуга шикаять кыламын, сезгә түгел, Аллаһ белдерүе белән мин сез белмәгән нәрсәләрне беләмен».

*Агаларына Йосыфның үзен танытуы*

88 Алар, Мисырга барып, Йосыф янына кереп әйттеләр: «Ий газиз! Безгә вә өй җәмәгатьләребезгә бик каты ачлык иреште, менә сезгә төрле акчалар китердек, саф көмештән генә китерергә көчебез җитмәде, акчабызга карата безгә ашлык үлчәп бир һәм мөмкин булса садака итеп тә бир... Әлбәттә, Аллаһ садака бирүчеләргә изге җәзалар бирер...»
89 Әйтте: «Беләсезме, хәтерегездәме? Йосыфка вә аның кардәше Бинямингә җаһиллек белән ниләр кылдыгыз?»





исән-саумы?» Ләкин кардәшләре авыз ачып сүз әйтә алмадылар, чөнки алар тәмам аптырап калганнар иде.
4 «Миңа якынрак килегез», — диде Йосыф. Кардәшләре якынлашкач: «Сезнең тарафтан Мисырга сатылган Йосыф мин! — дип өстәде. —
5 Ләкин мине монда сатып җибәрүегез өчен хәсрәт чигеп, үкенеп газапланмагыз. Чөнки сез инсаннарның гомерләрен саклап калу өчен, Аллаһы мине монда сездән алданрак күндерде.
6 Җир йөзендә инде менә ике ел кытлык хөкем сөрә. Алда тагы биш елы бар. Ул биш ел эчендә чәчү дә, уру да булмаячак.
7 Аллаһы сезнең нәсел-токымнарыгызны җир йөзендә калдырыр өчен һәм җаннарыгызны бөек афәттән йолып алыр өчен, алдан ук күндерде мине монда!
8 Димәк, мине монда җибәрүче сез түгел, ә Аллаһыдыр! Аллаһы мине монда фиргавенгә киңәшче ата, аның бөтен ил-йорты белән идарә итүче хуҗа, бөтен Мисыр мәмләкәте җирләренә хөкемдар итеп кылды!
9 Тизрәк атам янына кайтыгыз да аңа, улың Йосыф болай диде, диегез: „Аллаһы мине бөтен Мисыр мәмләкәте

90 Сорадылар: «Син әллә Йосыфмы?» Йосыф әйтте: «Әлбәттә, мин Йосыфмын, ошбу минем кардәшем Бинyaминдер, тәхкыйк, Аллаһ безгә нигъмәт вә дәрәҗәләр бирде. Берәү, Аллаһуга тәкъвалык кылып, башына килгән бәла-казаларга сабыр итсә, әлбәттә, Аллаһ яхшы эшләрнең әҗерен җуймый».
91 Куркып калтырап әйттеләр: «Ий Йосыф, валлаһи, сине Аллаһ безгә ихтыярлы вә баш кылды, шиксез, без хаталанучылардан булдык».
92 Йосыф әйтте: «Бүген сезне гаепләп битәрләү юк, мин сезне хөкем итмим. Кылган гөнаһларыгызны Аллаһ ярлыкасын, Ул бик шәфкатьле вә рәхимле!
93 Минем ошбу күлмәгемне алып атамның йөзенә ябыгыз, шуннан соң атамның күзләре ачылыр, күрә башлар, вә атамны һәм барча җәмәгатьләрегезне җыеп Мисырга минем хозурыма килегез!»
94 Угылларның кәрваны Мисырдан чыгып киткәч, аталары Ягъкуб Кәнгандә әйтте: «Әгәр, картлыгыннан саташып сөйли, дип гаепләмәсәгез, мин сезгә бер хәбәр әйтәм ки, мин Йосыф угълымның исен сизәмен, исән икән».

җирләренә хөкемдар кылды; вакытны сузмыйча, яныма килеп җит!
10 Син Гөшен җирләрендә яшәрсең; үзең дә, угылларың да, угылларыңның балалары да, мал-туар көтүләрең һәм кул астындагы бар нәрсәң минем янәшәмдә булырсыз.
11 Йортың-гаиләң бөлмәсен өчен, мин барысын эшләрмен, сине монда карап-ризыкландырып торырмын. Чөнки әле тагын биш ел кытлык дәвам итәчәк“.
12 Барыгыз алдында, энем Беньяминнең күз алдында сезгә мин әйткән, минем авызымнан чыккан сүзләр бу!
13 Атама сез минем Мисырда нинди шөһрәт казануымны, үзегез күргәннәрнең бөтенесен сөйләп бирегез һәм атамны тизрәк монда алып килегез!» <...>
21 Исраилнең угыллары нәкъ шулай эшләргә булдылар. Фиргавеннең әмерен үтәп, Йосыф үзенең кардәшләренә арбалар бирде, юл өчен җитәрлек азык-төлек белән тәэмин итте.
22 Һәркайсына, алыштырып кияр өчен, бер кат кием бирде... <...>
24 ...Йосыф аларга: «Юлда гауга чыгармагыз!» — дип калды.
25 Йосыфның кардәшләре шулай, Мисырны калдырып,



95 Янындагылар әйттеләр: «Валлаһи, син искечә һаман Йосыф белән саташасың, белеп сөйләмисең».
96 Кәрван Кәнган җиренә кайтып җиткәч, күлмәкне кулына тотып, шатлыклы Йосыф хәбәрен китерүче бер углы, атасы янына кереп, күлмәкне атасының йөзенә куйды, һәм атасының күзләре ачылды, күрә торган булды. Шулвакыт Ягъкуб г-м әйтте: «Мин сезгә әйтмәдемме Аллаһ белдерүе белән сез белмәгән нәрсәләрне беләмен дип?»
97 Угыллары әйттеләр: «Ий атабыз! Тәхкыйк, без хаталык кылдык вә гөнаһлы булдык, инде безне гафу ит! Һәм безнең өчен Аллаһудан ярлыкау өстәгел!» Аталары әйтте: «Әлбәттә, мин сезнең өчен Аллаһудан истигъфар кылырмын. Тәхкыйк, Ул — Аллаһ — ярлыкаучы вә рәхмәт итүче».
99 Барып җитеп Мисыр шәһәренә кергәндә Йосыф каршы алды һәм ата-анасын кочаклады вә әйтте: «Һәр бәла-казадан имин булган хәлдә, Алла теләсә, Мисыр шәһәренә керегез!»
100 Йосыф үзенең мәнзилендә ата-анасын хөрмәтләп тәхеткә утыртты, аннары Йосыфны зурлап шөкер йөзеннән





Кәнган җиренә, аталары Ягъкуб янына әйләнеп кайттылар.
26 Ягъкубка:
«Йосыф исән! — дип белдерделәр. — Ул хәзер бөтен Мисыр мәмләкәтенең хөкемдары!» — диделәр.

***Ягъкуб гаиләсенең Мисырга күченүе***

26 Ягъкуб тораташтай катып калган иде, угылларының сүзләренә аның ышанасы килмәде.
27 Угыллары аңа, Йосыфның бөтен әйткән сүзләрен кабатлап, аңлатырга тырыштылар. Бары шуннан соң һәм, үзен Мисырга алып китәр өчен, Йосыф җибәргән арбаларны күргәч кенә, аталары Ягъкубка җан керде.

**Яратылыш 46**

1 Ягъкуб, үзенең бар мал-мөлкәтен алып, юлга чыкты. Беер-Шебада туктап, атасы Исхакның Алласына багышлап, корбаннар китерде.



барчасы сәҗдәгә егылдылар, вә Йосыф әйтте: «Ий атам, күп еллар элек күргән төшемнең тәэвиле ошбудыр, тәхкыйк, Раббым бу төшемне дөрес кылды вә, тәхкыйк, Раббым миңа ихсан кылды, мине зинданнан чыгару белән вә сезне сахрадан Мисырга китерү белән минем белән кардәшләрем арасында шайтан вәсвәсә белән дошманлыкны салганы соңында, тәхкыйк, Раббым теләгән нәрсәсен шәфкать белән кылучы; әлбәттә, Ул белүче вә тиешенчә эш кылучы.

***Ягъкуб гаиләсенең Мисырга күченүе***

101 Йа Раббым! Син миңа Мисыр байлыгын бирдең вә төш юрауны өйрәттең. Йа Раббым, Син җир вә күкләрне яратучысың, дөньяда һәм ахирәттә Син миңа ярдәмчесең. Йа Раббым, мөселман хәлемдә җанымны ал һәм мине изге кешеләргә тоташтыр!»
102 Ий Мөхәммәт г-м, бу Йосыф кыйссасы сиңа гаиб хәбәрләрдән, Без аны сиңа вәхи кылабыз; Йосыфның кардәшләре хәйлә кылып Йосыфны коега салырга киңәш иткән вакытларында син алар янында юк идең...

2 Төнлә исә Исраилнең күз
алдында Аллаһы күренеп:
«Ягъкуб! Ягъкуб!» — дип өн
салды. «Мин тыңлыйм!» —
дип җавап бирде Ягъкуб.
3 Аллаһы әйтте: «Мин — Алла-
һы, атаңның Алласымын! —
диде. — Курыкма, Мисырга
күчеп кит! Мин анда синнән
бөек бер халык тудырачак-
мын.
4 Мин Мисырга синең белән
бергә барам. Соңра сине ан-
нан алып чыгучы да Мин
булырмын. Йосыф үз кулла-
ры белән синең күзләреңне
йомдырыр». <...>
28 Ягъкуб, Яһүдәне Йосыф яны-
на җибәреп, Гөшенгә бару
юлын алдан белешеп куй-
ган иде. Алар Гөшенгә килеп
җитәрәк,
29 Йосыф та, арбасын җиктереп,
атасы Исраилне каршылар
өчен, Гөшенгә килде. Атасын
күргәч ул, атлыгып, аның
муенына барып сарылды һәм
кочагында бик озак үксеп
елады.
30 «Инде үләргә дә була: йөзеңне
күрдем, син исән!» — диде
Исраил Йосыфка.
31 Йосыф үзенең кардәшләренә
һәм атасының өй җәмәгате-
нә болай диде: «Мин, барып,
фиргавенгә хәбәр ирештe-
рим: „Кәнган җирләрендә
яшәгән кардәшләрем белән
атамның бөтен өй җәмәгате



103 Ләкин син никадәр тырыш-
саң да, күп кешеләр иман
китермәсләр.
104 Иман китерүләре өчен син
алардан дөнья малын сора-
мыйсың, ул Коръән барча
галәм (өчен) вәгазьдән башка
нәрсә түгел.
105 Җирдә вә күкләрдә күпме
галәмәтләр бар — Аллаһуның
барлыгына һәм берлегенә
шуларны күреп-үтеп йөри-
ләр, ләкин гыйбрәтләнүдән
баш тарталар, һич игътибарга
алмыйлар.
106 Аларның күбрәге иман ки-
термәсләр, мәгәр иман ки-
терсәләр, кемне яки нәрсәне
дә булса Аллаһуга тиңдәш
кылып мөшрик булырлар.
107 Әйә алар имин булырлар-
мы Аллаһуның көйдергүче
газабы аларга килүдән яки
искәрмәстән кыямәт көне
килүдән имин булырлармы?
108 Ий Мөхәммәт г-м! Әйт: «Бу
Коръән күрсәткән юл — ми-
нем юлымдыр, мин шул юл
белән күреп-белеп кешеләрне
Аллаһуга чакырамын һәм
миңа ияргән мөэминнәр шул
юл белән барып, күреп-белеп
кешеләрне Аллаһуга чакы-
ралар, вә Аллаһу Тәгаләне
һәр кимчелектән пакь дип
беләмен һәм мин мөшрик-
ләрдән түгелмен».
109 Синнән элек җибәргән
пәйгамбәрләребез дә үз





минем янга күчеп килде-
ләр“, — дип әйтим».
32 Аңа сезнең сарык асраучы-
лар, көтүчеләр булуыгызны
аңлатыйм. „Алар вак һәм эре
терлектән барлык мал-ту-
арларын, булган бар мөл-
кәтләрен үзләре белән алып
килделәр“, — дип әйтим».

**Яратылыш 47**

2 Кардәшләреннән бишесен Йо-
сыф үзе белән алып килгән
иде, аларны фиргавен хозу-
рына кертеп бастырды.
3 Йосыфның кардәшләреннән
фиргавен: «Шөгылегез ни-
дән гыйбарәт?» — дип сора-
ды. Йосыфның кардәшләре:
«Ата-бабаларыбыз кебек, без
колларың да көтүчеләр, са-
рыклар асрыйбыз», — дип
җавап бирделәр. <...>
7 Йосыф үзенең атасы Ягъкубны
да фиргавен хозурына алып
килде. Ягъкуб фиргавенгә
хәер-фатихасын бирде. <...>
11 Йосыф шулай атасы Ягъкуб
белән үзенең кардәшләрен
Мисырга урнаштырды; фир-
гавеннең боерыгында әй-
телгәнчә, аларга илнең иң
яхшы өлешеннән — Рәмесес
төбәгеннән җир биләмәсе
бирде.
12 Атасы Ягъкубны, үзенең кар-
дәшләрен һәм Ягъкуб токы-
мындагы һәр гаиләне бала-
лары санынча Йосыф икмәк
белән тәэмин итте.



шәһәрләреннән ирләрдер.
Без аларга аятьләребезне
вәхи кыладыр идек. Югый-
сә фәрештә түгел иделәр.
Әллә алар җир өстендә сә-
яхәт кылып йөрмиләрме?
Әгәр йөрсәләр, күрер иде-
ләр әүвәлге кяферләрнең
ахыры ничек булганын.
Иман китереп Аллаһуга
тәкъвалык кылган кеше-
ләргә ахирәт йорты хәерле-
дер, әллә шуны аңлый ал-
мыйсызмы?
110 Хәтта ки әүвәлге пәйгамбәр-
ләр, өммәтләренең иманга
килүләреннән өметләрен
өзсәләр вә кяферләрнең,
болар пәйгамбәр түгелләр,
ялганчылар, дигәннәрен
белсәләр, ул пәйгамбәрләр-
гә Безнең ярдәмебез килер
булды, теләгән кешеләре-
безне һәлакәттән коткарыр-
быз, вә кяферләргә Безнең
газабыбыз килсә, һич кире
кайтарылмас.
111 Сөйләнгән ошбу Йосыф г-м
кыйссасында, әлбәттә, га-
кыл ияләренә гыйбрәтләр
бар. Коръән — Аллаһ исе-
меннән сөйләнгән ялган
сүз түгел, әлбәттә, Алла-
һу Тәгаләнең Үзенең сүзе,
Үзеннән элек индерелгән
китапларны дөресләп ин-
дергән хак китаптыр вә
һәрнәрсәнең хөкемен бә-
ян итеп индерелмештер; вә

13 Ул арада кытлык, көчәеп, шул дәрәҗәгә җитте ки, бөтен өлкәләрдә икмәкнең әсәре дә калмады. Мисыр һәм Кәнган җирләре тәмам зәгыйфьләнеп-корып киптеләр. <...>

***Ягъкубның вафаты һәм аның васыяте***

20 Шул рәвешчә, Йосыф Мисырдагы җир мәйданнарын да фиргавен өчен сатып ала башлады. Һәрбер мисырлы ачлык кытлыгыннан үзенең җир кисәген сатты. Илдәге бөтен җир мәйданы шулай фиргавеннеке булды. <...>

27 Исраил токымы шулай Мисыр мәмләкәтенең Гөшен өлкәсендә җир биләп яши башлады. Шунда алар, үрчеп, нәселләрен ишәйттеләр.

**Яратылыш 48**

21 Аннары, Йосыфка мөрәҗәгать итеп: Инде мин үләм, – диде Ягъкуб. – Әмма Аллаһы сезнең янда калачак. Ул сезне ата-бабаларыгыз туфрагына кире кайтарачак.

22 Кардәшләреңнекеннән аермалы буларак, мин сиңа өстәмә таулы җир биләмәсе – Шәкемне калдырам, заманында мин аны амориләрдән ук-җәям һәм кылычым белән яулап алган идем.

**Яратылыш 49**

1 Ягъкуб, угылларын янына җыеп, әйтте: «Бирегә җыелыгыз,



иман китергән кешеләргә һидаять һәм рәхмәт булсын өчен индерелде.

***Ягъкубның вафаты һәм аның васыяте***

**2 сүрә**

131 Ибраһим г-мгә Раббысы әйтте: «Аллаһуга итагать итеп чын мөселман бул!» Ибраһим г-м әйтте: «Бөтен галәмнәрне тәрбияләүче Аллаһуга итагать итеп чын мөселман булдым», – дип.

132 Ибраһим г-м угылларына васыять әйтте һәм әмер бирде: «Ий угылларым, шиксез, Аллаһ сезгә ислам динен ирекле итте. Дөрес һәм ныклап Аллаһ динен тотыгыз! Динегез була торып, кяфер булмагыз, мөселман булып яшәп, мөселман булып үлегез!» Ягъкуб г-м дә угылларына шул ук сүзләрне әйтте...

133 Ий яһүдләр! Ягъкуб пәйгамбәр үлер алдында сез аның янында идегезме? Ул сезгә сез әйткән сүзләрне әйттеме? Юк, әйтмәде. Менә ул угылларын җыеп әйтте: «Мин үлгәннән соң нәрсәгә гыйбадәт кылырсыз?» Угыллары әйтте: «Син үлгәч синең илаһыңа вә аталарың Ибраһим, Исмәгыйль, Исхакларның ила-





сезне ниләр көтәсен әйтә-
чәкмен! 2 Җыелыгыз, Ягъ-
кубның угыллары, атагыз
Исраилнең сүзен колак са-
лып тыңлагыз!» <...>

29-30 Ягъкуб, үзенең угылларына боерыклар биреп, болай диде: «Озакламый мин халкымның ата-бабалары белән кушылачакмын. Мине ата-бабаларым янына – Кәнган җиренә, Мәмре янындагы Махпела кырында урнашкан мәгарәгә алып кайтып дәфен кылыгыз. Ул мәгарәне, каберлек өчен, шул кыр белән берлектә бабам Ибраһим хосусый милек итеп хитти Эфроннан сатып алган иде.

31 Анда Ибраһим белән бергә аның җәмәгате Сара, Исхак белән аның җәмәгате Рәбика дәфен кылынган. Хатыным Лияне дә мин шунда дәфен кылдым.

32 Электә андагы бу кыр һәм мәгарә хиттиләр кулында иде.

33 Ягъкуб, үзенең угылларына җиткерәсе боерыкларын, васыятьләрен әйтеп бетереп, ятагына сузылып ятты һәм, җан тәслим кылып, үз халкының ата-бабалары белән кушылды.

**Яратылыш 50**

12 Ягъкубның угыллары шулай аталары әйтеп калдырган



һына гыйбадәт кылырбыз, Ул – Аллаһ – тиңдәше юк, бер генә илаһтыр. Без – Аңа буйсынучы мөселманнарбыз».

134 Зекер ителгән пәйгамбәрләр һәм аларның өммәтләре дөньядан үтеп киттеләр, кәсеп иткән сәваблары һәм гөнаһлары үзләренә. Сезнең дә кәсеп иткән сәвабларыгыз һәм гөнаһларыгыз үзегезгәдер. Аларның эшләгән эшләреннән соралмассыз.

**40 сүрә**

32 Ий кавемем, өстегезгә кыямәт көненең килүеннән куркамын, ул көндә кешеләр кычкырышырлар.

33 ...сезне Аллаһ газабыннан саклаучы да булмас, Аллаһ бирәүне хак юлдан адаштырса, аны туры юлга кертүче, әлбәттә, булмас.

34 ...элек могҗизалар белән Йосыф пәйгамбәр килде, ләкин сез аның китергән хак могҗизаларыннан даим шикләнүче булдыгыз, ул үлгәч хәтта, Йосыфтан соң Аллаһ пәйгамбәр җибәрмәс, дидегез. Сезне адаштырган кеби, Аллаһ ачык дәлилләрне күрә торып аны инкяр итүчене вә чиктән үтүчене хак юлдан адаштырыр.

боерык-васыятьне җиренә
җиткереп үтәделәр. <...>
15 Аталары вафатыннан соң,
Йосыфның кардәшләре,
үзара кайгырышып: «Әгәр
Йосыф, безгә кинә тотып,
эшләгән бөтен явызлыкларыбыз
өчен бездән үч алырга
теләсә, нишләрбез?» —
диештеләр.
16 Һәм Йосыфка хәбәр күндерделәр:
«Вафаты алдыннан
атабыз үзенең васыятендә
болай дип боерды:
17 „Йосыфка әйтегез: кардәшләрең
сиңа күп явызлыклар
эшләсә дә, син аларның гаеп
һәм гөнаһларын кичер“.
Инде син безләрне — атаң
табынган Аллаһының колларын
кичерә күр», — диделәр.
Бу хәбәрне ишеткәч, Йосыфның
күзләре яшькә манчылды.
<...>
19 Йосыф: «Курыкмагыз, мин
Аллаһы урынында түгел
бит! — дип җавап бирде аларга. —
20 Сез миңа яманлык эшләргә
теләгән булсагыз да, Аллаһы
сез теләгән яманлыкны яхшылыкка
әверелдерде: менә,
күрегез, күпме халыкның
тормышы, исәнлеге саклап
калынды.
21 Шуңа күрә курыкмагыз!
Сезне дә, балаларыгызны
да карап-ризыкландырып





торырмын». Шулай дип, Йосыф
үзенең кардәшләрен тәмам
тынычландырды, аларның
күңелләренә хуш килердәй
сүзләр сөйләде. <...>
26 Йосыф йөз дә ун яшендә вафат
булды.

## Муса

***Исраил халкы Мисыр коллыгында***

**Чыгыш 1**

6 Йосыф үзе... һәм әлеге буынның барлык кешеләре дә үлеп бетә,

7 ә исраилиләр үрчеп-ишәеп, аларның саны арттаннан-арта бара. Шул рәвешле, алар бөтен Мисыр җире буйлап тараалалар.

8 Вакытлар үтеп, Мисыр тәхетенә Йосыф турында берни белмәүче патша килә.

9 Үзенең халкына ул болай дип әйтә: «Карагыз, исраилиләр бездән күбрәк тә һәм безгә караганда көчлерәк тә!

10 Безгә, бик әйбәт уйлап, алар белән нәрсәдер эшләргә кирәк. Югыйсә исраилиләр, тагын да ишәеп, яу-фәлән булган очракта, дошманнарыбызга кушылып, безгә каршы сугышырга һәм бездән аерылып китәргә мөмкиннәр».

11 Шуңа күрә мисырлылар, исраилиләрне авыр эш белән интектерү максатыннан, алар өстеннән назыйрлар билгеләделәр һәм, фиргавенгә мал-мөлкәт туплау өчен, Питом һәм Рәмесес шәһәрләрен төзергә мәҗбүр иттеләр.

12 Әмма мисырлылар исраилиләрне нинди генә



## Муса

***Исраил халкы Мисыр коллыгында***

**28 сүрә**

3 Без сиңа Муса белән фиргавен хәбәрләреннән хаклык белән укыйбыз иман китергән кавемнәр өчен.

4 Дөреслектә, фиргавен Мисыр җирендә олугъланды, дәхи Мисыр халкын үзенең хезмәтендә төрле дәрәҗәләргә бүлде, алардан Ягъкуб балаларын хурлар иде, кыз балаларын калдырып, ир балаларын бугазлатыр иде, ул фиргавен күп бозыклык кылучы фасикъләрдан булды.

5 Фиргавен кулында изелгән Ягъкуб балаларын коткарып, аларга рәхмәт итәргә һәм аларны имамнар итәргә, һәм дә фиргавен байлыгына варислар итәргә теләдек.

6 Янә фиргавенгә, Һәмәнгә һәм аларның гаскәрләренә үзләре курыккан Мусаны күрсәтергә теләдек һәм аларны яхшы җиргә урнаштырырга теләдек...

**7 сүрә**

127 Фиргавен кавеменнән олылары әйттеләр: «Ий фиргавен! Мусаны вә аның кавемен җир өстендә бозыклык кылсыннар һәм сиңа вә сынымнарыңа гыйбадәт кылуны куйсыннар өчен





авырлыкларга дучар итсәләр дә, тегеләр арттаннан-арта гына бардылар һәм ил буйлап һаман күбрәк таралдылар. Мисырлылар исраилиләрдән тагын да ныграк курка башладылар,

13 шуңа күрә, һич кызганмыйча, аларны эшләргә мәҗбүр иттеләр.

14 Мисырлылар, алардан балчык издереп, кирпеч суктырып, кырлардагы бөтен эшләрен эшләтеп, тормышларын аяныч хәлгә төшерделәр — исраилиләр нинди генә эштә булмасын, аларга карата миһербансыз кыландылар.

15 Шифра һәм Пуга исемле гыйбри кендек әбиләренә Мисыр патшасы болай диде:

16 «Гыйбри хатын-кызларга бала табарга ярдәм иткәндә, яңа туган сабыйның нинди җенестән булуын карагыз: ир бала булса — үтерегез, кыз бала туса — калдырыгыз!»

17 Әмма кендек әбиләре Аллаһыдан курка һәм Аны хөрмәт итә иделәр, шуңа күрә Мисыр патшасы әмерен тыңламадылар — ир балаларны исән калдыра бардылар.

18 Мисыр патшасы, кендек әбиләрен үз янына чакыртып: «Ни өчен сез болай эшлисез? Ни өчен яңа туган ир балаларны исән калдырасыз?» — дип сорады.



аларны калдырасыңмы? Ягъни үтерергә кирәк», — диделәр. Фиргавен әйтте: «Тиздән кыз балаларын калдырып ир балаларын үтерербез, без, әлбәттә, алардан өстенбез, көчлебез», — дип.

19 Кендек әбиләре фиргавенгә: «Гыйбри хатын-кызлар Мисыр хатын-кызлары кебек түгел, алар тазалар һәм, без барып җиткәндә, балаларын инде тудырган булалар», — дип җавап кайтардылар.

20-21 Кендек әбиләре Аллаһыдан курыкканга һәм Аны хөрмәт иткәнгә күрә, Ул аларга игелек күрсәтте — гаиләле итте. Исраилиләр исә арткаnnан-арта барды.

22 Ахыр чиктә, фиргавен үзенең барлык халкына әмер бирде: «Гыйбриләрнең яңа туган ир балаларын Нил елгасына ташлагыз, ә кыз балаларын исән калдырыгыз».

*Мусаның туувы*

**Чыгыш 2**

1 Леви ыругыннан булган бер ир шул ук ыругтан бер хатынга өйләнде.

2 Хатын, балага узып, ир бала тапты һәм, матурлыгына сокланып, аны өч ай яшереп асрады.

3 Алга таба да баласын яшереп тоту мөмкин булмагач, ул, камыш кәрзин алып, аны сумала белән сылады да шуңа сабыен салды, аннары кәрзинне елга буендагы камышлар арасына куйды.

4 Сабыйның апасы исә, аның белән нәрсә булыр икән дип, ерактан күзәтеп торды.

ТӘҮРАТ

*Мусаның туувы*

**28 сүрә**

7 Мусаның анасына «балаң Мусаны имез, әгәр үтерүләреннән курыксаң, Мусаны Нил дәрьясына сал, батар дип курыкма һәм кулыңнан китүенә кайгырмагыл, Без аны сиңа кайтарачакбыз вә аны пәйгамбәрләрдән кылачакбыз» дидек...

8 Фиргавен җәмәгате, таң аткач, Мусаны дәрьядан табып алды — бармагын имеп ятадыр иде; Аллаһ бу эшне эшләде Муса фиргавенгә дошман һәм кайгы булсын өчен. Дөреслектә, фиргавен һәм аның вәзире Һәмән вә

КОРЪӘН





5 Бераздан фиргавен кызы елгага су коенырга килде... Кыз, камыш арасындагы кәрзинне күреп, бер хезмәтчесенә аны алып килергә кушты.

6 Кәрзинне ачуга, фиргавен кызы, анда елап яткан сабыйны күреп, аны бик кызганды. «Бу — гыйбри бала», — диде ул.

7 Сабыйның апасы, фиргавен кызы янына килеп: «Сабыйны күкрәк сөте белән туендырырга һәм аны тәрбияләргә бирәр гыйбри хатынны табып китеримме?» — дип сорады.

8 «Бар, китер», — диде фиргавен кызы. Сабыйның апасы китте һәм баланың анасын алып килде.

9 «Бу сабыйны ал да миңа аны имезеп үстереп бир, — диде фиргавен кызы...

10 Бала үсә төшкәч, ул аны фиргавен кызына бирде; ә кыз исә аны үз баласы кебек кабул итте. Ул аңа Муса дигән исем кушты һәм әйтте: «Чөнки мин баланы судан үзем тартып чыгардым», — диде.

ТӘҮРАТ

аларның гаскәрләре үзләренең башларына җитәчәк Мусаны тәрбияләп үстерү белән хаталык кылдылар, бу эшнең ахырын белмәделәр.

9 Фиргавен хатыны фиргавенгә әйтте: «Бу бала минем дә, синең дә күз нурыбыз булыр, аны үтермәгез, чөнки шул вакытта аны үтерергә теләгәннәр иде. Шаять, безгә файда итәр яки без аны үзебезгә бала итеп алырбыз». Ләкин алар бу эшнең ахырын белмәделәр.

10 Мусаның фиргавен кулына төшкәнен белгәч, анасының күңеле кайгыдан бушанды. Хәтта Муса үзенең угълы икәнлеген белдерергә якын булды, Безнең вәхигә ышанучы булсын өчен күңеленә иман куәтен салмасак, әлбәттә, алданыр иде.

11 Мусаның анасы баланың туган апасы Мәрьямгә әйтте: «Муса артыннан бар, бәлки берәр хәбәр алып кайтырсың». Мәрьям Мусаның сандыгы кая китүен ерактан күрде, әмма фиргавен җәмәгате берсе дә бу эшне белми иделәр.

12 Вә Без... имезүче хатыннарны имүдән Мусаны тыйдык; күп хатыннарны алып килделәр Мусаны имезергә, ләкин (бала) берсен дә кабул итмәде. Мәрьям фиргавеннәргә

КОРЪӘН

***Мусаның Мисырдан качып китүе***

11 Үсеп җиткәч, Муса бервакыт үз халкы арасына чыкты һәм аның авыр хезмәт башкаруын күрде. Шунда ул бер мисырлының үз халкы кешесен — гыйбрине кыйнавын күреп алды.

12 Як-ягына карады да, беркем дә юклыгын күргәч, әлеге мисырлыны, үтереп, комга күмеп куйды.

13 Икенче көнне Муса ике гыйбринең сугышуын күрде. Рәнҗетүчедән сорады: «Син нигә үзеңнең якыныңны кыйныйсың?» — диде.

әйтте: «Әйә мин сезгә бер өйнең җәмәгатен күрсәтимме, ул хатын сезнең өчен баланы имезеп тәрбияләр; һәм ул җәмәгать балага яхшы нәсыйхәт бирүчеләрдер», — дип...

13 Мусаны анасына кайтардык, баласын күреп күзе шатлансын һәм көенмәсен һәм дә Аллаһуның вәгъдәсе хак икәнне белсен өчен, ләкин күбрәк кешеләр Аллаһуның эше вә вәгъдәсе хак икәнне белмиләр.

14 Муса үсеп, куәткә җитеп, гакылы вә буе тигезләнгәч, ул Мусага шәригать хөкемнәрен һәм белем бирдек, әнә шулай Безгә итагать иткәннәргә изге җәза бирәбез.

***Мусаның Мисырдан качып китүе***

17 Янә әйтте: «Ий Раббым, мине ярлыкаганың өчен мине саклагыл, кяферләргә ярдәмче булмасам иде».

18 Соңра Муса Мисыр шәһәрендә курыккан хәлдә, миңа ни була инде дип, хөкем көтеп калды; кичә... Мусадан ярдәм сораган кеше... янә Мусадан ярдәм сорады. Муса ярдәм сораучыга әйтте: «Син ачык бер азгын кеше икәнсең, кичә бер кешене миннән үтерттең, бүген дәхи үтертмәкче буласыңмы?»





14 Ә анысы: «Безнең өстән сине башлык һәм хөкемче итеп куйдылармы әллә?! Мисырлыны үтергән кебек, мине дә үтерергә телисеңме?» — диде. Муса курка калды, «Минем нәрсә эшләгәнемне барысы да белә икән», — дип уйлады.

15 Мусаның нәрсә эшләгәнен белгәч, фиргавен аны үтерергә теләде, ә Муса исә, фиргавеннән качып, Мидьян җиренә юл тотты. Анда ул бер кое янына килеп утырды.

16 Мидьянда бер каһиннең җиде кызы бар иде; алар, аталарының сарыкларын сугару өчен, әлеге кое янына килделәр дә улакларга су тутырдылар.

17 Әмма берничә көтүче, килеп, кызларны куып җибәрде. Муса исә, урыныннан торып, кызларны яклап чыкты һәм аларның терлекләренә су эчерде.

18 Кызлар өйләренә кайткач, аталары Регуил алардан: «Нигә бүген иртә кайттыгыз?» — дип сорады.

19 Кызлары аңа: «Көтүчеләр безне куарга теләгән иде, әмма ниндидер бер мисырлы яклап калды, хәтта безгә су алып бирде һәм сарыкларыбызга эчерде», — дип җавап кайтарды.

19 Мусага да вә Мусадан ярдәм сораучыга да дошман булган кыбтыйны Муса тотарга теләгәч, кыбтый әйтте: «Ий Муса, мине үтерергә телисеңме, бит кичә бер кешене үтергән идең, син Мисыр җирендә кеше үтереп залим булырга телисең, әмма төзәтүчеләрдән булырга теләмисең».

20 Бер ир шәһәр уртасыннан бик ашыгып Муса янына килде һәм әйтте: «Ий Муса, кыбтыйлар сине үтерергә киңәш итәләр, син бу шәһәрдә торма, чык, мин сиңа яхшы киңәш бирүчеләрдәнмен».

21 Артымнан куа чыгарлар дип курка-курка Муса шәһәрдән чыкты: «Ий Раббым, мине фиргавеннең залим кавеменнән коткар», — диде.

22 Муса Мәдйән шәһәренә юнәлде, ләкин юлны белмидер иде, әйтте: «Шаять, Раббым Мәдйәнгә бара торган юлга күндерер», — дип.

23 Мәдйәннең кое суына җиткәндә ул кое янында хайваннарны эчерүче бер җәмәгатьне күрде, дәхи аларның артында ике хатынны күрде, алар хайваннарына су эчерми иделәр, Муса әйтте: «Ни булды сезгә, хайваннарыгызга су эчермисез?» Ул ике кыз әйттеләр: «Алдыбыздагы көтүчеләр хайваннарыны

[20] Кызларына Регуил: «Кайда ул кеше? Сез аны нишләп калдырдыгыз? Чакырыгыз, безнең белән бергә ашап алсын», — диде.
[21] Муса бу кешедә калырга риза булды, һәм Регуил үзенең Сиппора исемле кызын Мусага кияүгә бирде.
[22] Сиппора, балага узып, ир бала тапты, һәм Муса аңа Гершом дигән исем бирде. Шушы чит-ят җирдә үзе килмешәк булганга күрә, углын ул шулай атады.
[23] Күп вакытлар узды. Мисыр патшасы үлде, ә исраилиләр авыр эштән зар еладылар, сыкрандылар. Аларның фөрьядлары Аллаһыга барып иреште.
[24] Аллаһы аларның сыкрануларын ишетте һәм Ибраһим, Исхак, Ягъкуб белән төзегән килешүен исенә төшерде —
[25] Исраил халкының газап чигүен күреп, аларны кызганды.



эчереп китмичә без эчермибез, һәм безнең атабыз бик карт кешедер, шул сәбәпле хайваннарны эчерергә чыга алмый». Коеның чиләге бик зур булу сәбәпле кызлар коедан су ала алмыйлар иде, фәкать башка көтүләрдән калган суны эчерәләр иде.
[24] Муса коедан су тартып кызларның куйларына су эчерде, соңра китеп күләгәгә утырды һәм әйтте: «Ий Раббым, миңа диндә изгелектән биргән нәрсәң өчен мин фәкыйрь булдым, ашарыма юк», — дип...
[25] Ул ике кызның бере оялып кына йөрегәне хәлдә Муса янына килде, атам сине чакырадыр безнең куйларны эчертүеңнең хакын бирмәк өчен, диде. Муса кызларның атасы Шөгаеб пәйгамбәр янына килгәч, башыннан кичкән вакыйгаларны сөйләде. Шөгаеб әйтте: «Ий Муса, курыкма, залим кавемнәрдән бүген котылдың».
[26] Ике кызның берсе әйтте: «Ий атам, бу кешене хакын түләп көтүчелеккә ал, тәхкыйк, син хак түләп алган кешеләрнең хәерлесе, куәтлесе һәм әманәтле булганыдыр»...
[27] Шөгаеб әйтте: «Мин ошбу ике кызның берсен сиңа никахламакны телим, куйларымны сигез ел көтүең бәрабәренә.







***Аллаһның Мусага Исраил халкын Мисырдан алып чыгарга боеруы***

**Чыгыш 3**

[1] Муса үзенең кайнатасы — Мидьян каһине Итеронның вак терлекләрен көтә иде. Бервакыт ул, сарыкларын чүлгә алып китеп, Аллаһы тавы Хореб янына килеп чыкты.
[2] Шунда янып торган күгән
куагы эчендә аның алдында Раббы фәрештәсе пәйда
булды. Муса куакның януын, әмма һич янып бетмәвен күрде.
[3] Шулчак ул: «Ни
өчен куак дөрләп яна, әмма
янып бетми? Мин бу сәер
күренешне якынрак барып
карыйм әле», — дип уйлады.
[4] Раббы, Мусаның куакны карарга килүен күреп, куак арасыннан аңа: «Муса! Муса!» —



Әгәр ун елга тутырсаң, ансы синең изгелегеңнәндер, ун ел хезмәт ит, дип сине мәшәкатьләргә теләмим, вәгъдәдә торуда һәм йомшаклык кылуда, Аллаһ теләсә, мине изгеләрдән табарсың».
[28] Муса әйтте: «Ошбу шарт синең белән минем арабыздадыр, ике мөддәтнең кайсын гына үтәсәм дә, арттыру белән мине димләү булмасын яки золым итү булмасын, ошбу сөйләшүләребезгә Аллаһ шаһиттер».

***Аллаһының Мусага Исраил халкын Мисырдан алып чыгарга боеруы***

**20 сүрә**

[9] Сиңа Мусаның хәбәре килдеме?
[10] Хатыны белән юлда барганда караңгы кичтә еректа бер ут күрде, хатынына әйтте: «Мин ут күрдем, шул җирдә торыгыз. Шаять, мин ул җирдән яктыртучы ут алып килермен яки анда юл өйрәтүчеләрне табармын». Чөнки алар караңгыда юлларыннан адашкан иделәр.
[11] Ут янына килгәне заманда Аллаһ тарафыннан: «Ий Муса, — дип нида кылынды. —
[12] Синең Раббың, әлбәттә, Минмен, башмакларыңны сал, чөнки син Тува исемле мөкатдәс чокырдасың.

дип эндәште. «Мин мондамын», – дип җавап кайтарды Муса.
5 «Якын килмә, – диде Аллаһы, – аяк киемеңне сал, чөнки син басып торган урын – изгедер.
6 Мин – синең ата-бабаларыңның Алласымын; Ибраһим, Исхак һәм Ягъкубның Алласы!» Муса, Аллаһыга карарга куркып, йөзен каплады.
7 Раббы әйтте: «Халкымның Мисырда газап чигүен күрдем, назыйрларның җәбереннән ничек сыкрануын ишеттем. Мин әлеге халыкның ачы кайгысын беләм.
8 Шуңа күрә аны мисырлылар коллыгыннан азат итәргә дип индем: әлеге халыкны Мин, шул җирдән алып чыгып, иркен һәм уңдырышлы, сөт вә бал агып торган якларга алып барачакмын. Анда төрле халыклар: кәнганиләр, хеттиләр, амориләр, фәризиләр, хиввиләр һәм явүсиләр яши.
9 Әйе, Исраил халкының ялваруы Миңа иреште, шулай ук мисырлыларның аларны ничек изүен дә күрдем.
10 Менә Мин хәзер сине фиргавен янына җибәрәм. Бар һәм Минем халкымны – Исраил халкын – Мисыр җиреннән алып чык!»



13 Мин сине пәйгамбәрлеккә ихтыяр кылдым, сиңа вәхи ителмеш сүзләрне ишет!
14 Дөреслектә, Мин – Аллаһ, коллык кылырга яраклы Илаһ мәгәр Мин генә, Миңа гына гыйбадәт кыл вә Мине зекер итәр өчен намаз укы!
15 Тәхкыйк, кыямәт киләчәк, аның кайчан булачагын яшерүне телим, соңра, вакыт житкәч, кыямәтне булдырырмын, һәрбер кеше тырышып эшләгән изге эшенең яки явыз эшенең җәзасын алсын өчен».

**26 сүрә**

10 Раббың Мусага нида кылып әйтте: «Залим булган кавемгә бар...
11 Алар фиргавен кавемедер, алар мәхлукка табыналар, Аллаһудан курыкмыйлармы?»
12 Муса әйтте: «Йа Раббы, мине ялганга тотарлар дип куркамын.
13 Миңа ышанмаулары сәбәпле күңелемнең тараймаклыгыннан вә телемдә төен булу сәбәпле аңлата алмавымнан куркамын, миңа ярдәмче итеп кардәшем Һарунны җибәр!
14 Дәхи алар хозурында минем гөнаһым бар... үземне үтерерләр дип куркамын».
15 Аллаһ әйтте: «Юк, үтермәсләр, барыгыз икәү Минем аятьләрем белән, Без сезнең





11 Муса исә Аллаһыга болай диде: «Фиргавен янына барып, Исраил халкын Мисыр җиреннән алып чыгарга мин кем соң?!»
12 «Мин синең янәшәңдә булырмын! – диде Аллаһы. – Сине Мин җибәргәннең исбаты шул булыр: халыкны Мисыр жиреннән алып чыккач, сез, бу тауга килеп, Миңа табынырсыз!»
13 Муса исә: «Әгәр мин, барып, Исраил халкына: „Мине сезнең ата-бабаларыгызның Алласы җибәрде“, – дисәм, ә алар миннән: „Аның исеме ничек соң?“ – дип сораса, мин нәрсә дип җавап кайтарырмын? – диде.
14 Аллаһы Мусага болай дип җавап бирде: «Мин – Мәңге Булучы. Исраил халкына: „Сезнең янга мине Мәңге Булучы җибәрде“, – дип әйт».

**Чыгыш 4**

1 Шунда Муса: «Әгәр Исраил халкы миңа ышанмаса, сүземне тыңламаса, „Раббы синең алда пәйда булмады“ дисә, нәрсә эшләрмен?» – дип сорады.
2 Раббы Мусадан: «Синең кулыңда нәрсә ул?» – дип сорады. «Юл таягым», – дип җавап кайтарды Муса.
3 «Таягыңны җиргә ташла», – диде Раббы. Мусаның таякны җиргә ташлавы булды,



белән бергәбез, сүзегезне ишетәбез.
16 Фиргавенгә барыгыз вә, без бөтен галәмнәрне тәрбияләүче Аллаһуның рәсүлебез,
17 безнең белән Ягъкуб балаларын җибәрмәклегең өчен килдек», – диегез.

**20 сүрә**

19 Аллаһ әйтте: «Ий Муса, таягыңны ташлагыл җиргә».
20 Муса таякны җиргә ыргытты. Ул таяк җиргә төшү белән корсагында ашыгып йөрүче зур елан булды.
21 Аллаһ әйтте: «Ий Муса, бу еланны тотып ал, курыкма. Без аны әүвәлге халәтенә кайтарырбыз...
22 Инде уң кулыңны сул култык астына сук: ул кулыңны култыгыңнан чыгар – күзне чагылдыра торган булып, үзе зарарсыз булыр; галәмәт синең пәйгамбәрлегеңә икенче галәмәт булганы хәлдә.
23 Бу эшне кылдык синең пәйгамбәрлегеңә олугъ галәмәтне кешеләргә күрсәтмәклегебез өчен.
24 Фиргавен янына барып аны хак дингә өндәгел, ул чиктән тыш азды, хәтта: „Мин – илаһ“, – дия башлады».
25 Муса әйтте: «Йа Раббы, күкрәгемне киң кыл залимнәрнең каршылыгына сабыр итәргә.
26 Вә эшләремне миңа җиңел кыл.

таяк шундук еланга әверелде.
Муса еланнан читкә сикерде,
4 ләкин Раббы аңа: «Кулыңны
суз да еланны койрыгыннан
тотып ал», – диде. Мусаның,
кулын сузып, еланны койры-
гыннан тотып алуы булды,
елан аның кулында шундук
янә таякка әверелде.
5 Раббы әйтте: «Менә шулай эш-
лә, шул чагында кешеләр
ата-бабалары Раббы Алла-
сының, Ибраһим, Исхак һәм
Ягъкуб Алласының, синең
алда пәйда булуына ыша-
нырлар».
6 Раббы Мусага тагын шуны
әйтте: «Кулыңны куеныңа
тык». Муса кулын япанчасы
астына тыкты. Ә инде кире
чыгарганда, кулы йогыш-
лы тире авыруыннан кардай
агарган иде.
7 «Хәзер кулыңны яңадан ку-
еныңа тык», – диде Раббы,
һәм Муса янә кулын куе-
нына тыкты, ә кулын ки-
ре алганда, тәненең башка
урыннары кебек, ул сәп-сә-
ламәт иде.
8 Аннары Раббы: «Әгәр кешеләр
беренче могҗизага ышан-
масалар, икенче могҗизаны
күрсәткәч ышанырлар, – ди-
де. –
9 Әгәр инде ике могҗизага да
ышанмасалар һәм сине тың-
ламасалар, Нил елгасыннан
бераз су ал да җиргә түк;



27 Вә телемнән төенне чиш, сөй-
ләшүдә тотлыгуымны бетер.
28 Тыңлаган кешеләр сүземне
аңласыннар өчен...
29 Миңа үз әһелемнән бер яр-
дәмче бир.
30 Кардәшем Һарунны.
31 Аның белән минем куәтем-
не... ныгыт.
32 Вә миңа аны пәйгамбәрлек
эшемдә ярдәмче иптәш кыл.
33 Сиңа күп тәсбих әйтмәкле-
гебез өчен.
34 Вә Сине күп зекер итмәкле-
гебез өчен.
35 Тәхкыйк, Син безнең хәлләр-
не күреп беләсен».
36 Аллаһ әйтте: «Ий Муса! Тәх-
кыйк, сиңа сораган нәрсә-
ләрең бирелде.
37 Ий Муса, ошбулар сиңа икен-
че мәртәбә ингам итүебездер.
38 Беренче мәртәбә ингам итү-
без сиңа вәхи иткән нәрсәне
анаңа вәхи итүебез булды.
39 Сине табутка салып Нил дәрь-
ясына агызырга анаңа вәхи
иттек вә, зарар тидермичә
корыга чыгар, дип Нилгә
вәхи иттек Минем дошма-
ным вә Мусаның дошманы
фиргавен алсын өчен. Ий
Муса, Үземнән сиңа мәхәб-
бәт салдым ки, һәркем, хәтта
фиргавен сине сөйде, Минем
күз алдымда тәрбия ител-
мәклегең өчен».
40 ...Мусаны судан алгач, күк-
рәк сөтен имезү өчен күп





җиргә тиюгә, су шундук кан-
га әверелер».
10 Әмма Муса Раббыга әйтте: «И
Хуҗа-Хакимем! Мин элек тә
матур итеп сөйләми идем,
хәзер дә, Син Үзеңнең колың
белән сөйләшеп торганда да
шулай. Мин тотлыгучан һәм
сакаумын».
11 Раббы аңа әйтте: «Кешегә тел-
не кем бирә?! Кешене кем
телсез яки чукрак ясый ала?!
Кешене кем сукыр яисә күзле
итә?! Мин, Раббы, түгелме?!
12 Хәзер бар; син сөйләгәндә,
Мин сиңа ярдәм итәрмен һәм
нәрсә әйтергә кирәклегенә
өйрәтермен».
13 Муса исә Раббыга: «Әй Ху-
җа-Хакимем, зинһар өчен,
башка берәүне җибәр!» –
диде.
14 Шулчак Раббы ачуланып әйт-
те: «Леви ыругыннан Һарун
синең туганың түгелме?!
Мин аның сүзгә оста икә-
нен беләм. Ул инде сине кар-
шыларга чыкты һәм сине
күрүенә шат булыр.
15 Һарунга син нәрсә сөйләргә
кирәклеген әйтерсең. Нәрсә
сөйләргә кирәклеген Мин
сезгә әйтермен һәм нәрсә
эшләргә икәнен өйрәтермен.
16 Һарун исә синең урыныңа
халык белән сөйләшер. Ул –
синең авызың, ә син аның
өчен Аллаһы кебек булыр-
сың.



хатыннарны чакырып име-
зеп карадылар, ләкин Му-
са һичберсен кабул итмәде.
Шул вакытта Мусаның кыз
кардәше фиргавен йортына
килде, ул әйтте: «Бу сабыйны
тәрбияләп үстерү өчен яхшы
хатыннан хәбәр биримме?» –
дип. Соңра Мусаның анасын
алып килделәр. Муса, әлбәт-
тә, үз анасын кабул итте. Без
сине үз анаңа кайтардык,
сине күреп анаңның күзләре
карарлансын (шатлансын) вә
тынычланып кайгысы бет-
сен өчен. «Ий Муса, син бер
имансыз кыбтыйны үтердең,
бу эшеңнең җәзасын алудан
Без сине коткардык вә сине
төрле мәшәкатьләргә төше-
реп сынадык. Син Мәдйән
кавеме эчендә Шөгаеб пәй-
гамбәр янында ун ел тордың,
соңра пәйгамбәр булырга
тәгаенләнгән вакытта Ми-
сырга килдең, и Муса!
41 Тур тавына килгән вакытта
Мин сине пәйгамбәрлеккә
ихтыяр иттем.
42 Инде, ий Муса, үзең вә кар-
дәшең Һарун Мин биргән
могҗизалар белән фирга-
венне вә аның кавемен хак
дингә өндәргә барыгыз вә
Минем зекеремдә иренмә-
гез!
43 Вәгазьләр өчен икегез фир-
гавенгә барыгыз, чөнки ул
чиктән тыш азды.

17 Кешеләргә могҗизалар күрсәтү өчен, үзең белән юл таягыңны ал». <...>

19 Муса әле Мидьянда чакта ук Раббы аңа: «Мисырга кайт, сине үтерергә теләгән барча кешеләр инде үлделәр», – диган була. <...>

21 Аннары Раббы Мусага әйтте: «Мисырга кайткач, Минем кодрәтем белән тудырылган барлык могҗизаларны фиргавен алдында күрсәтергә онытма. Ә Мин аның йөрәгенә кирелек салырмын, һәм халыкка ул китәргә рөхсәт итмәс.

22 Фиргавенгә, Раббы болай дип әйтә, диген: „Исраил – Минем беренче углым;

23 Мин сиңа, углымны Миңа табынырга җибәр, дидем. Син җибәрмәдең, һәм хәзер Мин синең беренче углыңны үтерәчәкмен“». <...>

27 Раббы Һарунга: «Чүлгә Мусаны каршыларга бар», – диде. Шуннан Һарун китте һәм Аллаһы тавында Муса белән очрашты, күрүгә, Мусаны үбеп алды.

28 Муса аңа Раббы әйтергә кушкан барлык сүзләрне һәм нинди могҗизалар күрсәтергә боерганны сөйләп бирде.

29 Шуннан Муса белән Һарун исраилиләрнең барлык өлкәннәрен җыйдылар.



44 Фиргавенгә йомшак, яхшы сүзләр сөйләгез, шаять, вәгазьләнер яки Аллаһ газабыннан куркыр».

45 Әйттеләр: «Ий Раббыбыз, без куркабыз фиргавен ашыгып безгә газап бирер яки явыз эшне эшләвен арттырыр», – дип.

46 Аллаһ әйтте: «Ий Муса, курыкмагыз; әлбәттә, Мин сезнең белән, фиргавенгә сөйләгән сүзләрегезне ишетәмен һәм күрәмен, сезне саклармын.

47 Барыгыз, ул фиргавенгә әйтегез: «Без икебез дә сине хак дингә өндәү өчен җибәрелгән Раббы пәйгамбәрләребез. Ягъкуб балаларын безнең белән җибәр, аларны төрлечә газаплама. Без сиңа Раббыбыз тарафыннан күндерелгән рәсүлләр икәнлегебезгә могҗизалар белән килдек, Аллаһуның сәламе без күрсәткән хак юлга кергән кешеләргәдер.

48 Дөреслектә, Аллаһ газабы, пәйгамбәрләрне ялганга тотып, хаклыктан баш тарткан кешеләргә, дип безгә Аллаһудан вәхи килде».

49 Фиргавен әйтте: «Ий Муса! Сезнең Раббыгыз кем?»

50 Муса әйтте: «Безнең Раббыбыз Үзе халык кылган мәхлукларына һәрнәрсәне бирде, соңра Үзе биргән нәрсәләрдән





30 Раббының Мусага әйткән барлык сүзләрен Һарун халыкка җиткерде һәм алар алдында могҗизалар кылды.

31 Кешеләр Муса белән Һарунга ышандылар; аларның газапларын Раббының күрүен һәм Раббының аларны кайгыртуын белгәч, исраилиләр Раббыга баш иделәр, сәҗдә кылдылар.

**Чыгыш 5**

1 Муса белән Һарун, фиргавен янына барып, менә нәрсә диделәр: «Исраилнең Раббы Алласы сиңа: „Минем хөрмәткә бәйрәм ясасыннар өчен, халкыма чүлгә чыгарга рөхсәт ит“, – дип әйтә».

2 Фиргавен исә: «Кем соң ул Раббы?! Нишләп әле мин аны тыңларга һәм исраилиләрне җибәрергә тиеш?! Мин Раббыны белмим һәм исраилиләргә китәргә рөхсәт итмим!» – диде.



файдаланырга кешеләргә юл күрсәтте, ислам диненә дә юл күрсәтте».

51 Фиргавен әйтте: «Әүвәлдә үлеп киткән кешеләрнең хәлләре ничек, алар икенче дөнья өчен гыйбадәт кылалар иде».

52 Муса әйтте: «Аларның хәлләрен белмәк Аллаһ хозурындадыр, ләүхелмәхфузда язылмыш. Минем Раббым сүзендә вә эшендә һич хаталанмый һәм һичнәрсәне онытмас.

53 Ул – Аллаһ – җирне сезгә түшәк кылды, җир өстендә сезгә юллар кылды вә сезгә күктән яңгыр индерде. Аллаһ әйтте: „Яңгыр белән сезгә җирдән күп төрле үсемлекләр чыгардык.

54 Без чыгарган ризыклардан яхшыларын ашагыз вә хайваннарга яраклысын аларга ашатыгыз! Аллаһуның бу эшләрендә гакыл ияләренә гыйбрәтләр бар.

55 Без сезне җирдән яраттык һәм үтереп янә җиргә кайтарабыз вә һәм кыямәт булганда икенче мәртәбә сезне җирдән чыгарабыз “».

**26 сүрә**

18 Фиргавен әйтте: «Ий Муса, син сабый чагында бездә тәрбияләндең түгелме, вә гомереңнән бездә... ел тордың.

### *Муса белән Һарун фиргавен янында*

3 «Гыйбриләр Алласы безгә күренде, — дип җавап бирде Һарун белән Муса. — Зинһар, Раббы Аллабызга корбан китерү өчен, безгә өч көнлек сәфәргә чүлгә чыгарга рөхсәт ит. Әгәр моны эшләмибез икән, Ул безне үтерер: без йә берәр авырудан үләрбез, йә кылычтан һәлак булырбыз».

4 Ә Мисыр патшасы: «Муса, Һарун! Ни өчен халыкка эшләргә комачаулыйсыз? Барыгыз, эшләгез!



19 Һәм кыласы эшеңне кылдың ...син минем биргән нигъмәтемне инкяр итүчесен».

20 Муса әйтте: «Ул эшне мин эшләдем, ләкин шәригатьне белмәвем сәбәпле мин адашкан идем.

21 Сездән куркып качтым, вә Раббым миңа шәригать хөкемнәрен бирде вә мине рәсүлләрдән кылды.

22 Син миңа миннәт иткән нигъмәт ул шундый нигъмәттер, Ягъкуб балаларын үзеңә кол ясап, ир балаларны бугазлавыңдыр, үлемнән калу өчен мин синең тәрбияңә төшкәнмен».

23 Фиргавен әйтте: «Галәмнәрне тәрбия итүче ул нинди зат?»

### *Муса белән Һарун фиргавен янында*

24 Муса әйтте: «Ул — җирне, күкләрне һәм алар арасында булган нәрсәләрне тәрбия итүче, әгәр бу хак сүзгә ышансагыз».

25 Фиргавен Мусаның сүзләренә ышанмаган хәлдә үзенең тирәсендәге дусларына әйтте: «Әллә ишетмисезме Мусаның сүзләрен, мин аңа Раббысы хакында сорау бирдем, ул җавап кайтарды», — дип.

26 Муса әйтте: «Ул Аллаһ — сезнең Раббыгыз вә атагызның Раббысыдыр».







5 Сезнең халык бик күбәйде, ә сез аларны эштән аермакчы!» — дип әйтте.

6 Исраилиләр өстеннән күзәтчелек итүче назыйрларга һәм җитәкчеләргә фиргавен шул көнне үк әмер бирде:

7 «Элек сез, кирпеч сугу өчен, салам бирә идегез, хәзер инде саламны үзләре барып тапсыннар.

8 Алар сугарга тиешле кирпеч саны элеккечә калсын, кимемәсен. Алар ялкауландылар, шуңа күрә үз Аллаларына корбан китерү өчен җибәрүемне сорыйлар.

9 Күбрәк эшләргә мәҗбүр итегез, ул чагында алар эшләрләр һәм ялган сүзләрне тыңламаслар». <...>

19 Исраилиләрнең җитәкчеләре «Сугылган кирпечнең көндәлек күләме кимемәскә тиеш!» дигәнне ишеткәч, үзләренең бәлагә таруларын аңладылар.

20 Фиргавен яныннан чыккач, алар үзләрен көтеп торучы Муса белән Һарунны очраттылар.

21 «Безне фиргавен һәм аның күзәтчеләре нәфрәтенә дучар иткән өчен, Раббы сезгә җәза бирсен! Сез фиргавенне, аның хезмәтчеләрен безгә дошман ясадыгыз һәм, безне үтерү өчен, аларга кылыч тоттырдыгыз», — диделәр алар Муса белән Һарунга.



27 Фиргавен әйтте: «Сезгә рәсүл итеп җибәрелгән Муса, әлбәттә, җенледер».

28 Муса әйтте: «Ул Аллаһ — мәшрикъның вә мәгърибнең һәм алар арасындагы нәрсәләрнең Раббысыдыр, әгәр аңласагыз».

29 Фиргавен әйтте: «Әгәр син миннән башканы илаһ (итеп) тотсаң, мин сине төрмәгә бикләүчеләрдән булырмын».

30 Муса әйтте: «Әгәр пәйгамбәрлегемә ачык дәлилләр китерсәм дә, ул эшне эшләрсеңме?»

31 Фиргавен әйтте: «Әгәр дөрес пәйгамбәр булсаң, дәлилеңне китер».

32 Муса таягын җиргә ташлады, шуннан соң ул йөрүче зур елан булды.

33 Вә кулын култыгына тыгып чыгарды, караучыларга күзне чагылдырырлык ак булып чыкты.

34 Фиргавен әйтте: «Бу Муса барыгыздан да остарак сихерчедер.

35 Үзенең сихере белән сезне Мисыр җиреннән чыгарырга телидер, — үзенең олугъларына, — миңа нинди әмер бирәсез, шуны кыйлырмын», — диде.

36 Олугълары әйтте: «Мусаны вә кардәше Һарунны бикләп куй вә сихерчеләрне чакырырга кешеләр җибәр.

22 Муса кабат Раббыга мөрәҗәгать итте: «Йа Хуҗа-Хакимем, нигә Син Үз халкыңны шундый бәлагә дучар кылдың? Нәрсәгә дип мине бирегә җибәрдең?
23 Мин, фиргавенгә барып, аңа Синең исемеңнән сөйләп бирдем, һәм ул шул вакыттан бирле халыкны җәберли башлады. Син бит, халыкка ярдәм итү өчен, бернәрсә дә эшләмәдең!»

**Чыгыш 6**

1 Шуннан соң Раббы Мусага әйтте: «Фиргавен белән нәрсә эшләвемне син менә хәзер күрерсең. Мин аңа каршы Үземнең кодрәтемне юнәлтермен, һәм ул Минем халкыма китәргә рөхсәт итәчәк, хәтта үзе үк аларны куып җибәрәчәк, чөнки Мин аңа Үземнең кодрәтемне кулланырмын».

**Чыгыш 7**

1 Раббы исә Мусага: «Фиргавен өчен Мин сине Аллаһы кебек итәрмен, ә Һарун синең пәйгамбәрең булыр, — диде. —
2 Сиңа нәрсә боерсам, барысын да туганың Һарунга әйт, ә ул, Исраил халкына бу җирдән чыгарга рөхсәт итсен өчен, фиргавенгә җиткерер.
3 Мин исә фиргавенне кирәләндерермен, ә соңыннан Мисырда бик күп могҗизалар тудырырмын.

37 Алар сиңа Мусадан да остарак сихерчеләрне алып килсеннәр».
38 Һәм билгеләнгән вакытка сихерчеләр җыелдылар.
39 Кешеләргә әйтелде: «Җыелдыгызмы ике якның кылган эшләрен карарга?»
40 Җыелган мөшрикләр әйттеләр: «Әгәр сихерчеләр Мусаны җиңсәләр, шаять, сихерчеләргә иярербез».
42 Фиргавен әйтте: «...әгәр Мусаны җиңсәгез, минем якыннарымнан булырсыз».
43 Муса аларга әйтте: «Сез әүвәл ташлагыз ташларга дигән нәрсәләрегезне».
44 Һәм сихерчеләр арканнарын вә таякларын ташладылар вә әйттеләр: «Фиргавен олугълыгы белән ант итеп әйтәбез, әлбәттә, без Мусаны җиңәчәкбез», — дип.
45 Соңра Муса таягын җиргә ташлады, шулвакыт зур елан булды да тегеләрнең сихер белән елан итеп күрсәткән аркан вә таякларын чәйнәп ашап бетерде.
46 Бу хәлне күргәч сихерчеләр Аллаһуга сәҗдәгә егылдылар.
47 Әйттеләр: «Галәмнәрне тәрбия итүче Аллаһуга иман китердек.
48 Ул Аллаһ — Мусаның вә Һарунның да Раббысыдыр».





4 Ләкин фиргавен ул чагында да тыңларга теләмәс. Шуннан соң Мин, Үземнең кодрәтем белән мисырлылар өстенә куркыныч җәзалар җибәреп, Үз гаскәремне — халкым Исраилне Мисыр җиреннән алып чыгармын». <...>
8 Раббы Муса белән Һарунга әйтте:
9 «Фиргавен сездән могҗиза күрсәтүне таләп итсә, Һарунга әйт, ул үзенең юл таягын җиргә ташласын, һәм таяк фиргавен күз алдында еланга әверелер».
10 Муса белән Һарун фиргавен янына бардылар һәм, Раббы нәрсә кушкан булса, шуны үтәделәр. Һарунның таякны җиргә ыргытуы булды, таяк фиргавен һәм аның хезмәтчеләре күз алдында еланга әверелде.
11 Шуннан соң фиргавен үзенең акыл ияләрен һәм тылсымчыларын чакырып китерде, һәм Мисыр сихерчеләре тылсымнары белән Һарун кылганны кылдылар:
12 таякларын җиргә ташлаулары булды, һәр таяк шундук еланга әверелде, әмма Һарунның таягы тегеләрнең барлык таякларын йотып бетерде.
13 Фиргавен исә һаман киреләнә бирде. Барысы да Раббы әйткәнчә булды: фиргавен

49 Фиргавен әйтте: «Әллә сез мин рөхсәт бирүдән элек Мусага иман китерәсезме? Әлбәттә, сихер белемендә ул сезнең олугыгыздыр, сезгә аз гына өйрәткән, шуның өчен ул сезне җинде; бәс минем җәзамны тиз белерсез, сезнең уң кулыгызны вә сул аягыгызны кисәрмен һәм барчаларыгызны да асармын», — дип.
50 Иман китергән сихерчеләр әйттеләр: «Ий фиргавен, син кыйлган эштән безнең иманыбызга зарар юк, үлгәч без Раббыбызга кайтабыз, Ул безгә әҗерен бирер.
51 Ширек вә сихердән булган хаталарыбызны, әлбәттә, Раббыбыз ярлыкар дип өмет итәбез, Мусага беренче без иман китергәнебез өчен».

Муса белән Һарунны тың-
лаудан баш тартты.

***Мисырга Аллаһы җибәргән җәзалар***

[14] Раббы шуннан Мусага әйтте:
«Фиргавеннең йөрәге йом-
шармый, халыкка китәргә
рөхсәт бирми ул.
[15] Иртә белән фиргавен Нил ел-
гасы буена чыгар, син, шун-
да барып, аны көт. Еланга
әверелгән теге таягыңны да
үзең белән ал
[16] һәм фиргавенгә болай дип әйт:
„Раббы, гыйбриләр Алласы,
мине синең янга җибәреп,
Миңа табыну өчен халкыма
чүлгә чыгарга рөхсәт ит, дип
әйтергә кушкан иде. Ләкин
син моңарчы Аны тыңла-
мадың.
[17] Шунлыктан Раббы болай дип
әйтә: хәзер син Минем Раббы
икәнемне белерсең! Менә,
кулымдагы таягым белән
Нил елгасына сугуым булыр,
су канга әверелер.
[18] Андагы балык үлеп бетәр, елга
сасый башлар, һәм мисыр-
лылар аннан су эчә алмас“».
[19] Раббы болай дәвам итте: «Һа-
рунга әйт, ул үзенең таяк тот-
кан кулын Мисырдагы бар-
лык елгалар, арыклар, күлләр
һәм һәр сусаклагыч өстенә
сузсын, аның шулай эшләве
булыр – шундук барча сулар
канга әверелер. Мисырның



***Мисырга Аллаһы җибәргән җәзалар***

**7 сүрә**

[127] Фиргавен кавеменнән олы-
лары әйттеләр: «Ий фирга-
вен! Мусаны вә аның ка-
вемен җир өстендә бозык-
лык кылсыннар һәм сиңа
вә сынымнарыңа гыйбадәт
кылуны куйсыннар өчен
аларны калдырасыңмы?» –
диделәр. Фиргавен әйтте:
«Тиздән кыз балаларын
калдырып, ир балаларын
үтерербез, без, әлбәттә,
алардан өстенбез, көчле-
без», – дип.
[128] Муса үзенең кавеменә әйтте:
«Аллаһудан ярдәм сорагыз
һәм залимнәрнең золымы-
на чыдагыз! Бит җир Ал-
лаһу Тәгаләнеке, җиргә Ул
Үзе теләгән бәндәсен хуҗа
кылыр, эшнең ахырындагы
шатлык вә уңыш тәкъва мө-
эминнәргә».
[129] Муса кавеме әйтте: «Ий Муса!
Без син килгәнче дә бу фир-
гавен кавеменнән күп золым
күрдек һәм син килгәч тә
золым күрмәктәбез», – дип.
Муса әйтте: «Раббыгызның
сезнең дошманнарыгыз-
ны тиздән һәлак итмәклеге
өметле һәм алар урынына
сезне хәлифә итмәклеге,





һәр җирендә кан булыр. Хәт-
та агач һәм таш савытлардагы
су да канга әверелер».
[20] Муса белән Һарун Раббының
кушканын үтәделәр. Һарун-
ның фиргавен вә аның хез-
мәтчеләре күз алдында, та-
ягын күтәреп, Нил елгасына
сугуы булды – бөтен су канга
әверелде.
[21] Нилдагы балыклар үлде, һәм,
андагы су сасып, мисырлы-
лар аннан су эчә алмадылар.
Мисырның һәр җирендә кан
иде.
[22] Мисыр тылсымчылары, үз
сихерләрен кулланып, шуны
ук эшләделәр. Фиргавен, ки-
реләнеп, Муса белән Һарун-
ны тыңлаудан баш тартты.
Һәммәсе дә Раббы әйткәнчә
булды.
[23] Фиргавен, Муса белән Һа-
рунның кылган эшләренә
игътибар бирмичә, борылып,
өенә кайтып китте.
[24] Барлык мисырлылар елга су-
ын эчә алмадылар һәм эчәргә
су табу максаты белән Нил
ярлары буйлап коелар ка-
зыдылар.
[25] Раббының Нил елгасына су-
гуына җиде көн узды.

**Чыгыш 8**

[5] Раббы янә Мусага әйтте: «Һа-
рунга әйт, юл таягы тоткан
кулын елгалар, арыклар, күл-
ләр өстенә сузып, Мисыр
өстенә бакалар җибәрсен».



Аллаһ сезне күзәтер, ничек
эш кылырсыз икән!»
[130] Тәхкыйк, фиргавен кавемен
ачлык белән вә бакча җи-
мешләрен уңышсыз итү бе-
лән бәлаләндердек, вәгазьлә-
неп иман китерсеннәр өчен.
[131] Әгәр аларга шатлык, бай-
лык килсә: «Бу безгә тиешле,
үзебезнең яхшылыгыбыздан
килде, әгәр яманлык ирешсә,
бу яманлык Муса белән аның
иярченнәреннән», – дип
шомланырлар. Агәһ булыгыз,
аларның шомланулары Ал-
лаһу хозурында, әмма аларга
ирешкән яманлык үзләренең
кәсебе өчен Аллаһудан ире-
шә, ләкин күбесе Аллаһудан
ирешә дип белмәсләр.
[132] Фиргавен кавеме кяферләр
әйттеләр: «Безне сихерләр
өчен берәр галәмәт китерсәң
дә, без барыбер сиңа ышану-
чы кешеләр түгелбез».
[133] Аларга су баскынын, саранча,
бет, бакаларны һәм кан җи-
бәрдек, боларны аерым-ае-
рым ачык галәмәтләр итеп
җибәрдек. Бу галәмәтләрне
күргәннең соңында да тә-
кәбберләнеп, азган кяфер
кавеме булдылар.
[134] Аларга Аллаһуның газабы
килгәндә әйттеләр: «Ий Му-
са! Безнең өчен Раббыңа до-
га кыл, Ул сиңа «дога кыл»
дип әмер иткәне өчен! Әгәр
безнең өстебездәге газапны

6 Һарун үзенең кулын Мисыр
сулыклары өстенә сузды, һәм
шундук бакалар, чыгып, бө-
тен Мисырны каплап алды-
лар. <...>
16 Раббы Мусага әйтте: «Һа-
рунга әйт: „Таягыңны су-
зып, тузанлы җиргә сук!“
Шул чагында бөтен Ми-
сырдагы тузан черкигә әве-
релер».
17 Алар нәкъ шулай эшләделәр
дә. Һарунның, таяк тоткан
кулын сузып, тузанлы җиргә
сугуы булды, бөтен Мисыр-
да тузан бөртекләре черкигә
әверелде дә, кешеләрне һәм
терлекне черки сырып ал-
ды. <...>
24 Раббы шулай эшләде дә. Ми-
сыр җирен биниһая күп че-
беннәр каплап алды, алар
фиргавен өенә дә, аның хез-
мәтчеләре яшәгән өйләргә
дә кереп тулды. Чебен чирүе
бөтен Мисырны һәлакәткә
төшерде.

**Чыгыш 9**

6 Икенче көнне Раббы шулай
эшләде дә: мисырлыларның
бар терлеге үлеп бетте, ә Ис-
раил халкының бер генә хай-
ваны да үлмәде.
7 Фиргавен, белешер өчен, ке-
шеләр җибәрде, һәм, дөрес-
тән дә, Исраил халкының
бер генә хайваны да үлмә-
гән иде. Шулай да фиргавен
каршы торуын дәвам итте

ТӘҮРАТ

җибәрә алсаң, әлбәттә, сиңа
иман китерербез һәм Ягъкуб
балаларын да синең белән,
әлбәттә, җибәрербез», – дип.
135 Муса догасы аркасында алар-
дан газапны алсак, киләсе
газап вакытында, шул ва-
кытта алар гаһедләрен сын-
дыралар – сүзләрендә тор-
мыйлар.
136 Аларны суга батырып алардан
үчебезне алдык, аятьләребез-
не ялган диеп аннан гафил
булганнары өчен...

КОРЪӘН





һәм Исраил халкына китәргә
рөхсәт бирмәде.
8 Раббы Муса белән Һарунга:
«Мичтән, уч тутырып, көл
алыгыз, һәм фиргавен күз
алдында Муса шул көлне
күккә сибеп җибәрсен.
9 Көл шунда, тузанга әйләнеп,
бөтен Мисырны каплап
алыр, һәм илдәге барча ке-
шеләр вә хайваннар тәнендә
эренле чуан ялкынсынуы
башланыр», – диде.
10 Муса белән Һарун, мичтән
көл алып, фиргавен каршына
килеп бастылар. Мусаның
көлне күккә сибеп җибәрүе
булды, кеше һәм хайваннар
тәнендә эренле чуан ялкын-
сынуы башланды.
11 Тылсымчылар Муса янына
чыга алмадылар, чөнки алар,
барлык мисырлылар кебек,
эренле чуан белән капланган
иделәр. <...>
22 Раббы Мусага әйтте: «Кулың-
ны күккә суз, һәм шундук
бөтен Мисырда боз ява баш-
лар. Кешеләрне, терлекләрне,
Мисыр җирендәге барлык
үсемлекләрне боз сугар».
23 Мусаның таякны күккә сузуы
булды, Раббы, күкләр күк-
рәтеп, боз җибәрде, җиргә
яшен төшерде. Бөтен Мисыр
өстенә Раббы ишеп боз яу-
дыра башлады.
24 Боз яуды, яшен яшьнәде – ил
буларак Мисырның нигезе

ТӘҮРАТ

салынган көннән алып мон-
дый көчле бозның яуганы
юк иде әле.
25 Мисыр кырларындагы бар
нәрсәне – кешеләрне, тер-
лекләрне һәм үсемлекләрне
боз харап итте, хәтта агач-
ларны сындырып бетерде.
26 Бары тик исраилиләр яши
торган Гөшен җирендә генә
боз яумады.

**Чыгыш 10**

12 «Мисыр җиренә кулыңны
суз, – диде Раббы Мусага, –
җир өстен саранча басып ал-
сын да басу-кырларда боз
сугудан исән калган барча
үсемлекне ашап бетерсен».
13 Мусаның таякны сузуы булды,
Раббы Мисыр җиренә көчле
көнчыгыш җилен җибәрде.
Җил, көн буе вә төн буе исеп,
иртәнге якта саранча алып
килде.
14 Саранча бөтен җир өстен кап-
лап алды – шуның кадәр
саранчаның моңарчы бул-
ганы юк иде һәм киләчәктә
дә булмас.
15 Бар җирне саранча басып ал-
ганлыктан, җир өсте кап-ка-
ра булды. Саранча басу-кыр-
ларда боз сугудан исән кал-
ган барлык үсемлекләрне һәм
агачлардагы барлык җимеш-
ләрне ашап бетерде. Бөтен
Мисыр илендә агачларда һәм
үсемлекләрдә яфрак әсәре
калмады.







16 Фиргавен ашыгыч рәвештә
Муса белән Һарунны үзенә
чакыртып алды һәм әйтте:
«Раббы Аллагызга һәм сез-
гә каршы килеп, мин гөнаһ
эшләдем». <...>
21 Аннары Раббы Мусага әйтте:
«Кулыңны күккә суз, һәм
шулчак Мисыр җире өсте-
нә дөм караңгылык төшәр!»
22 Мусаның күккә кул сузуы
булды, бөтен Мисыр өстен
тоташ караңгылык каплап
алды.
23 Өч көн буе кешеләр бер-бер-
сен күрә алмады һәм өйлә-
реннән чыкмады, ә исраи-
лиләр яшәгән төбәк яп-якты
булды.
24 Фиргавен яңадан Мусаны ча-
кырып алды да: «Барыгыз,
Раббыга табыныгыз! Үзе-
гез белән балаларыгызны
да алыгыз, тик вак һәм эре
терлегегезне калдырыгыз», –
диде.

**Чыгыш 12**

29 Төн уртасында Раббы Мисыр
җирендә беренче булып ту-
ганнарның барысын да – тә-
хеттәге фиргавеннең беренче
углыннан башлап, зindан-
дагы тоткынның беренче уг-
лына кадәр үтерде. Беренче
булып туган барлык иркәк
терлек тә үтерелде.
30 Ул төнне фиргавен, аның хез-
мәтчеләре һәм барча мисыр-
лылар уяу иделәр – бөтен

Мисыр җирендә кычкырып елаган тавышлар ишетелеп торды, чөнки һәр йортта кем дә булса үлгән иде.

***Израилиләрнең Мисырны ташлап китүе***

31 Шул төнне фиргавен Муса белән Һарунны чакырып алды да әйтте: «Үзегез дә, исраилиләр дә минем халкымнан аерылып китегез! Сораганыгызча, Раббыгызга барып табыныгыз!

32 Сез сораганча булсын: үзегез белән вак һәм эре терлегегезне алыгыз да китегез! Ә миңа хәер-фатихагызны бирегез!»

33 Мисырлылар да, Исраил халкының Мисыр җиреннән тизрәк китүен сорап: «Югыйсә барыбыз да һәлак булачакбыз», – диделәр.

34 Шуннан соң исраилиләр камырлары әчеп өлгермәгән куәс чиләкләрен кием-салымга төрделәр дә җилкәләренә куеп алып киттеләр.

35 Алар, Муса кушканча, мисырлылардан көмеш вә алтын әйберләрен һәм кием-салым сорадылар.

36 Раббы мисырлылар күңелендә Үз халкына карата кызгану хисе уятты, һәм алар исраилиләр сораган барлык әйберләрне бирделәр. Исраилиләр, шулай итеп, мисырлыларны талап киттеләр.



***Израилиләрнең Мисырны ташлап китүе***

**10 сүрә**

87 Муса илә Һарунга вәхи кылып әйттек: «Кавемегезгә Мисырда өйләр хәзерләгез вә ул өйләрегездә мәсҗидләр кылыгыз һәм намазларыгызны шул өйләрегездә үтәгез, вә мөэминнәрне шатландыр, аларга дөньяда һидаять, ахирәттә җәннәт булачак».

88 Муса әйтте: «Ий Раббым! Кешеләрне аздырмак өчен фиргавенгә вә аның олугъларына дөньяда зиннәт һәм мал биргәнсең. Ий Раббыбыз, син аларның малларыны һәлак итеп, күңелләрен каралт ки, һәлак итүче газапны күрмичә иман китермәслек булсыннар».

89 Аллаһ әйтте: «Тәхкыйк, сезнең догаларыгыз кабул ителде, боерылган эшегездә туры торыгыз һәм хакны белми торган наданнарга һич иярмәгез».

**26 сүрә**

52 Без Мусага вәхи кылдык: «Кавемең белән Мисырдан чыгып кит, әлбәттә, фиргавен гаскәре белән артыгыздан куа чыгачак», – дип.







**Чыгыш 13**

17 Фиргавен Исраил халкына Мисырдан китәргә рөхсәт иткәч, Аллаһы аларга пелештиләр җиренә илтә торган кыска юлдан барырга ирек бирмәде, чөнки Ул: «Исраилиләргә сугышырга туры килсә, алар, кире уйлап, Мисырга әйләнеп кайтырга мөмкин», – дип әйтте.

18 Шуңа күрә Аллаһы аларны урау юлдан, чүл аша Камышлы диңгезгә алып китте. Мисыр җиреннән чыкканда, Исраил халкының кулында инде сугыш коралы бар иде.

19 Йосыфның сөякләрен Муса үзе белән алды, чөнки кайчандыр бервакыт Йосыф: «Аллаһы сезгә ярдәмен күрсәткәч, минем сөякләремне бу илдән алып чыгарсыз», – дип, исраилиләрне ант иттергән була.

20 Суккөттән чыккач, Исраил халкы, чүл кырыендагы Этам дигән җирдә тукталып, чатырлар корды.



53 Фиргавен шәһәрләргә гаскәр җыючыларны җибәрде.

54 Фиргавен әйтте: «Мусаның гаскәре безнекенә караганда аз гаскәрдер.

55 Алар безне ачуландыра торган эш кыйлдылар.

56 Без, әлбәттә, аларны куарга хәзерләнәбез», – дип.

57 Һәм без фиргавенне вә гаскәрне бакчалардан вә елгалардан чыгардык.

58 Вә алтын-көмеш вә башка байлыклардан һәм яхшы урыннан чыгардык.

59 Әнә шулай Без аны кызык иттек, алар байлыгына һәм урыннарына Ягъкуб балаларын хуҗа кылдык.

60 Һәм фиргавен белән гаскәре кояш чыккан вакытта Муса артыннан куып киттеләр.

61 Фиргавен гаскәре белән Муса гаскәре бер-берсен күргәннәре заманда, Муса гаскәреннән берсе куркып: «Фиргавен артыбыздан җитте, тәхкыйк, куылып тотылдык», – диде.

62 Муса әйтте: «Юк, безгә ирешә алмаслар, чөнки Раббым минем иләдер, әлбәттә, котыла торган юлга күндерер», – дип.

63 «Таягың илә диңгезгә сук», – дип Мусага вәхи кылдык, бәс диңгездән 12 юл ачылды, һәр ике юл арасында зур тау кеби бөек су булды.

*Диңгез кичү*

**Чыгыш 14**

3 «Фиргавен: „Исраилиләр чүлдә адашып йөриләр, барыр җирләре юк“, – дип уйласын.

4 Мин фиргавенне янә үҗәтләндерермен, һәм ул аларны куа чыгар, ә Мин аны һәм аның гаскәрен җиңәрмен дә, Миңа дан килер. Шул чагында мисырлылар Минем Раббы булуымны танырлар». Исраил халкы шулай эшләде дә.

5 Мисыр патшасына, ягъни фиргавенгә «Исраил халкы качты» дигән хәбәр ирешкәч, аның һәм хезмәтчеләренең исраилиләр турындагы

64 Вә фиргавен гаскәрен шул тау кеби сулар арасына якын китердек.

65 Вә Мусаны һәм аның белән булганнарның барчасын коткардык.

66 Сонра шул суга фиргавенне гаскәре белән бергә батырып һәлак иттек.

67 «Мин – Аллаһ» дигән фиргавеннең гаскәре белән суга батып һәлак булуында, әлбәттә, гакыллы кешеләр өчен гыйбрәт бардыр. Мисыр халкының күбрәге Аңар иман китермәс булдылар.

68 Синең Раббың әнә шулай дошманнарыннан үч алучы вә дусларына рәхмәт итүчедер.

*Диңгез кичү*

**10 сүрә**

90 Бәни Исраилне дәрья аркылы үткәрдек, тәкәбберлек вә дошманлык белән алар артыннан фиргавен вә аның гаскәре куып чыктылар. Бәни Исраил өчен ачылган су аралыгына кереп бата башлагач, фиргавен әйтте: «Иман китердем, гыйбадәт кылырга яраклы Илаһ юк, мәгәр бәни Исраил иман китергән Аллаһу Тәгалә генәдер вә мин мөселманнарданмын».

91 Аллаһ әйтте: «Хәзер иман китерәсеңме? Башта Аллаһуга





фикерләре кинәт үзгәрде: «Нәрсә эшләдек без?! Ник исраилиләргә китәргә рөхсәт бирдек?! Безнең хәзер эшләргә хезмәтчеләребез калмады бит», – диеште алар. <...>

8 Раббы шулчак Мисыр патшасының, ягъни фиргавеннең кирелеген кузгатты, һәм ул батыраеп китеп барган исраилиләрне куа чыкты.

9 Мисырлылар – фиргавеннең барлык атлары, арбалары, җайдаклары һәм сугышчылары – исраилиләрне Пи-Һахирут янында, Багал-Сефон каршындагы диңгез ярында куып җиттеләр. Тегеләрнең нәкъ чатырлар корып яткан чаклары иде. <...>

15 Шулчак Раббы Мусага әйтте: «Син әле нишләп Мине ярдәмгә чакырасың? Исраил халкына әйт – алга барсыннар.

16 Син исә юл таягыңны күтәр һәм кулыңны диңгез өстенә суз, шулчак сулар икегә аерылыр да, халык, коры җирдән баргандай, дингезне кичәр.

17 Мин мисырлыларны киреләндерермен, шуңа күрә алар сезнең арттан куа барырлар, ә Мин фиргавенне, аның барлык гаскәрен арбалары һәм җайдаклары белән бергә җиңәрмен дә, Миңа дан килер». <...>

гасый булдың һәм бозыклык кылучылардан идең.

92 Сездән соң киләчәк кешеләргә гыйбрәт булсын өчен тәнегезне бүген су өстенә чыгарабыз». Ләкин кешеләрнең күбрәге Безнең гыйбрәтләнерлек аятьләребездән гафилләр, һич вәгазьләнмиләр.

**17 сүрә**

103 Фиргавен Муса г-мне вә Ягъкуб балаларын Мисыр җиреннән куып җибәрергә теләде, Без аны һәм дә аның белән бергә булганнарны һәммәсен суга батырып һәлак иттек.

104 Фиргавенне һәм аның кавемен һәлак иткәч Ягъкуб балаларына әйттек: «Фиргавен сезне куып чыгарырга теләгән җирдә хәзер инде сез торыгыз! Кыямәт көне килсә, барчагызны каберләрегездән кубарып мәхшәр җиренә китерербез, анда мәгълүм булыр, кем яхшы, кем яман икәнлеге».

[27] Муса диңгез өстенә кулын
сузды, һәм, таң атып кил-
гәндә, диңгез әүвәлге хәленә
кайтты. Мисырлылар судан
качып йөгерергә тотынды-
лар, әмма Раббы, селкеп тө-
шергән сыман, аларны дул-
кын эченә ыргытты.
[28] Су, кабат үз урынына кай-
тып, Исраил халкы артыннан
куып килгән фиргавеннең
барлык гаскәрен, арбаларын
һәм җайдакларын күмеп кит-
те. Аларның берсе дә исән
калмады!

### *Чүлдә сыналу*

**Чыгыш 13**
[21] Көндезен Раббы, болыт бага-
насы булып, алар алдыннан
юл күрсәтеп барды, төнлә
исә, ут баганасы булып, ба-
рыр юлларын яктыртты.
Шуңа күрә алар көндез дә,
төнлә дә юлларын дәвам итә
алдылар.
[22] Болыт баганасы – көнозын, ә
ут баганасы төне буе алардан
аерылмады.
**Чыгыш 16**
[2] Чүлдә бар халык Муса белән
Һаруннан зарланды.
[3] «Раббының кулы безне Мисыр
җирендә үтерсә, яхшырак бу-
лыр иде, – диде алар. – Анда,
ичмаса, ит салынган казан
янында утырдык, туйганчы
ашадык. Ә сез безне шушы
чүлгә алып килдегез, һәм



### *Чүлдә сыналу*

**2 сүрә**
[57] Ий Ягъкуб балалары! Болыт-
ны Без сезгә күләгә кылдык
һәм сезгә күктән ширбәт вә
кош итен индердек, ашагыз
Без биргән хәләл һәм пакь
ризыкларны! Без аларга зо-
лым кылмадык, ләкин алар
үзләренә золым кылдылар.
[58] Янә: «Әрихә шәһәренә ке-
регез», – дип әйткәнемне
дә хәтерләгез! Ягъни кырык
елдан соң, Муса үлгәч, Ягъ-
куб балаларына Әрихә шә-
һәренә керергә Аллаһудан
әмер булды. Шәһәргә кергәч,
анда ризыкларны киңлек бе-
лән теләгәнчә ашагыз, шә-
һәр капкасыннан кергәндә
баш иеп, түбәнчелек белән
керегез һәм «хаталарыбыз-
ны гафу ит, Раббым» дип







биредә без барыбыз да ачтан
үләчәкбез».
[4] Шулчак Раббы әйтте Мусага:
«Карагыз аны: Мин сезгә
күктән икмәк яудырырмын.
Халык көн саен чыксын һәм,
көненә күпме кирәк булса,
шуның кадәр генә җыйсын.
Минем Канун буенча гамәл
кылырлармы икән дип сы-
намакчымын аларны. <...>
[12] Мин Исраил халкының зар-
ланганын ишеттем. Аларга
болай дип әйт: „Бүген кич
сез ит ашарсыз, ә иртән ик-
мәк белән туенырсыз һәм
шул чагында Минем Раббы
Аллагыз булуымны аңлар-
сыз“».
[13] Шул кичне бүдәнәләр өере
очып килеп исраилиләр ста-
нын каплап алды, ә иртәге-
сен станның әйләнә-тирәсе-
нә чык төште.
[14] Чык күтәрелгәч, чүлдә юка
катлам булып бәскә охшаган
нәрсә ятып калды.
[15] Моны күреп, исраилиләр
бер-берсеннән:
«Бу ни соң?» – дип сорашты-
лар, чөнки аларның мондый
нәрсәне әлегәчә күргәннәре
юк иде. Муса аларга әйтте:
«Бу – икмәк; аны сезгә Раббы
җибәрде». <...>
[21] Ашый алган күләмдә кешеләр
һәр иртәдә икмәк җыйдылар;
көндезге эсседә исә ризык
эреп юкка чыга иде.



әйтегез! Шулай кылсагыз,
хата эшләрегезне ярлыкар-
быз. Яхшы эшләрне кылучы
мөэминнәргә нигъмәтләре-
безне бик тиз арттырырбыз.
[59] Ягъкуб балалары арасында
булган залимнәр шәһәргә
кергәндә үзләренә золым
кылдылар, ягъни шәһәр
капкасыннан кергәндә Ал-
лаһудан әмер ителгән сүз-
не әйтмичә, башка сүзгә
алыштырдылар, ягъни шә-
һәргә кергәндә Аллаһудан
гафу сорап, тәүбә итеп керер
урында, шайтан өйрәткән
сүзне әйтеп, тәкәбберләнеп
керделәр. Ул залимнәргә
явызлык кылганнары өчен
күктән рисвай итүче газап
индердек.
[60] Янә шуны хәтерләгез, Муса
үзенең кавеме өчен Аллаһу-
дан су сорады, Без Мусага
әйттек: «Таягың белән таш-
ка сук», – дип. Муса таягы
белән ташка сукты, таштан
12 чишмә акты, чөнки алар
12 кабилә иделәр. Һәр каби-
лә үзенең чишмәсен белде.
Аллаһ биргән ризыклардан
ашагыз, эчегез, әмма җир
өстендә бозыклык кылып
йөрмәгез, дип әйтелде аларга
Аллаһудан.
[61] Янә әйттегез: «Ий Муса, без
бертөрле генә ризыкка сабыр
итә алмыйбыз, безнең өчен
Раббыңа дога кыл, җирдә

**Саннар 11**

4 Халык арасындагы төрле милләт кешеләре аш талымлый башлады, һәм алар белән бергә исраилиләр дә елап зарланырга тотындылар: «Безне кем ит белән туендырыр?!

5 Без Мисырда вакытта бушлай ашаган балыкларны, кыяр, кавыннарны, ялпак суган, башлы суган һәм сарымсакларны искә төшерәбез.

6 Инде хәлсезләнеп беттек без, ашарга бернәрсә юк, күз алдыбызда манна гына». <...>

10 Муса һәр гаиләнең үз чатыры алдында яшь түгүен ишетте. Раббының моңа бик нык ачуы кабарды, Муса да борчуга төште.

11 Муса Раббыга әйтте: «Ни өчен Син мине – Үз колыңны газаплыйсың? Ни өчен мин Синең күз алдында шәфкать казанмадым һәм нигә Син бөтен халыкның авырлыгын минем өстемә йөкләдең?» <...>

23 Раббы Мусага әйтте: «Әллә Раббының кулы кыска дип уйлыйсыңмы?! Сиңа әйткән сүзем тормышка ашырмы, юкмы икәнен хәзер күрерсең». <...>

31 Менә Раббы җил кузгатты, һәм шул җил диңгез ягыннан бүдәнәләр очыртып китерде. Станның һәр тарафында, бер



үсә торган нәрсәләрдән: кыяр, сарымсак, суган һәм вак орлыклардан сорап». Муса аларга әйтте: «Аллаһ биргән әүвәлге яхшы ризыкларны үзегез сораган начар ризыкларга алыштырасызмы? Шәһәргә керегез, сез сораган нәрсәләр анда булыр». Аларга авыр эшләр, хурлык, мескенлек вә Аллаһуның ачулы каһәре йөкләтелде. Аларга бу җәзалар Аллаһудан тиешле булды. Аның аятьләрен инкяр иткәннәре һәм пәйгамбәрләрне хаксыз үтергәннәре өчен, дәхи бу җәзалар аларга тиешле булды Аллаһуга гөнаһлы булганнары һәм сызган сызыктан чыкканнары өчен.

**20 сүрә**

80 «Ий Ягъкуб балалары, тәхкыйк, Без сезне дошманыгыз фиргавеннән коткардык вә Тур тавы(ның)... уң ягыннан сезгә Тәүратны вәгъдә иттек вә сезгә ашарга күктән ширбәт һәм кош итен индердек.

81 Без биргән ризыклардан яхшысын ашагыз, көфран нигъмәт итеп гөнаһ эшләүдә чиктән узмагыз, югыйсә сезгә ачуым тияр, берәүгә Минем ачуым инсә, тәхкыйк, ул кеше һәлак булыр.

82 Тәүбә итеп иман китергән вә Коръән юлы белән изге гамәлләр кылган, соңра туры





көнлек юл ераклыгында, әйләнә-тирәдә ике терсәк калынлыгында өем-өем булып бүдәнәләр ята иде.

32 Халык исә шул көнне һәм төн буе, шулай ук икенче көнне бүдәнә җыйды. Иң аз дигәндә дә һәркайсы ун хомер бүдәнә җыйды һәм аларны стан тирәли җәеп таратты.

33 Әмма кешеләр, итне авызларына алып, чәйнәп йотарга да өлгермәделәр – Раббының халыкка ачуы кузгалып, аларга Ул үләт зәхмәте җибәрде.

**Чыгыш 17**

1 Раббы кушканча, Исраил халкы, бер урыннан икенче урынга күчә-күчә, Син чүле буйлап алга атлады. Чатырлар корып, алар Рефидимдә тукталдылар, әмма анда эчәргә су булмады.

2 Халык янә, Мусаны гаепләп: «Безгә эчәргә су бир», – дип таләп итте. «Сез әле нишләп мине гаеплисез? – диде Муса. – Ни өчен сез Раббыны сыныйсыз?» <...>

4 Муса Раббыга ялварып әйтте: «Бу халык белән миңа нишләргә хәзер? Озакламый алар миңа таш атар!»

5 Раббы Мусага әйтте: «Үзең белән берничә Исраил өлкәнен ияртеп һәм Нил елгасына суккан таягыңны тотып,



юлга күнелеп үлгәнче хак юлда таза торган кешеләрне Мин, әлбәттә, ярлыкаучымын».

**7 сүрә**

160 Без Ягъкуб балаларын унике кабиләгә бүлдек вә Мусаның кавеме су сораганда Без Мусага вәхи кылдык: «Таягың белән ташка сук», – дип. Ул таштан унике чишмә акты, тәхкыйк, һәр кабилә үзенең чишмәсен белде; аларны кояш кыздырмасын өчен болыт белән күләгәләдек һәм ширбәт илә кош итен индердек вә: «Ашагыз Без биргән яхшы ризыклардан», – дидек. Алар Безгә золым кылмадылар, ләкин ризыклар хакында Аллаһ хөкеменә хыянәт итеп, үзләренә золым иттеләр.

халык алдына чык та юлыңны дәвам ит.
6 Мин исә Хоребтагы кыя башында синең каршыда басып торырмын. Таягың белән кыяга сугуың булыр, шундук аннан су бәреп чыгар, һәм кешеләр сусыннары канганчы эчәрләр». Муса Исраил өлкәннәре күз алдында нәкъ шулай эшләде дә.

**Чыгыш 15**

27 Шуннан алар Элимгә килеп җиттеләр. Анда унике су чыганагы һәм үсеп утыра торган җитмеш хөрмә агачы бар иде. Алар, чатырлар корып, су янында урнаштылар.

### *Синай тавында*

**Чыгыш 19**

16 Өченче көнне иртән тауга куе болыт төште, күк күкрәп, яшен яшьнәде һәм быргының колак яргыч тавышы ишетелде – стандагы халык курка калды.
17 Шулвакыт Муса кешеләрне, Аллаһы белән очрашырга дип, станнан алып чыкты, һәм алар тау итәге янына килеп бастылар.
18 Синай тавы төтенгә күмелде, чөнки Раббы тауга ут эчендә төште. Таудан, мичтән чыккан сыман, төтен бөркелә иде. Тау тоташтан селкенеп торды.

### *Синай тавында*

**7 сүрә**

142 Мусаны Тур тавында утыз кичә вә утыз көн тотмак белән вәгъдә кылдык, вә ул утыз көнне янә ун көн кушып тәмам иттек, Раббысының вәгъдәсе кырык кичтә тәмам булды. Муса Тур тавына киткәндә кардәше Һарунга әйтте: «Кавемем арасында минем урынымда кал һәм аларның эшләрен төзек кыл вә бозыклык кылучылар юлына кермә!»
143 Муса вәгъдә кылынган урыныбызга килгәч, Раббысы аңа сөйләде, ягъни сөйләштеләр, Муса Алла-





19 Быргы тавышы көчәйгәннән-көчәя барды. Шулчак Муса Аллаһыга мөрәҗәгать итте, һәм Аллаһы, күк күкрәтеп, аңа җавап кайтарды.

**Чыгыш 24**

18 Муса, тауга күтәрелеп, болытлар эченә керде; әлеге тауда ул кырык көн һәм кырык төн булды.

**Чыгыш 33**

18 Шулчак Муса Раббыга әйтте: «Зинһар өчен, миңа Үзеңнең шөһрәтеңне күрсәт».
19 Раббы җавап кайтарды: «Синең алдыңда Мин Үземнең бар шөһрәтемне күрсәтермен; Үземнең „Раббы“ дигән исемемне игълан итәрмен. Кемгә теләсәм, шуңа шәфкать күрсәтермен; кемне кызганырга теләсәм, шуны кызганырмын.
20 Әмма Минем йөземне күрә алмассың, чөнки Мине күргән кеше исән кала алмый».
21 Раббы тагын әйтте: «Менә, Минем янымда бер урын бар. Син шушы урында – кыяда басып торырсың.
22 Минем шөһрәтем шул турыдан узганда, Мин сине кыя ярыгына яшерермен һәм, шөһрәтем узып киткәнче, сине Үз кулым белән каплап торырмын.
23 Соңыннан кулымны алырмын, һәм син Минем аркамны

һыны күрергә теләп әйтте: «Ий Раббым! Миңа күрен, мин Сиңа карыйм», – дип. Аллаһ әйтте: «Юк, Мине күрә алмассың, ләкин тауга карагыл, әгәр тау урынында тора алса, Мине күрерсең». Мусаның Раббысы тауга һәйбәт нурын төшергәч, тауны кисәкләр кылды, вә Муса һушы китеп егылды; Муса гакылына килгәч әйтте: «Ий Раббым! Сине һәрбер кимчелектән пакьсең дип беләмен, Сиңа тәүбә иттем вә мин өммәтем арасында иң әүвәлге мөэминмен».
144 Аллаһ Мусага әйтте: «Ий Муса! Кешеләргә пәйгамбәр итеп җибәрергә вә Үзем белән сөйләшергә сине ихтыяр кылдым. Без биргән китапны куәт белән тот вә Без биргән нигъмәтләргә шөкер итүчеләрдән бул».
145 Мусага Тәүрат такталарында һәрнәрсәне яздык, вәгазьне вә һәрнәрсәне бәян иттек, аны ал куәт белән һәм кавемеңә дә Тәүрат белән гамәл кылырга боер, Тәүратның күркәмрәк хөкемнәрен алсыннар! Мин сезгә тиздән күрсәтермен фасикълар йорты җәһәннәмне, Тәүрат хөкемнәрен бозып фасикъ булмагыз!

күрерсең, әмма йөземне күрә алмассың».

**Чыгыш 24**

1 Шуннан соң Раббы Мусага: «Син үзең, Һарун, Надаб, Абиһу һәм житмеш Исраил өлкәне тауга күтәрелегез дә ерактан гына Миңа табыныгыз.

2 Әмма Раббы янына Муса үзе генә якынлашсын, ә калганнар моны эшләмәсен. Халык исә аның белән тауга менәргә тиеш түгел», — диде.

3 Муса, халык янына барып, Раббының барлык сүзләре һәм кануннары турында сөйләп бирде, һәм барысы да бертавыштан: «Без Раббының барлык сүзләрен үтәрбез», — дип җавап кайтарды.

4 Раббының барлык сүзләрен Муса язып алды, ә иртәгесен иртүк торып, тау итәгендә мәзбәх төзеде һәм Исраилнең һәр ыругыннан бер таш исәбеннән унике таш утыртып куйды.

5 Аннары Муса Исраил егетләрен корбанлык мал алып килергә җибәрде. Бу егетләр тулаем яндыру корбаннары китерделәр һәм үгезләрне, татулык корбаны буларак, Раббыга тәкъдим иттеләр.

6 Муса, бу хайваннарның канын алып, яртысын касәләргә

155 Муса тауга барганда кавеме эченнән житмеш ирне үзе белән алды. Ул ирләрне зилзилә тоткач, ягъни Аллаһуның тауга төшкән нуры белән көеп үлгәч, Муса әйтте: «Ий Раббым! Әгәр ул ирләрне вә мине һәлак итәргә теләсәң, әлбәттә, аларның миңа юлдаш булуларыннан элек һәлак итәр идең. Йа Раббы! Безләрдән гакылсызлар кылган эш өчен безне һәлак итәрсеңме? Аларның Сине күрергә теләүләре Үзең теләгән бер фетнә сынаудыр, аның белән Үзең теләгән кешене адаштырырсың вә Үзең теләгән кешене һидаятькә салырсың. Син генә безнең ярдәмчебезсең, безне ярлыка вә рәхмәт кыл! Син ярлыкаучыларның иң хәерлесесең!

156 Йа Раббы! Безгә һидаятьле күркәм тормышны насыйп ит! Һәм ахирәттә күркәм тормышны бир! Тәхкыйк, без Синең хөкемнәреңә итагать иттек, туры юлыңа күнелдек! Аллаһу Тәгалә әйтте: «Үзем теләгән кешегә газабымны ирештерермен һәм рәхмәтем дә киндер, һәрнәрсәне сыйдырды. Ул рәхмәтебезне көфердән вә Аллаһ хөкемнәрен бозудан сакланучы тәкъва кешеләргә





салды, ә калган яртысын мәзбәхкә чәчрәтте.

7 Муса төргәккә язылган Килешүне халыкка укыды, һәм кешеләр: «Без Раббының барлык сүзләрен үтәрбез һәм Аңа буйсынырбыз», — диделәр.

8 Шулчак Муса корбан канын халык өстенә чәчрәтте һәм әйтте: «Бу — Раббының сезнең белән төзегән Килешүне раслаучы кан. Шушы барлык сүзләр — Килешүнең нигезе».

9 Шуннан соң Муса, Һарун, Надаб, Абиһу һәм Исраилнең житмеш өлкәне тауга күтәрелделәр

10 һәм шунда Исраил Алласын күрделәр. Аның аяклары астында зәңгәр якуттан ясалган, аяз күк төсендә басма сыман бер нәрсә бар иде.

11 Исраилнең башлыклары Аллаһыны күрделәр, әмма Аллаһы, кулын сузып, аларга зыян китермәде, һәм алар ашадылар, эчтеләр.

12 Раббы Мусага: «Минем янга тауга күтәрел һәм шунда кал. Мин Үземнең канун һәм боерыкларымны, ике таш тактага язып, халыкка житкерү өчен, сиңа бирермен», — диде.

бик тиз бирербез, ул тәкъва кешеләр зәкятләрен бирерләр һәм Безнең аятьләребезгә ышанырлар.

157 Укый-яза белмәгән рәсүлебез — Мөхәммәт г-мгә ияргән кешеләргә рәхмәтебез ирешер, кулларындагы Тәүрат, Инжил китапларында рәсүлнең сыйфатлары язылганын табарлар, Мөхәммәт г-м аларны гөнаһлы эшләрдән тыяр вә сәваблы эшләргә өндәр, яхшы-пакь нәрсәләрне аларга хәләл кылыр, зарарлы-пычрак нәрсәләрне аларга хәрам кылыр, аларда булган авырлыкны вә диннәрендәге каты хөкемнәрне алардан бетерер, рәсүлгә ышанып аны зурласалар вә аңа ярдәм итсәләр һәм ул китергән һидаять яктылыгы булган Коръән хөкемнәренә иярсәләр, алар — өстенлек табучылар».

*Ун боерык*

**Канун 6**

4 «Тыңла, Исраил халкы! Раббы Аллабыз — бердәнбер Раббы.

5 Раббы Аллагызны бөтен йөрәгегез, җаныгыз белән, бар көчегезгә яратыгыз».

**Чыгыш 20**

12 «Ата-анаңны хөрмәт ит. Шулай эшләсәң, Раббы Аллаң сиңа бирәсе җирдә гомерең озын булыр».

**Чыгыш 21**

15 «Атасына яки анасына кул күтәргән һәркемнең җәзасы — үлемдер».

**Левиләр 19**

32 «Чәчләре чаларган өлкәннәр алдында урыныгыздан торыгыз, карт кешегә хөрмәт күрсәтегез. Аллагыздан куркып, Аны хөрмәт итегез. Мин — Раббы».

**Левиләр 19**

9 «Иген кырыгызда уңыш җыйган вакытта, басуның читенә кадәр житкереп урмагыз һәм урганнан калган башакларны да җыймагыз.

10 Бакчагыздагы йөземне дә соңгы җимешенә кадәр җыймагыз һәм җиргә коелганнарын да алмагыз: аларны фәкыйрьләргә һәм килмешәкләргә калдырыгыз. Мин — сезнең Раббы Аллагыз». <...>

ТӘҮРАТ

*Ун боерык*

**112 сүрә**

1 Әйт, әй Мөхәммәт: «Ул — Аллаһ — һич тиңдәше вә охшашы булмаган ялгыз бер генә Аллаһудыр».

**17 сүрә**

22 Ахирәт дәрәҗәләренә ирешергә теләсәң, «Аллаһуның тиңдәше бар» дип игътикад итмә! Әгәр мөшрик булсаң, җәннәт нигъмәтләреннән мәхрүм булып җәһәннәмдә рисвай булып утырырсың.

23 Аллаһ хөкем итте вә әмер бирде: фәкать Аллаһуга гына гыйбадәт кыйлырга һәм ата-анага игелек итәргә. Әгәр син исән чакта аларның берсе яки икесе дә картлыкка ирешсәләр, син аларга «уф» та димәгел вә каһәрләмә, кәефләрен җибәрмә, бәлки аларга һәрвакыт йомшак вә мөлаем сүзләр сөйләгел!

24 Вә аларга шәфкать итеп, рәхим канатларыңны җәйгел! Вә әйт: «Ий Раббым! Алар мине кечкенә чагымда мәрхәмәт белән үстергәннәре кебек, Син дә аларга дөньяда һәм ахирәттә шәфкать кыйл!»

25 Күңелләрегездә нинди ниятләр вә теләкләр барын Аллаһ белә, әгәр күңелләрегез яхшы булса, Аллаһ, әлбәттә,

КОРЪӘН





13 «Якыныңны рәнҗетмә һәм талама. Ялчыңа хезмәт хакын түләүне икенче көнгә калдырма».

**Зәбур 118**

36 Йөрәгемне күрсәтмәләреңә таба юнәлт, хәрәм малга ымсындырма мине.

**Лүк 12**

15 Шуннан соң һәммәсенә мөрәҗәгать итеп: «Карагыз аны, һәртөрле комсызлыктан сакланыгыз, чөнки кешенең гомере мал-мөлкәтенең күплегенә бәйләнмәгән», — диде.

**Яратылыш 9**

6 «Кеше канын койган адәмнең үз каны да кеше кулыннан коелыр. Чөнки кешене Аллаһы Үз сурәтендә яратты».

**Левиләр 24**

17 «Әгәр берәр кеше кемне дә булса үтерә икән, аны үлем җәзасы көтә».

**Чыгыш 20**

13 «Кеше үтермә.

14 Зина кылма.

15 Урлашма. <...>

17 Башка берәүнең өенә, хатынына, ир яки хатын-кыз колына, үгезенә яки ишәгенә — гомумән, кеше малына нәфесеңне сузма».

**Левиләр 19**

11 «Урлашмагыз, ялганламагыз, иптәшегезне алдамагыз. <...>

35 Озынлык, авырлык һәм күләмне үлчәгәндә, гадел булыгыз.

ТӘҮРАТ, ЗӘБУР, ИНҖИЛ

тәүбә итеп төзәлгән кешеләрне гафу итәдер.

26 Дәхи якын кардәшләрнең вә мескеннәрнең вә мөсафирләрнең хакларын бир! Әмма малыңны тиешсез җирләргә исраф итмә!

27 Тиешсез урынга малны исраф итүчеләр, әлбәттә, шайтан кардәшләредер, шайтан Раббысына кяфер булды.

28 Мохтаҗ кешеләр килеп синнән ярдәм сораганда синең бирергә һичнәрсәң булмаса, «Раббым рәхмәт итеп нигъмәт бирсә, сезгә дә бирер идем» дип алардан йөз дүндерсәң, ул вакытта йомшак сүзләр әйтеп күңелләрен табарга тырыш!

29 Мохтаҗларга садака бирүдә кулыңны муеныңа баглап куйма, сараннар кыяфәтендә шулай ук кулыңны бөтенләй ачып җибәрмә, ягъни үзеңә калдырмыйча бирип бетермә, әгәр киемеңә хәтле бирип бетерсәң, ул вакытта ялангач хәлеңдә үзеңне шелтәләп, хәсрәтләнеп утырырсың.

30 Тәхкыйк, Раббың теләгән кешесенә киң ризык биреп бай кылыр вә теләгән кешесен фәкыйрь кылыр; әлбәттә, Ул бәндәләрен күрә вә хәлләрен беләдер. Шуның өчен фәкыйрь кеше хәсрәтләнмәсен, сабыр итсен!

КОРЪӘН

36 Үлчәүләрегез, герләрегез һәм башка үлчәү әсбапларыгыз дөрес булырга тиеш. Мин – сезне Мисырдан алып чыккан Раббы Аллагыз».

**Гыйбрәтле сүзләр 16**

18 Горурлык – һәлакәткә, масаю хурлыкка илтә.

19 Тыйнак рухлы фәкыйрьләр белән аралашу тәкәбберләр белән табыш бүлешүдән яхшырак.

**Чыгыш 20**

3 «Сездә Миннән башка аллалар булмасын.

4 Үзегезгә һичнинди потлар ясамагыз. Югарыда, күктә, һәм түбәндә, җирдә, яисә җир асты суларында булган нәрсәләргә охшатып, сын-сурәтләр ясамагыз.

5 Аларга табынмагыз, сәҗдә кылмагыз, чөнки Мин, сезнең Раббы Аллагыз, бары тик Үземә генә тугры булып калуны таләп итүче Затмын. Миннән йөз чөергән аталарының гөнаһлары өчен өченче, дүртенче буынгача балаларына җәза бирүчемен.

6 Ә Мине яраткан һәм әмерләремне үтәгәннәрнең меңенче буынына кадәр мәрхәмәт күрсәтүчемен».



31 Фәкыйрь булудан куркып балаларыгызны үтермәгез! Балаларыгызны да, үзегезне дә Без ризыкландырырбыз, әлбәттә, үз балаларын үтерүләре гафу ителми торган хатадыр, зур гөнаһтыр.

33 Аллаһ үтерүне хәрам иткән кешене үтермәгез! Мәгәр үтерү тиеш булса гына үтерегез... Берәү хаксыз золым белән үтерелсә, үтерелгән кешенең вәлисенә ихтыяр бирдек, теләсә үтерүчене үтерсен, теләсә үтермичә мал алсын, теләсә гафу итсен! Ләкин бу эшләрдә чиктән үтмәсен, бер кеше урынына ике кешене үтермәсен, яки мал алса, тиешлесеннән артык алмасын! Тәхкыйк, ул варис Аллаһудан ярдәм бирелмеш булды.

34 Ятимнәр малына да якын бармагыз, ягъни аларның малыннан аз гына да файдаланмагыз, мәгәр ятимгә файда итү юлы белән аның малына катнашыгыз яки ятим тәмам үсеп гакылга утыргачны аның малына якын бармагыз! Вә гаһедләрегезне һәм вәгъдәләрегезне үтәгез, бозмагыз! Чөнки гаһедләрен бозган кешеләр кыямәт көнне соралачаклардыр.

35 Дәхи үлчәгәндә үлчәүләрегез дөрес булсын, тигез үлчәгез вә дөрес үлчи торган гадел мизаннар белән үлчәгез!







*Үгез бозау сыны*

**Чыгыш 32**

1 Инде күп вакыт узып та, Мусаның һаман да таудан төшмәвен күргәч, кешеләр Һарун тирәсенә җыелдылар һәм аңа: «Әйдә, безгә аллалар



Гадел үлчәсәгез, үзегезгә хәерледер вә ахыры да күркәм булыр.

36 Вә дәлилең, белемең булмаган нәрсәгә иярмә, ягъни дәлилсез гамәл дә кыйлма, хөкем дә итмә, фәтва да бирмә! Аллаһ биргән колак, күз, күңел – боларның һәрберсеннән кыямәт көнне сорау булыр, аларны сәвабле урыннарга гына кулланыгыз!

37 Җир өстендә зураеп күкрәк киереп йөрмә! Чөнки син никадәр зурайсаң да, җирне ертырга хәлеңнән килмәс һәм никадәр зурайсаң да, таулар хәтле зурая алмассың!

38 ...Аллаһ тыйган эшләрне эшләүче кеше явызлыгы белән Аллаһ хозурында яман кеше саналды.

39 Ошбу хөкемнәр Аллаһуның хикмәтеннән сиңа вәхи ителгән хөкемнәрдер. Аллаһ янына тагын бер нәрсәне Аллаһ итеп алма! Әгәр ул эшне эшләсәң, Аллаһуның рәхмәтеннән киселгән булырсың һәм шелтәләнгән хәлдә җәһәннәмгә ташланырсың.

*Үгез бозау сыны*

**7 сүрә**

148 Муса тауга киткәч, кавеме алтын-көмештән бозау ясады, ул бозауның тавышы бар иде, бозау шулай ясалган иде – аңарга җил кереп, эченнән

яса, алар безнең алдан барсыннар. Безне Мисырдан алып чыккан Мусага нәрсә булганны белмибез», — диделәр.

2 Һарун халыкка әйтте: «Хатыннарыгызга, угылларыгызга һәм кызларыгызга кидергән алтын алкаларны салдырып, миңа алып килегез».

3 Шуннан соң бар халык, алтын алкаларын салып, Һарунга алып килде.

4 Һарун халыктан алтынны алды, аны эретеп койды да кискеч ярдәмендә үгез бозау сынын ясады. Шулчак халык әйтте: «Әй Исраил токымы! Сине Мисыр җиреннән алып чыккан аллаң менә шушы!»

5 Һарун, моны күреп, бозау каршында мәзбәх төзеде һәм әйтте: «Иртәгә Раббы хөрмәтенә бәйрәм булыр».

6 Икенче көнне халык, бик иртә торып, тулаем яндыру корбаннары һәм татулык корбаннары китерде; соңыннан барысы утырып ашап-эчте дә күңел ачарга кереште.

7 Шулчак Раббы Мусага: «Тиз генә түбәнгә төш, Мисыр җиреннән алып чыккан халкың бозылды! — диде. —

8 Минем әмерләремнән алар бик тиз тайпылдылар, үзләренә үгез бозау сынын коеп, шуңа табындылар һәм корбаннар китерделәр, һәм халык әйтте:



тавыш чыга иде. Әллә алар күрмиләрме: бозау алар белән сөйләшми һәм аларны туры юлга күндерергә дә көче җитми. Гаҗәп, һичнәрсәгә ярамаган нәрсәне илаһ тоттылар һәм шуның өчен залим булдылар.

149 Аларның кулларына сугылгач һәм, шиксез, адашканлыкларын белгәч, әйттеләр: «Әгәр безгә Раббыбыз рәхмәт кылмаса һәм гөнаһларыбызны ярлыкамаса, әлбәттә, һәлак булучылырдан булырбыз!»

150 Муса, кавеме янына ачу вә кайгы белән кайткач, әйтте: «Мин киткәч нинди кабахәт эш эшләгәнсез! Раббыгызның эшендә ашыктыгызмы? Аллаһ вәгъдә кылган кырык көнне көтәргә күпсендегезме?» Вә ачуыннан кулындагы Тәүрат такталарын ташлады һәм кардәше Һарун г-мнең сакалыннан тотып үзенә тартты. Һарун әйтте: «Ий анам улы кардәшем! Тәхкыйк, бу кавем мине зәгыйфькә санады һәм бозау ясауларыннан тыйганым өчен мине үтерә башлады, минем өчен дошманнарны шатландырма вә мине залим кавемнәр җөмләсеннән санама!»

151 Муса әйтте: «Йа Раббы! Мине вә кардәшем Һарунны ярлыка вә безне рәхмәтеңә кергез!







„Әй Исраил токымы! Сине Мисыр җиреннән алып чыккан аллаң менә шушы!“»

9 Раббы Мусага янә әйтте: «Күрәм ки, бу халык үзсүзле.

10 Хәзергә син Мине калдырып тор. Ачу-ярсуымнан Мин аларны кырып бетерәм, ә соңыннан синнән бөек халык булдырам».

11 Әмма Муса Раббыдан, үз Алласыннан ялварып сорады: «Әй Раббы, Үзеңнең бөек көчең, кодрәтле кулың белән Мисыр җиреннән алып чыккан халкыңа ник шулай ачулысың?

12 Нишләп әле Син мисырлыларга: „Раббы Үз халкын усал ният белән — тауларда һәлак итеп, җир йөзеннән юкка чыгарыр өчен, Мисырдан алып киткән икән“, — дип әйтергә юл куясың?! Ярсуыңны чәчмә, үзгәрт карарыңны, Үз халкыңа афәт беләнянама!

13 Колларың Ибраһим, Исхак һәм Исраилне исеңә төшер — аларга Син Үз Затыңнан: „Нәселегезне күктәге йолдызлар санынча ишәйтермен. Вәгъдә иткән шушы җирләрнең бөтенесен нәсел варисларыгызга мәңгелек биләмә итеп бирермен“, — дип ант иттең».

14 Шуннан Раббы Үзенең карарын үзгәртте, һәм халыкка



Син рәхим кылучыларның иң рәхимлесесең!»

152 Бозауны Аллаһ (итеп) тотучыларга дөньяда Аллаһуның ачуы вә хурлык иреште. Әнә шулай җәза кылачакбыз «Аллаһуның тиңдәше бар» дип ифтира кылучыларны.

153 Бозык эшләрне эшләүчеләр, тәүбә итеп гамәл кылу нияте белән Коръәнгә иман китерсәләр, шуның соңында Раббың, әлбәттә, ярлыкаучы, рәхимле.

154 Мусаның ачуы басылгач, әүвәлдә атып ташлаган Тәүрат такталарын кулына алды. Ул Тәүратта Аллаһудан курыккан кешеләр өчен һидаятькә күнелү тәртипләре һәм Аллаһуның рәхмәте язылган иде.

**20 сүрә**

83 Аллаһ әйтте: «Ий Муса, кавемеңне калдырып ялгыз килергә сине нәрсә ашыктырды?» Чөнки Муса Тур тавына барганда үзе белән 70 кеше алган иде, тауга җиткәндә аларны арттарак калдырып үзе алданрак барды.

84 Муса әйтте: «Алар минем эземнән килделәр, әмма мин үзем, йа Раббы, Синең ризалыгыңны эстәп ашыктым».

85 Аллаһ әйтте: «Ий Муса, син киткәннән соң кавемеңне бәлаләндердек, Самири залим, бозауга табындырып, аларны адаштырды».

кылынасы афәт булмый
калды.
15 Ә Муса исә, боерыклар язылган әлеге ике таш тактаны
алып, таудан төште. Бу ташларның ике ягына да боерыклар язылган иде.
16 Бу таш такталарны Аллаһы Үзе ясап, әлеге боерыкларны
Үзе уеп язган иде. <...>
19 Станга якынлашкач, Муса үгез бозау сынын һәм биеп йөрүче халыкны күрде. Шунда Муса, ачуыннан ярсып, тау итәгендә такталарын җиргә атып бәрде, һәм алар чәлпәрәмә килеп ватылды.
20 Аннары Муса алар ясаган үгез бозау сынын алды да утка салды һәм алтынны, көл хәленә китереп, суга сибеп җибәрде, шуннан соң Исраил халкын шул суны эчәргә мәҗбүр итте. <...>
25 Муса күрде ки, Һарун кул астында исраилиләр тыеп булмас дәрәҗәдә йөгәнсезләнгән, дошманнарын сөендереп, тәмам мәсхәрәгә калган.
26 Муса стан капкасы алдына басты да әйтте: «Кем Раббы артыннан барырга тели, шулар минем янга килсен!» Барча левиләр Муса янына җыелдылар.
27 Муса аларга әйтте: «Исраилнең Раббы Алласы



86 Муса, кавеме эшләгән эш өчен кайгырып вә ачуланып, кавеме янына кайтты. Әйтте: «Ий кавемем, Раббыгыз сезгә „Тәүрат бирәм“ дип яхшы вәгъдә кылды түгелме? Мин сезгә, кырык көннән кайтам, дип вәгъдә биреп киттем, әллә сезгә шул кырык көн бик озын вакыт булдымы? Яки Аллаһуның ачуы вә газабы иңүен теләдегезме? Тәхкыйк, Аллаһуга гына гыйбадәт кылырбыз, дип миңа биргән вәгъдәгезгә хилафлык кылдыгыз».
87 Кавеме әйтте: «Без синең вәгъдәңә үз ихтыярыбыз илә хилафлык кылмадык, ләкин Мисырдан чыккан вакытыбызда Мисыр хатыннарының бизәк әйберләрен алган идек, ул бизәкләрне һәммәсен утка салып эреттек, Самири да Җәбраил атының эзеннән алган туфракны утка салды».
88 Һәм Самири шул эрегән бизәкләрдән бозау чыгарды, ул бозау сурәтендә бозау тавышы бар иде, һәм Самири вә аның иярченнәре әйттеләр: «Менә бу сезнең вә Мусаның илаһыдыр», – дип; вә бозауга гыйбадәт кыла башладылар һәм: «Бозау үзенең илаһы икәнлеген Муса онытты, тауга илаһ эзләп китте», – диделәр.







болай ди: „Һәркайсыгыз кылычын ассын да станның бер очыннан икенче очына узсын һәм үзенең туганын, дустын, якынын үтерсен“».
28 Левиләр Мусаның боерыгын үтәделәр, һәм шул көнне өч мең чамасы кеше һәлак булды. <...>
30 Икенче көнне иртән Муса халыкка әйтте: «Гөнаһыгыз зур сезнең! Әмма мин хәзер Раббы янына менәм, бәлки, гөнаһларыгызны кичерүен үтенә алырмын!»
31 Муса, Раббы янына әйләнеп кайтып, әйтте Аңа: «Әйе, бу халык зур гөнаһ эшләде. Алар үзләренә алтыннан алла ясадылар.
32 Хәзер Син аларның бу гөнаһын кичерсәң иде! Әгәр кичермисең икән, Үзең язган китаптан исемемне сызып ташла».
33 Раббы Мусага: «Китабымнан Мин Үземә каршы гөнаһ эшләүчеләрнең исемнәрен сызам.
34 Хәзер исә юлга кузгал һәм Мин әйткән урынга халыкны ияртеп кит, ә Минем фәрештәм алдыңнан барыр. Вакыты җиткәч, кылган гөнаһлары өчен Мин аларга җәза бирермен», – дип җавап кайтарды.



89 Аллаһ әйтә: «Әйә алар белмиләрме: бу бозау аларга һичнәрсә сөйләмәс, әгәр бозауның үзенә сөйләсәләр, җавап бирмәс вә аларга файда китерергә дә, зарар китерергә дә кадир булмас».
90 Муса таудан кайтмас борын Һарун әйткән иде: «Ий кавемем, сез ошбу бозау белән бәләләндегез, зинһар, аңа гыйбадәт итмәгез, хакыйкатьтә, сезнең Раббыгыз – рәхмәт иясе Аллаһу Тәгаләдер, миңа иярегез вә минем әмеремә итагать итегез!»
91 Кавеме Һарунга әйтте: «Муса кайткангача бозауга гыйбадәт кылудан туктамабыз».
92 Муса, кайткач, Һарунга әйтте: «Ий Һарун, кавемең бозауга табынып азган вакытта
93 миңа иярүдән сине нәрсә тыйды? Югыйсә минем әмеремә карыштыңмы?»
94 Муса ачуланды вә Һарунның сакалыннан тартты. Һарун әйтте: «Ий анамның угълы, сакалымнан тотмагыл һәм башымнан да тотмагыл, алар минем сүземне тыңламадылар, әгәр мин алар белән сугышсам яки аларны ташлап китсәм, алар төрле фиркага бүленерләр дә, „Ягъкуб балаларын ник аердың“ дип әйтүеңнән һәм „минем сүземне тотмадың“ дип ачулануыңнан курыктым».

35 Халык ясаган үгез бозау сы-
ны өчен, ягъни Һарун эшләп
биргән сын өчен, Раббы ис-
раилиләргә җәза җибәрде.

### *Күзәтчеләрнең Кәнган җиренә баруы*

**Саннар 13**

1 Аннары халык, Хасероттан
кузгалып, Паран чүленә җит-
те һәм шунда чатырларын
корып урнашты.



95 Муса Самиридән: «Ник бозау
ясадың?», — дип сорады.
96 Самири әйтте: «Ягъкуб ба-
лалары күрмәгән нәрсәне
мин күрдем, ул — Җәбраил
фәрештәдер, аның атының
аягы эзеннән бер уч туфрак
алдым, ул туфракны утта
эрегән бизәкләр өстенә ыр-
гыттым да бозау булды, шу-
лай эшләргә нәфесем яхшы
күрде».
97 Муса Самиригә әйтте: «Бар,
арабыздан кит, ләкин һич-
кемгә катнаша алмассың һәм
сиңа һичкем килә алмас, дө-
ньядагы газабың өстенә ахи-
рәттә дә сиңа газап вәгъдә
ителгән ки, аннан котыла
алмассың. Ий Самири, ка-
ра: „минем илаһым“ дигән
бозавыңны утта яндырабыз,
соңра көлен күккә очырабыз!
98 Бәлки барчагызның да гыйба-
дәт кылырга тиешле булган
илаһыгыз Аллаһу Тәгаләдер,
Аңардан башка һичбер илаһ
юк, мәгәр Ул Үзе генә. Аның
белеме һәрнәрсәдән киң бу-
лып, вөҗүдтә бар нәрсәне
белеме эченә сыйдырды».

### *Күзәтчеләрнең Кәнган җиренә баруы*

**5 сүрә**

20 Мусаның үз кавеменә әйт-
кән сүзләреннән гыйбрәт
алыгыз! Әйтте: «Ий каве-
мем, Аллаһ сезгә биргән





2 Раббы Мусага әйтте:
3 «Исраилиләргә Мин бирәсе
Кәнган җирләрен карап кай-
тыр өчен, кешеләр җибәр —
һәр ыругтан берәр җитәкче
барсын.
4 Муса, шулай итеп, Раббы күр-
сәтмәсе буенча, шул кеше-
ләрне Паран чүленнән Кән-
ганга җибәрде. <...>
26 Әлеге җирләрне үз күзләре
белән күргән исраилиләр
кырык көннән соң кире
кайттылар.
27 Паран чүлендәге Кадыш-
ка — Муса, Һарун һәм Ис-
раил халкы янына әйләнеп
кайткач, күзәтчеләр бөтен
күргән-белгәннәрен аларга
сөйләп бирделәр, шул җир-
дән алып кайткан җимеш-
ләрне күрсәттеләр.
28 Алар Мусага: «Син җибәргән
якларда булдык без, — диде-
ләр. — Ул җирдә чынлап та
сөт вә бал ага икән, менә ул
җирнең җимешләре.
29 Әмма ул җирдә яшәүче халык
көчле, шәһәрләре ныгытыл-
ган һәм бик зур; без анда
Анак угылларын да күрдек.
30 Амалыкыйлар — Нәгебтә, хит-
тиләр, явүсиләр һәм амори-
ләр — таулы илдә, ә кәнгани-
ләр исә диңгез буйларында
һәм Үрдүн елгасы тирәсендә
яши».
31 Мусаны әйләндереп алган ха-
лыкны тынычландырмакчы



нигъмәтләрне хәтерләгез!
Аллаһ арагызга күп пәйгам-
бәрләр күндерде, үзегездән
сезгә патшалар кылды һәм
галәмдә һичбер кавемгә бир-
мәгән нигъмәтләрне сезгә
бирде...»
21 Муса әйтте: «Ий кавемем,
Аллаһ билгеләгән һәм сез-
нең өчен файдасы булган
Әрихә шәһәренә керегез,
Аллаһ әмерен үтәүдән баш
тартмагыз, артка борылып
китмәгез! Әгәр баш тартса-
гыз, әлбәттә, нигъмәтләрдән
коры калып, хәсрәтләнүче
булып әверелерсез».
22 Әлеге куркак кабилә баш-
лыклары әйттеләр: «Ий Му-
са, Әрихә шәһәрендә көчле,
батыр кавем яши, без алар-
дан куркабыз, шул сәбәпле
шәһәргә һич тә кермәбез,
хәтта ул кавем чыгып кит-
кәннәренә чаклы. Әгәр алар
шәһәрдән чыгып китсәләр,
без, әлбәттә, шәһәргә керү-
чебез», — дип.
23 Кабилә башлыкларыннан
Аллаһ нигъмәтләгән икесе
әйттеләр: «Кяферләрдән ку-
рыкмагыз, Аллаһуга тәвәк-
кәл итеп шәһәр капкасыннан
керегез! Әгәр шәһәр капка-
сыннан керсәгез, кяферләрне
җиңәрсез. Аллаһуга тәвәккәл
кылыгыз һәм шәһәргә кере-
гез, әгәр Аллаһуның ярдәм
бирәчәгенә ышансагыз».

булып, Кәлеб: «Әйдәгез, һөҗүм итеп, ул җирне басып алыйк, бездә көч җитәрлек бит!» – диде.
32 Әмма аның белән бергә барганнар: «Без ул халыкка һөҗүм итә алмыйбыз, чөнки алар бездән көчлерәк», – диделәр
33 һәм үзләре карап кайткан җир турында исраилиләр арасында яман хәбәр тарата башладылар: «Без карап кайткан ул җир үзендә яшәүчеләрне йота икән, һәм анда яшәүчеләрнең барысы да зур гәүдәлеләр.
34 Без анда әзмәвердәй кешеләр күрдек (Анак угыллары әзмәверләр токымыннан иде). Алар янында без чикерткәләр кебек кенә идек. Алар да безне шундый итеп күрделәр».

**Саннар 14**

6 Кәнган җирен карап кайтучылардан Нун углы Ешуа һәм Ифунни углы Кәлеб, өсләрендәге киемнәрен ертып,
7 Исраил халкына: «Без карап кайткан җирләр искиткеч яхшы.
8 Әгәр Раббы бездән канәгать булса, сөт һәм бал агып торган шул җиргә алып барып, аны безгә бирер. Ул шундый җир ки, анда сөт вә бал ага.

ТӘҮРАТ

24 Кяферләрдән куркучылары әйттеләр: «Ий Муса, без Әрихә шәһәренә, әлбәттә, мәңге кермәбез, шәһәр халкы анда торган вакытта. Ий Муса, үзең һәм Раббың барыгыз, шәһәр кяферләре белән икәү сугышыгыз! Ә без шушы урында карап утырабыз», – дип.
25 Муса әйтте: «Ий Раббым, мин фәкать үземә һәм кардәшем Һарунга ихтыярлымын, башкага һич сүзем үтмидер. Ий Раббым, фасикъ белән безнең араны аер», – дип.
26 Аллаһ әйтте: «Инде аларга Әрихә шәһәренә керүне кырык елга чаклы хәрам кылдым. Кырык ел үтмичә анда керә алмаслар, хәйран булып сахрада адашып йөрерләр. Ий Муса, фасикъ кавем өчен кайгырма, инкяр кылсалар, җәзасы үзләренәдер», – дип.

КОРЪӘН





9 Тик Раббыга каршы баш күтәрмәгез һәм ул җирдә яшәүче халыктан курыкмагыз, чөнки без аларны икмәк ашагандай ашап бетерәчәкбез. Аларның яклаучысы юк инде, ә Раббы – безнең белән, шуның өчен алардан курыкырга кирәкми», – диделәр.
10 Әмма кешеләр: «Аларны таш атып үтерергә кирәк!» – диде. Шулвакыт Очрашу чатырында исраилиләр алдында Раббы шөһрәте пәйда булды. <...>
26 Раббы Муса белән Һарунга әйтте:
27 «Бу явыз халык кайчангача Миннән зарланыр икән?! Миннән зарланганда, исраилиләрнең нәрсә дип сукрануларын ишетәм Мин. <...>
34 Сез ул җирне кырык көн карап йөрдегез, һәм шул көннәр хисабынча, һәр көн өчен бер ел исәбеннән, ягъни кырык ел дәвамында, гөнаһларыгыз өчен михнәт чигәчәксез. Менә шуннан соң инде Минем тарафтан кире кагылуның нәрсә икәнлеген яхшы беләчәксез.
35 Мин – Раббы, һәм Миңа каршы баш күтәргән бу явыз халыкка нәкъ әйткәнемчә эшләячәкмен; бу чүлдә аларның һәммәсе һәлак булачак һәм үлеп бетәчәк».

ТӘҮРАТ

### *Корахның баш күтәрүе*

**Саннар 16**

1 Леви углы Коһат тудырган Исһарның углы Корах һәм Рубин ыругыннан Элиаб угыллары Датан вә Абирам белән Пелет углы Он

2 Мусага каршы баш күтәрделәр. Исраил халкының ике йөз юлбашчысы да аларга кушылды. Әлеге юлбашчылар халык арасында дан казанган, дәрәҗәле кешеләр иде.

3 Муса белән Һарунга каршы чыгып, алар әйттеләр: «Җитәр сезгә! Халкыбызның һәр кешесе изгедер, һәм Раббы – халык арасындадыр. Ни өчен сез үзегезне Раббы халкыннан өстен куясыз?!»

4 Моны ишеткәч, Муса йөзе белән җиргә капланды.

5 Корахка һәм аның тарафдарларына ул: «Иртәгә таңда Раббы кемнең Аныкы һәм изге булуын, кемгә Раббыга якынлашырга яравын күрсәтер. Раббы кемне сайлап алса, шул Аңа якынлаша алыр... <...>

11 Син һәм синең тарафдарларың Раббыга каршы баш күтәрәсез. Һарунга нәрсә булган, сез нигә аңа карата ризасызлык белдерәсез?!»

12 Аннары Муса Элиаб угыллары Датан белән Абирамны чакырырга кеше җибәрде,



### *Карунның баш күтәрүе*

**28 сүрә**

76 Тәхкыйк, Карун Муса кавеменнән вә аңа иман китергән кешеләрдән иде, Ягъкуб балаларына золым итте һәм байлыгы белән олугъланды; Без аңа күп байлык бирдек ки, аның хәзинә сарайларының ачкычларын күтәрмәк куәт ияләре булган җәмәгатькә дә авыр булыр иде. Кавеме Карунга әйтте: «Малың күплеге белән мактанып шатланма, тәхкыйк, Аллаһ мал белән шатланучыларны сөймидер.

77 Бәлки Аллаһ биргән малны Аллаһ юлына биреп ахирәтне кәсеп ит, дөньядан үз өлешеңне онытма, ахирәтең өчен гамәл кыл, Аллаһ сиңа ихсан кылып мал биргән кеби, син дә мохтаҗ кешеләргә малыңнан бир, җир өстендә явызлык белән фәсадлык кыйлып йөрмә, тәхкыйк, Аллаһ фәсадчыларны сөймидер».

78 Карун әйтте: «Миңа бу мал белемемнең күплеге өчен бирелде», – дип. Аллаһ әйтте: «Галим булса, белмиме моннан элек Аллаһ күпме җәмәгатьне Аңа карышканнары өчен һәлак итте; ул һәлак булган кешеләр куәттә Каруннан артыграк вә җыйган







әмма алар: «Синең алдына бармыйбыз! – дип җавап кайтарды. –

13 Безне сөт вә бал агып торган җирдән алып чыгып, чүлдә үтерергә ният коруың җитмәгәнме?! Инде хәзер безнең өстән хакимлек итмәкче буласыңмы?!

14 Син безне сөт вә бал агып торган җиргә алып бармадың, безгә кырлар, йөзем бакчалары бирмәдең. Син бу кешеләрне алдарга телисеңме?! Синең алдыңа бармыйбыз без!»

15 Муса, бик нык ачуы чыгып, Раббыга әйтте: «Алар китергән бүләкләргә күзеңне дә салма. Мин аларның һичберсенә явызлык эшләмәдем, һичберсенең хәтта ишәген дә алмадым».

16 Корахка Муса: «Иртәгә син үзең дә, барча тарафдарларың да Раббы алдында булыгыз. Һарун да шунда килер.

17 Ике йөз илле юлбашчының һәммәсе үзенең сумала-майлар көйрәтү савытын алсын да, эченә хуш исле сумала-майлар салып, Раббы каршына китерсен. Син дә үзеңнең савытыңны алып кил, Һарун да алып килер». <...>

23 Раббы Мусага болай диде:

24 «Халыкка әйт: „Корах, Датан һәм Абирамның торак



маллары күбрәк иде, фәсадчы залимнәр кыямәт көнендә гөнаһларыннан соралмаслар, хисапсыз җәһәннәмгә кererләр».

79 Карун беркөнне йөгән-иярләре алтын белән зиннәтләнгән атка атланып кавеменә чыкты, дөнья тереклеген генә теләүчеләр әйттеләр: «Карунга бирелгән байлык кеби безгә дә бирелгән булса, нинди яхшы булыр иде, ул Карун дөньяга олуг насыйп иясе», – дип.

80 Белем бирелмеш кешеләр дөньяны сөючеләргә әйттеләр: «Үкенеч булсын сезгә, иман китереп изге гамәлләр кылган кешеләргә Аллаһ вәгъдә иткән җәннәт нигъмәтләре Карунга бирелгән малдан хәерлерәктер, ул җәннәткә ирешмәс һичкем, мәгәр сабыр итеп Аллаһ юлында яшәгән хак мөэминнәр ирешерләр», – дип.

81 Без ул Карунны һәм йортын җиргә йоттырдык, чөнки Карун, байлыгына таянып, Мусаны күп җәберләде. Шул вакытта Аллаһудан башка Карунга ярдәм бирүче булмады, һәм җир астына китүдән үзен-үзе дә саклый алмады.

82 Әле күптән түгел генә Карунның дәрәҗәсен өмет итүче кешеләр Карунның йорты белән җир астына киткәнен

урыннарыннан читкәрәк
китегез“».
25 Муса торды да Датан белән
Абирамга таба юнәлде, аның
артыннан Исраил өлкәннәре
дә иярде.
26 Муса халыкка: «Бу яман ке-
шеләрнең чатырларыннан
ерактарак торыгыз һәм, гө-
наһлары аркасында һәлак
булмас өчен, аларның һич-
нәрсәсенә дә кагылмагыз».
27 Корах, Датан һәм Абирам ча-
тырларыннан халык читкә
китте. Датан һәм Абирам
исә хатыннары, угыллары
вә кечкенә балалары белән
чатырлары алдына чыгып
бастылар.
28 Муса әйтте: «Менә хәзер сез,
бу эшләрне башкару өчен,
мине Раббы җибәргәнне бе-
лерсез – мин бит боларны
үз теләгем белән эшләмим.
29 Әгәр алар барлык кешеләр
кебек табигый үлем белән
үлеп китсә һәм аларның яз-
мышы башкалар язмышы
кебек булса, димәк, мине
Раббы җибәрмәгән дигән сүз.
30 Әмма инде Раббы, гадәттән
тыш хәл кылып, җир ярылса
һәм аларны бар мөлкәте бе-
лән бергә йотса, алар терелә
үлеләр дөньясына убылып
төшсә, димәк, болар – Раб-
бына кире каккан кешеләр».
31 Мусаның шушы сүзләрне әй-
теп бетерүе булды, тегеләр-



күреп тордылар вә әйтер бул-
дылар: «Гаҗәп бу эш безгә
шөбһәле булды, Аллаһ, сы-
нар өчен, теләгән бәндәсенә
киң ризык вә теләгән бәндә-
сенә тар ризык бирер икән,
әгәр Аллаһ, без теләгәнчә,
Карун малы кеби малны без-
гә дә биргән булса, әлбәттә,
без дә Карун белән бергә җир
астына киткән булыр идек;
вәй, Карунның эше үкенечле
булды! Аллаһыга карышып
көфран нигъмәт кылучылар
Аллаһ газабыннан котыла
алмаслар икән ләбаса», – дип
әйттеләр.
83 Без ахирәтне, иман ките-
рүдән вә Аллаһуга итагать
итүдән олугъланмаган һәм
җир өстендә бозыклык фә-
сад кыйлмаган хак мөэмин-
нәр файдасына кылырбыз,
эшенең ахырындагы уңыш,
ахирәттәге бәхет Аллаһуга
карышудан гөнаһлы булу-
дан сакланучы мөэминнәр-
гәдер.
84 Берәү Аллаһ риза булырдай
яхшылык белән барса ахи-
рәткә, аңа Аллаһу хозурында
хәерлерәк күбрәк нигъмәт
булыр, берәү күп гөнаһ бе-
лән яман кеше булып барса,
андый кешеләр фәкать бо-
зык эшләренә каршы каты
хөкем, каты газап белән җә-
заланырлар.







нең аяк астында җир ярылып
та китте;
32 һәм, авызын ачып, аларның
үзләрен, гаиләләрен, Корах-
ның барлык тарафдарларын
һәм бөтен малларын йотты.
33 Алар бар мөлкәте белән бергә
үлеләр дөньясына терелә
убылып төштеләр; упкын
авызы ябылды, һәм алар,
шушылай итеп, халык ара-
сыннан юк булдылар.
34 Әйләнә-тирәдәге бар халык,
тегеләрнең ачы тавышын
ишетүгә: «Безне дә җир йот-
магае!» – дип кычкыра-кыч-
кыра качып киттеләр.
35 Хуш исле сумала-майлар ки-
тергән теге ике йөз илле ке-
ше дә Раббы индергән уттан
һәлак булды.

## Шаул патша

**I Патшалар 8**
4-5 Шуннан Исраил өлкәннәре,
җыелып, Шемуил янына Ра-
маһка килделәр һәм: «Үзең
олыгайдың инде, угылларың
исә синең юлыңнан тайпыл-
дылар; димәк, безнең өстән
патша билгеләсәң, кулайрак
булыр иде, башка халыклар-
да кабул ителгәнчә, безнең
белән патша идарә итсен», –
диделәр.
6 Өлкәннәрнең «Безнең өстән
патша куй, безнең белән ул
идарә итсен» дигән сүзләре
Шемуилгә ошамады, һәм ул
Раббыга дога белән мөрәҗә-
гать итте.
7 Раббы аңа болай дип җавап
бирде: «Халык сүзенә колак
сал, алар кушканның бары-
сын да эшлә, чөнки аларның
әлеге гамәлләре синнән түгел,
ә бәлки нәкъ менә Миннән
баш тартулары хакында сөй-
ли; алар үзләре өстеннән Ми-
нем патшалык итүне теләми.
8 Мин аларны Мисырдан алып
чыккан көннән башлап бү-
генгәчә халык һаман үзе-
некен эшли – Мине читкә
тибәреп, башка илаһларга
табына. Синең белән дә нәкъ
шулай ук эш кылулары.
9 Димәк, аларның гозеренә ко-
лак сал, әмма үзләре өстен-
нән идарә итәчәк патшаның

## Талут патша

**2 сүрә**
246 Муса пәйгамбәрдән соң Ягъ-
куб балаларыннан бер җә-
мәгатьнең хәлен белдеңме?
Алар үзләренең пәйгамбәре
Юшагъ г-мгә әйттеләр: «Без-
гә патша билгеләә, без аңа
буйсынып Аллаһ юлында
кяферләр белән сугышыр
идек», – дип. Юшагъ әйтте:
«Әгәр сезгә сугыш фарыз
ителсә, ихтимал, сугышмас-
сыз, карышырсыз», – дип.
Алар әйттеләр: «Безгә ни
булган Аллаһ юлында су-
гышмаска? Чөнки без шул
кяферләр тарафыннан йорт-
ларыбыздан чыгарылдык һәм
балаларыбыздан аерылдык;
әлбәттә, сугышачакбыз».
Кайчан аларга кяферләр бе-
лән сугышу фарыз ителде,
алар сугыштан баш тартты-
лар, мәгәр бик азлары баш
тартмады, гайрәт белән су-
гышты. Аллаһ сугыштан баш
тарткан залимнәрне белә.
247 Пәйгамбәрләре әйтте: «Аллаһ
сезгә Талутны патша кылды».
Алар пәйгамбәргә әйттеләр:
«Кайда инде ул Талутка без-
нең өстән патша булу, патша
булу өчен без хаклырак, чөн-
ки Талутка малдан байлык
бирелмәгән». Пәйгамбәрләре
әйтте: «Аллаһ сезгә Талутны
патшалыкка ихтыяр кылды.





хокуклары турында аларны
алдан ук кисәтеп куй».

**I Патшалар 10**
17 Шемуил бөтен Исраил халкын
Миспага – Раббы каршына
чакырып китерде
18 һәм Исраил угылларына болай
дип мөрәҗәгать итте: «Исра-
илнең Раббы Алласы болай
дип әйтә: „Мин, Исраилне
Мисырдан алып чыгып, сез-
не мисырлылар һәм сезне
золымлыкка салган башка
патшалыклар җәбереннән
йолып алдым.
19 Бүгенге көндә исә сезне бә-
ла-казалардан йолып алган,
кайгы-хәсрәтләрдән коткар-
ган Аллагыздан йөз чөереп,
юк, безнең өстән патша куй,
дип сорыйсыз. Инде шулай
икән, ыругларга бүленеп, нә-
сел-нәсел булып Раббыгыз
каршына килеп басыгыз“».
20 Шуннан Шемуил Исраилдәге
бөтен ыругларны чакырып
алды һәм, нәтиҗәдә, Бень-
ямин ыругы сайланды.
21 Аннары, Беньямин ыругына
кергән нәселләрне аерым-ае-
рым үз янына чакырганнан
соң, Матри нәселенә тук-
талдылар; ахырдан Кыйш
углы Шаул сайланды. Әмма
Шаулны эзли башлаганнар
иде – таба алмадылар.
22 Алар: «Шаул бирегә килде-
ме соң?» – дип, Раббыдан
сорадылар. Раббы: «Монда

Патша булу өчен бай булу
шарт түгел, бәлки гакыл-
лы, галим булу шарт. Аллаһ
үзенең байлыгын теләгән
бәндәсенә бирер, Аллаһ –
киңлек һәм белем иясе».
248 Пәйгамбәрләре әйтте Талут-
ның Аллаһудан билгеләнгән
патша икәнлеген: «Аллаһу-
дан бер сандык килер, аның
эчендә күңелләрегез карар
(шатлык) табардай нәрсәләр
булыр – Муса илә Һарунның
гаиләләре калдырган Муса
г-мнең таягы, чалмасы, ча-
паны һәм башка нәрсәләр
булыр, ул сандыкны фәреш-
тәләр алып килер. Аллаһудан
сезгә бу сандыкның килүен-
дә, шиксез, Талутның патша
икәнлегенә галәмәт бар, әгәр
бу галәмәтнең Аллаһудан
булуына ышансагыз...»

ул, олаулар арасына кереп
поскан», – дип җавап бирде.
23 Йөгереп барып, Шаулны кач-
кан җиреннән алып чыкты-
лар. Үзен әйләндереп алган
төркем уртасында басып кал-
ган Шаул бөтен кешедән бер
башка биегрәк иде.
24 Җыелган халыкка Шемуил:
«Күрәсезме, Раббы кемне
сайлап алды?! Бөтен халык
арасында аңа тиң булырдай
кеше юк!» – диде. Бар халык
шунда: «Яшәсен патша!» –
дип кычкырып җибәрде.
25 Шемуил халыкка патша ида-
рәсенең хокук-кагыйдәләрен
аңлатты; аңлатканнарын ки-
тапка теркәп куйгач, китап-
ны Раббы каршына илтеп
салды да халыкка өйләренә
таралышырга кушты.
26 Шаул да үз өенә – Гибгага
юнәлде; күңелләренә Аллаһы
кагылып узган кыю йөрәкле
ир-егетләр дә аның артын-
нан иярде.
27 Әмма җәнҗал сөючеләр: «Ни-
чек итеп бу кеше безне кот-
кара алыр икән?!» – дип,
үзләренең канәгатьсезлеген
белдерделәр һәм Шаулга бү-
ләкләр китерүдән баш тарт-
тылар, ләкин Шаул болар-
ның берсен дә игътибарга
алмады.

**I Патшалар 6**

13 Бәйт-Шемеш халкының үзән-
дә бодай урып яткан чагы





иде. Раббы сандыгын күреп,
алар бик сөенделәр.
14 Арба Бәйт-Шемештә яшәүче
Ешуа атлы адәмнең басуы-
на килеп җитте дә зур бер
таш янында туктап калды.
Бәйт-Шемеш халкы, арбаны
утынга чапкалап, сыерларны
тулаем яндыру корбаны була-
рак Раббыга багышлады. <...>
19 Раббы сандыгы эченә күз
салган өчен, Аллаһы шун-
да Бәйт-Шемешнең җитмеш
кешесен үтерде. Шул сәбәп-
ле халык кычкырып еларга
тотынды, чөнки Раббының
җәзасы аяусыз иде.
20-21 Шушы вакыйгадан соң
Бәйт-Шемеш халкы: «Әле-
ге Изге Аллаһының, Раб-
бының хозурында кем тора
алыр икән?! Ул бездән соң
кем янына барыр?» – дип,
Кыръят-Ягаримгә үзенең ил-
челәрен җибәрде. Илчеләр,
алар янына килеп: «Пелешет
халкы Раббы сандыгын кире
кайтарды. Килеп, үзегезгә
алып китегез аны», – диде.

## Гидеон һәм аның сугышчылары

**Хакимнәр 7**

2 «Сугышчыларың артык күп синең, – диде Гидеонга Раббы, – алар кулына мидьяниләрне тапшыра алмыйм мин. Югыйсә исраилиләр: „Без үзебезне үз көчебез белән коткардык“, – дип, Минем алда борыннарын чөеп йөрер иде.

3 Халкыңа җиткер: куркып һәм калтырап торучылар Гилыгад тауларын ташлап өенә кайтып китсен!» Шуннан егерме ике мең гаскәри кайтып китте, ун меңе исә сугыш кырында калды.

4 «Халкың һаман да күп әле, – диде Гидеонга Раббы, – аларны чишмә буена алып кил, шунда Мин сиңа сайлап бирермен...

5 Гидеон үзенең кешеләрен чишмә буена алып килгәч, Раббы аңа: «Суны эт кебек ялап эчүчеләр бер якка бассын, тезләнеп эчүчеләр икенче якка бассын», – диде.

6 Суны ялап эчүчеләрнең саны өч йөз булды; калганнары исә суны тезләнгән килеш учына алып эчте.

ТӘҮРАТ

## Талут һәм аның сугышчылары

**2 сүрә**

249 Талут гаскәр белән шәһәрдән чыгып сәфәргә киткәндә гаскәргә әйтте: «Аллаһ сезне бер елга белән сыный, мин әйткәнчә эш кылыгыз, шул елгадан су эчкән кеше миннән аерылып калыр, фәкать су эчмәгән кеше генә минем белән сугышка барыр, яки учы белән алып бер мәртәбә генә эчкән кеше миңа юлдаш булыр». Әмма күбесе елгадан туйганчы су эчтеләр, мәгәр бик азлары гына эчмәде. Талут һәм аның белән бергә су эчмичә калган мөэминнәр арасыннан кайберләре шул елганы үтеп киткәч әйтте: «Кяфер гаскәренә безнең көчебез җитмәс, Җалутка һәм аның гаскәренә каршы тора алмабыз, чөнки аларның саны бик күп, әмма безнең саныбыз бик аз». Ахирәттә Аллаһыга юлыгачакларын белгән галим мөэминнәр әйттеләр: «Күп вакытта аз санда булган мөэминнәр Аллаһ ярдәме белән күп санда булган кяферләрне җинделәр түгелме?..» Аллаһы Тәгалә сугышларда батырлык күрсәткән чыдамлы мөэминнәр белән бергә.

КОРЪӘН



## Давыт патша

*Давыт һәм Галиат*

**I Патшалар 17**

4 Гәт шәһәрендә яшәүче, буе алты терсәк вә бер карыш булган Галиат атлы көрәшче пелештиләр арасыннан алга чыкты.

5-6 Аның башында – җиз очлым, өстендә – балык тәңкәләре сыман итеп эшләнгән, авырлыгы биш мең шәкылга тәңгәл бакыр көбә, аягында – бакырдан коелган тез каплагычлары, аркасында – кыска саплы сөңге.

7 Сөңгесенең сабы туку күшәсе сыман, тимер очлыгы исә алты йөз шәкылга тиң иде. Корал йөртүчесе, Галиатның калканын тотып, аның алдыннан атлады. <...>

49 Аннары кулын биштәренә тыгып бер таш алды да теге ташаткыч каеш ярдәмендә Галиатка томырды. Таш нәкъ аның маңгаена туры килеп яньчеп керде, һәм Галиат йөзе белән җиргә ауды.

50 Шул рәвешле, Давыт, Пелешет баһадирын ташаткыч вә бер таш ярдәмендә җиңеп, аны теге дөньяга озатты; алышка чыкканда, Давытның кулында кылыч юк иде.

51 Шуннан Давыт йөгереп килеп Галиат өстенә аягын куйды

ТӘҮРАТ

## Давыт патша

*Давыт белән Җалут*

**2 сүрә**

250 Мөэминнәр Җалутка һәм аның гаскәренә якын килгәч әйттеләр: «Ий Раббыбыз, безгә сабырлык, батырлык бир һәм аякларыбызны нык беркет һәм кяфер кавемен җиңәргә ярдәм бир».

251 Аз санда булган мөэминнәр, Аллаһы ярдәме белән, күп санда булган кяфер гаскәрен җинделәр, һәм Давыт кяферләрнең башлыгы Җалутны үтерде. Аллаһы Давытка байлык һәм пәйгамбәрлек бирде һәм аңа үзе теләгән нәрсәләрне өйрәтте. Әгәр Аллаһ кешеләрне якламаса иде, әлбәттә, җирдәге кешеләр һәммәсе һәлак булыр иделәр. Ләкин Аллаһ барча галәмнәр мәхлугына рәхмәт иясе.

252 Бу сөйләгән кыйссалар – Аллаһуның аятьләре, ий Мөхәммәт г-м, аны сиңа хаклык белән укыйбыз, әлбәттә, син рәсүлләрдән.

КОРЪӘН

һәм, аның кынысыннан
кылычын тартып чыгарып,
башын чабып өзде. Баһадир-
ларының җан бирүен күргәч,
пелештиләр кача башлады.

***Сарыклар турында гыйбрәтле хикәя***

**II Патшалар 12**
1 Беркөн Раббы Давыт янына
Натанны җибәрде, һәм ул,
Давыт янына килеп, болай
диде: «Бер шәһәрдә ике ке-
ше яшәгән, аның берсе бай,
икенчесе ярлы булган.
2 Байның вак һәм эре терлеге
бихисап күп икән.
3 Ярлының исә үзе сатып ал-
ган сарык бәрәненнән баш-
ка нәрсәсе булмаган. Әлеге
бәрән аның балалары белән
бергә үскән; хуҗасы аны кы-
зы урынына баккан. Сарык
бәрәне хуҗасы ашаганны
ашаган, аның савытыннан
эчкән һәм аның күкрәгендә
йоклаган.
4 Беркөн бай янына бер юлчы
килгән дә, бай кеше, әле-
ге юлчыга ашарга әзерләр
өчен, үзенең сарыгын яисә
үгезен суярга кызганып, те-
ге ярлының бәрәнен чалган
һәм бусагасына аяк баскан
юлчы адәмгә ризык хәстәр-
ләгән».
5 Давытның әлеге байга бик
нык ачуы чыгып, Натанга
ул: «Раббы Үзе шаһиттыр:



***Сарыклар турында гыйбрәтле хикәя***

**38 сүрә**
17 Ий Мөхәммәт г-м, аларның
үз зарарларына сөйләгән
сүзләренә сабыр ит! Безнең
колыбыз Давытны сөйлә, ул
гыйбадәттә куәт иясе иде,
көн аша рузә тотып гыйбадәт
кылыр иде; вә һәр мәкрүһ
эшләрдән тәүбә итеп Алла-
һуга кайтучыдыр.
18 Без Давыт пәйгамбәргә зекер-
дә тауларны иярттек, аның
белән бергә иртә вә кич тәс-
бих әйтерләр иде.
19 Вә кошларны да зекердә аңа
иярттек, һәммәсе аның яны-
на җыелып тәсбих әйтерләр
иде. <...>
21 Ий Мөхәммәт г-м, сиңа ике
дәгъвачының Давыт яны-
на хөкем иттерергә килгән
хәбәрләре ирештеме? Алар
килеп михрабтан мәсҗиднең
эченә үттеләр.
22 Алар кеше сурәтендә Давыт
янына кергәч, Давыт, бу ке-
шеләр кайдан керделәр, дип
курка калды, чөнки ишек-
ләрдә көчле сакчылар бар
иде. Кеше сурәтендәге фә-
рештәләр әйттеләр: «Син







моны эшләгән кеше үләргә
тиеш!
6 Кылган гамәле вә миһербан-
сызлыгы өчен бәрән бәясен
аңардан дүртләтә түләтергә
кирәк!» — диде.
7 Шунда Натан Давытка: «Әле-
ге кеше — син ул! — диде. —
Исраилнең Раббы Алласы
менә нәрсә ди: „Мин сине,
башыңа май сөртеп, Исраил
патшасына ихтыяр кылдым,
Мин сине Шаул кулыннан
йолып алдым.
8 Мин сиңа әфәндеңнең йор-
тын, хатыннарын бирдем,
Исраил белән Яһүдә пат-
шалыгын сиңа тапшырдым;
әгәр болар аз тоелган булса,
тагын да күбрәк өстәп бирер
идем.
9 Раббы сүзенә илтифат итмичә,
ни өчен син шундый яман-
лык кылдың? Хитти Урияне
син, аммониләр кылычын-
нан үтертеп, аның хәләл
җефетен үзеңә хатынлыкка
алдың.
10 Мин кушканнарны санга
сукмыйча, хитти Урия-
нең хатынын үзеңә алган
өчен, синең йортың өстен-
дә мәңге кылыч эленеп то-
рыр“.
11 Раббы тагын болай ди: „Бә-
хетсезлекне Мин сиңа үз
йортыңда бирермен. Синең
күз алдыңда, хатыннарың-
ны синнән тартып алып,



бездән курыкма, без ике
дәгъвачыларбыз, беребез
икенчебезгә золым итмеш-
тер, арабызны хаклык белән
хөкем ит, безгә золым итмә
һәм бу эшебездә безне туры
юлга сал!»
23 Аларның берсе әйтте: «Ме-
нә бу иптәшем диндә ми-
нем кардәшемдер, аның 99
сарыгы бар, минем исә бер
генә сарыгым бар, шул бер
сарыгыңны миңа бир, дип
минем белән низаг кыла, вә
сүзендә мине җиңде, минем
ни әйтергә дә хәлем калма-
ды», — дип.
24 Давыт әйтте: «99 сарыгы була
торып синең бер сарыгыңны
сорап сиңа золым иткән. Ур-
таклык илә эш кылучылар,
әлбәттә, бер-берсенә золым
итәрләр, мәгәр иман китереп
изге гамәлләр кылган мөэ-
миннәр золым итмәсләр, лә-
кин андый кешеләр аздыр».
Фәрештәләр, бу сүзләрне
ишеткәч, Давыт үз зарарына
хөкем итте дип, күккә ашты-
лар. Давыт эшне анлады: бу
ике фәрештәнең аны сынар
өчен һәм тәнбиһ итәр өчен
килгәннәрен белде, Раббы-
сыннан гафу сорады вә сәҗ-
дәгә китте һәм тәүбә итте.
25 Ярлыканырга теләгән хата-
сын гафу иттек, вә кыямәт
көнендә аңа Безгә якын булу
һәм күркәм урын бардыр.

якыныңа бирермен, һәм ул көпә-көндез алар белән ятып йоклар.
12 Син моны яшертен эшләдең, мин исә бөтен Исраил алдында, көн күзендә эшләрмен“».
13 «Раббы каршында гөнаһым чиксез минем!» — диде Давыт Натанга. Аңа җавап итеп Натан: «Раббы синең гөнаһыңны кичерә, җаныңны кыймый, — диде. —
14 Ләкин шушы ялгыш гамәлең белән син дошманнарына Раббыны санламаска юл куйдың; шуның өчен синең туачак углың үләр».
15 Шуннан Натан үз өенә юнәлде. Раббы исә Урия хатыны тапкан балага зыян салды, һәм сабый авырый башлады.

*Давытның иманы*

**Зәбур 97**

8 Елга-дәрьялар алкышлап кул чапсын, таулар гөрелдәшеп сөенсен.

**Зәбур 148**

7 Раббыны данлагыз, әй җир йөзендәгеләр, диңгездәге җанварлар, төпсез чоңгыллар,
8 яшен-ялкыннар, боз бөртекләре, төтен-болытлар, Раббы сүзен гамәлгә ашыручы давыллы җилләр,
9 барлык таулар һәм калкулыклар, барлык җимеш вә эрбет агачлары,



26 Ий Давыт, Без сине җир өстенә хәлифә кылдык, кешеләр арасында хаклык илә хөкем ит, нәфес һавасына иярмә, әгәр иярсәң, ул нәфес сине Аллаһ юлыннан адаштырыр. Бит Аллаһ юлыннан адашканнаргадыр каты газап, кыямәт көнне булачак хисапны онытып, фарыз, важиб гамәлләрне калдырып хәрам эшләрне эшләгәннәре өчен.

*Давытның иманы*

**21 сүрә**

78 Вә Давыт илә Сөләйманны да хәтерләгез: бер кешенең игенен башка кешенең куйлары, кич белән кереп, ашап вә таптап юкка чыгарган иделәр; шул хакта алар икесе хөкем иттеләр, вә без аларның хөкеменә шаһит булдык.
79 Иген хакында дөрес хөкем итүне Сөләйманга аңлаттык... Аларның һәр икесенә файдалы белем вә шәригать хөкемнәрен бирдек вә Давытка тауларны һәм кошларны





10 киек-җәнлек вә терлек-хайваннарның һәр төре, сөйрәлүчеләр вә канатлы кошлар.

**Зәбур 108**

1 И Аллаһы, Сиңадыр мактау сүзләрем! Җавапсыз калма!
2 Чөнки яманнар, мәкерлеләр миңа каршы авызларын ачтылар, минем өскә ялган яудыралар.
3 Нәфрәт тулы сүзләре чолгап алды мине, миңа каршы сәбәпсез сугыш ачтылар.
4 Яхшы мөнәсәбәтемә каршы миңа яла ягалар, ә мин һаман догадамын.
5 Яхшылыгыма — явызлык, дуслыгыма нәфрәт белән җавап кайтаралар,
6 минем турыда әйтәләр: «Раббы аны яман бер адәм кулына тапшырсын, уң ягында аның яла ягучы утырсын,
7 мәхкәмәдә ул гаепле дип табылсын, догасы гөнаһ булып саналсын... <...>
17 Каргау-каһәрләүне үз итте ул — каһәре аның үз башына төшсен! Хәер-фатиха бирергә теләмәде — фатихадан мәхрүм ителсен!
18 Каргау-каһәрләү аның өс киеме булсын, су кебек эченә керсен, зәйтүн мае кебек сөякләренә сеңсен!
19 Әйдә, өстенә кигән киеме булсын ул аңа, билен бәйли торган бер пута булсын!» — диләр.



ияртек, Давыт белән бергә тәсбих әйтерләр иде. Вә Без бу әйтелгәннәрне барын да эшләдек.
80 Вә Давытка сезнең өчен сугыш киемнәре тегәргә өйрәттек, ул киемнәр белән сезне кылыч зарарыннан сакламак өчен. Әйә сез шуның өчен шөкер итәсезме?

**34 сүрә**

10 Без Давыт пәйгамбәргә үз юмартлыгыбыздан башка кешеләргә караганда артыклыкны бирдек; тавышы матур иде, тимер аның кулында камыр кеби йомшарыр иде. Аллаһ әйтте: «Ий таулар белән кошлар, Давыт белән бергә тәсбихләр әйтегез». Без аның кулында тимерне йомшак кылдык, утсыз ни теләсә, тимердән шуны ясыйдыр иде.
11 «Ий Давыт, ислам гаскәрләренә тимердән сугыш киемнәре яса вә ул киемнәрне һәрбер ирнең тәненә яраклаштырып яса, һәм, ий мөселманнар, һәммәләрегез дә изге гамәлләр кылыгыз вә яхшы эшләр эшләгез! Әлбәттә, Мин сезнең кылган эшләрегезне күрүчемен».

**5 сүрә**

78 Бәни Исраилнең кяферләре Давыт һәм Мәрьям угълы Гайсә теле белән ләгънәт ителделәр... Бу җәза аларга

20 Миңа яла ягучыларга, явыз
сүзләр белән җанымны әр-
нетүчеләргә Раббыдан җәза
нәкъ үзләре әйткәнчә бул-
сын!
21 Ә Син, Хуҗа-Раббым, мөкат-
дәс исемең хакына, Үз исе-
мең хакына миңа ярдәм ит,
мәрхәмәтең, игелегең хакына
коткар мине!
22 Мин бичара бер мазлум вә
фәкыйрьмен, эчемдә йөрәгем
яралы минем.
23 Эреп югала барган күләгә ке-
бек мин юкка чыгам; мине,
чикерткәдәй, селкеп төшер-
деләр.
24 Ураза тотып, тезләрем хәл-
сезләнде, мае бетеп, бәдәнем
сулыкты.
25 Кеше көлкесенә калган бер
зат булдым, мине күрделәр
исә, башларын чайкыйлар.
26 И Раббы Аллам, ярдәм ит,
мәрхәмәтең хакына коткар
мине!
27 Белсеннәр бу эштә Синең
кулың уйнаганны, моны
бары Син, Раббым, эшлә-
гәнне!
28 Алар ләгънәтләсен, ә Син
мине мөбарәк кыл! Миңа
баш калкытучылар рисвай
булсыннар, ә минем күңел-
гә — колың күңеленә — сөе-
нечләр тулсын!
29 Миңа яла ягучылар мәсхәрәгә
уралсыннар, кием итеп хур-
лыкка төренсеннәр!

ЗӘБУР

тиешле булды зур гөнаһлары
һәм хаклык чигеннән үтеп
киткәннәре өчен.
79 Алар үзләре кыла торган
бозык эшләрдән, батыйль
игътикатлардан бер-берсен
тыймадылар, нинди яман-
лыктыр аларның эшләре.

**4 сүрә**

163 ...һәм Давытка — Зәбур исемле
китап бирдек.

КОРЪӘН





30 Мин Раббыга чиксез рәхмәт-
ләр яудырырмын, халык ара-
сында Аны данлармын,
31 чөнки Ул — фәкыйрь-юк-
сылның уң ягында торучы,
аны гаепләүчеләрдән ара-
лаучы.

ЗӘБУР

# Сөләйман патша

*Сөләйман һәм Шеба мәликәсе*

**III Патшалар 10**

1 Шеба мәликәсе, Раббы исемен
данлаган Сөләйман хакын-
да ишетеп, авыр-четерекле
сораулар белән сынар өчен,
аның хозурына килде.
2 Иерусалимгә ул шактый зур
мал-мөлкәт алып килгән
иде: дөяләргә хуш исле су-
мала-майлар, байтак кү-
ләмдә алтын вә кыйммәт-
ле-затлы ташлар төялгән
иде. Ул, Сөләйман янына
килеп, күңелендә йөрткән
бар уй-фикерләре белән ур-
таклашты.
3 Мәликәнең һәммә сүзенә Сө-
ләйман аңлатма бирде; сорау-
лар арасында патша ачыклык
кертә алмаган бер генә авыр
нәрсә дә очрамады.
4 Шеба мәликәсе Сөләйманның
акыл-зиһенен, ул салган са-
райны,
5 патша өстәлендәге ризык-ни-
гъмәтләрне, түрәләренең
яшәү рәвешен, хезмәтче-
ләренең әдәплелеген һәм
аларның өс-башын, патша
шәрабчыларын, Раббы йор-
тында патша китергән кор-
баннарны күргәннән соң,
Шеба мәликәсе гаҗәпләнеп
6 сүзен башлады: «Синең эш-га-
мәлләрең, акыл-зиһенең



# Сөләйман патша

*Сөләйман һәм Сәба мәликәсе*

**27 сүрә**

20 Сөләйман шул арада һөдһөд
кошын югалтты һәм әйт-
те: «Миңа ни булды: һөдһөд
кошын күрмимен, яки ул
югалып киттеме?»
22 Аз гына вакыт үткәч һөдһөд...
Сөләйман янына килде вә
әйтте: «Ий патшам, мин ерак
җиргә барып син белмәгәнне
белдем вә Сәба шәһәреннән
сиңа хак булган яңа хәбәр
белән килдем.
23 Мин Бәлкыйс исемле бер ха-
тын патшаны таптым, вә ул
хатынга патшаларга бирелә
торган һәрнәрсә бирелгән,
дәхи аның зиннәтләнгән бик
зур тәхете бардыр.
24 Вә ул хатынны һәм кавемене
Аллаһудан башка кояшка
сәҗдә кылучылар таптым,
шайтан аларга кояшка та-
бынуларын яхшы эш дип
күрсәткән, шайтан аларны
хак дингә керүдән тыйган,
инде алар хак дингә күнел-
мәсләр».
25 Янә һөдһөд әйтте: «Ий ке-
шеләр, агяһ булыгыз, җиргә
яңгырны кушып төрле ри-
зыклар чыгаручы Аллаһуга
гыйбадәт кылмаска нәрсә
булган, янә Ул – Аллаһ –
күңелләрегездәге яшерен







турында үз җиремдә ишет-
кәннәрем хак дөрес икән.
7 Бирегә килеп үз күзем белән
күрмичә, мин ул сүзләргә
ышанып бетмәгән идем, бак-
саң, синең хакта мин күргән
кадәрнең яртысын да әй-
тмәгәннәр икән. Синдәге
зиһен-акыл вә мал-мөлкәт
мин ишеткәнгә караганда
байтакка күбрәк.
8 Синең кешеләрең нинди бә-
хетле! Көннен-көнендә синең
каршыңда торып гакыллы
сүзләреңне ишетүче хезмәт-
челәрең нинди бәхетле!
9 Синнән разый булып, сине
Исраил тәхетенә утырткан
Раббы Аллаңа шөкраннар
яусын! Раббы, Исраил хал-
кына булган мәңгелек мә-
хәббәтен раслап, гаделлек
белән хөкем кылсын өчен,
сине патша итеп куйган
икән».
10 Шуннан патшага бүләккә ул
йөз егерме талант алтын, күп
итеп хуш исле сумала-май-
лар вә зиннәтле ташлар
тапшырды; Шеба мәликәсе
Сөләйман патшага бүләк ит-
кән сыман хуш исле сума-
ла-майларның әле моңарчы
күрелгәне юк иде.
11 (Офирдән алтын алып кайт-
кан Хирам кораблары шулай
ук аннан бик күп күләмдә
бәкам агачы һәм зиннәтле
ташлар да төяп кайтты.



уйларыгызны һәм телләрегез
сөйләгән сүзләрегезне белер.
26 Ул Аллаһудан башка илаһ юк,
мәгәр Ул гына вә Ул олуг га-
решнең Раббысыдыр», – дип.
27 Сөләйман әйтте: «Ий һөдһөд,
тиз карарбыз, китергән хә-
бәрең дөресме яки ялганчы-
лардан булдыңмы.
28 Минем бу хатымны алып барып
алларына сал, соңра читкә-
рәк китеп карап тор, ничек
җавап бирерләр». Һөдһөд хат-
ны илтеп алларына салды.
29 Бәлкыйс хатны алгач әйтте:
«Ий җәмәгать, миңа бер ях-
шы хат ташланмыш булды.
30 Ул хат Сөләйманнандыр һәм
ул хатта: „Рәхмәтле, рәхимле
булган Аллаһ исеме белән
әйтәмен.
31 Миңа тәкәбберлек итмәгез,
итагать иткәнегез хәлдә миңа
килегез“, – дип язылган иде».
32 Бәлкыйс янә үзенең янында-
гыларга әйтте: «Ий җәмәгать,
ошбу эш хосусында нинди
киңәшегез вә хәйләгез бар,
миңа әйтегез, мин бер эш
хакында карар чыгармыйм,
мәгәр сезнең белән бергә
булганда гына карар чыга-
рамын».
33 Бәлкыйсның ярдәмчеләре
әйттеләр: «Без куәт ияләребез
вә сугышта каты батырлык
ияләребез, шулай булса да,
эш сиңа тапшырылмыштыр,
уйлап кара: сугышыргамы

[12] Патша әлеге агачтан Раббы йорты һәм үзенең сарае өчен терәү баганалары эшләтте, шулай ук җырчылар өчен гөслә һәм арфа да ясатты. Бүгенге көнгә кадәр аның кадәр агачның беркайчан кайтканы да, күрелгәне дә булмый.)
[13] Сөләйман патша үз кулы белән бүләк иткән әйберләрдән тыш Шеба маликәсе үзе теләгән һәм сораган һәммә нәрсәне аңа бүләк кылды. Шуннан маликә үзенең хезмәтчеләре белән үз җиренә юл алды.



яки килешергәме, ни әйтсәң – без хәзербез, сүзеңнән чыкмыйбыз».
[34] Бәлкыйс әйтте: «Әгәр патшалар бер шәһәргә һөҗүм белән керсәләр, ул шәһәрне җимерәләр һәм хөрмәтле олуг кешеләрен иң түбән вә хур итеп калдыралар, патшалар әнә шулай кылырлар.
[35] Мин Сөләйманга бүләкләр белән илчеләр җибәрәмен, соңра карармын, илчеләр нәрсә белән кайтырлар, минем бүләгемне кабул итеп алырлармы, юкмы»...
[36] Илчеләр бүләкләре белән Сөләйман хозурына килгәч, Сөләйман әйтте: «Миңа мал белән ярдәм итәсезме? Аллаһу миңа биргән пәйгамбәрлек вә патшалык (Ул) сезгә биргән малдан хәерлерәктер, бәлки сез ошбу бүләкләрегез белән үзегез мактанырсыз».
[37] Бүләкләр алып килгән илчегә Сөләйман әйтте: «Бар, бүләкләреңне алып кайтып Бәлкыйска тапшыр, без, әлбәттә, аларга гаскәр белән барабыз, безнең гаскәребезгә каршы торырга аларның такате булмас, без аларны Сәба шәһәреннән хур итеп чыгарырбыз, һәм аларның игътибары калмас»...
[38] Сөләйман әйтте: «Ий җәмәгать, Бәлкыйснең тәхетен миңа кем китерә, алар минем





СӨЛӘЙМАН ПАТША

яныма килеп иман китереп мөселман булганнарына чаклы?..»
[39] Җен таифәсеннән гыйфрит әйтте: «Син утырган урыныңнан торганчы мин ул тәхетне алып килермен, ул тәхетне сәламәт хәлендә алып килергә мин, әлбәттә, кадирмен», – дип.
[40] Аллаһ китабын яхшы белгән бер зат әйтте: «Син бер якка башыңны борып яңадан алдыңа караганыңча ул тәхетне алып килермен». Сөләйман башын күтәреп күккә карады, яңадан алдына караса, алдында тәхетне күрде. Сөләйман тәхетне алдында күргәч әйтте: «Бу тәхетнең шулай тиз килүе Раббымның фазылыннандыр, шөкер итәрме яки көферлек кылырмы дип мине сынар өчендер. Берәү шөкер итсә, үзе өчен шөкер итәдер вә берәү нигъмәткә көферлек итсә, тәхкыйк, Раббым байдыр, аның шөкер итүенә мохтаҗ түгелдер».
[41] Сөләйман әйтте: «Тәхетнең тышкы күренешен үзгәртегез, карарбыз: ул Бәлкыйс үзенең тәхетен танырмы яки танымаучылардан булырмы?»
[42] Бәлкыйс Сөләйман янына килгәч, аңа әйтелде: «Синең тәхетең шундый идеме?»

***Сөләйманның зирәклеге һәм кодрәте***

**III Патшалар 4**

21 Сөләйман патша Фырат елгасыннан алып Мисыр чигенә һәм пелештиләр җиренә кадәр булган патшалыкларны биләп торды. Алар һәммәсе,



Бәлкыйс әйтте: «Бу тәхет минем тәхеткә охшаган, минем тәхетем булса кирәк, ошбу хәлдән элек Аллаһуның кодрәтенә, синең пәйгамбәрлегеңә безгә дәлил бирелеп, без, иман китереп, мөселман булган идек.

43 Сөләйман Бәлкыйсны – Аллаһудан башка – кояшка гыйбадәт кылудан тыйды, чөнки Бәлкыйс элек кяферләр кавеменнән иде.

44 Бәлкыйска Сөләйман тарафыннан: «Шул пыяла сарайга кер!» – дип әйтелде. Бәлкыйс сарайга кергәндә пыяланы сизмәде, суга керәм дип уйлады һәм аяк балтырларын ачты. Аннары Сөләйман әйтте: «Син уйлаганча тирән су түгел, бәлки су өстендә ялтыравыклы пыяладан ясаган идәндер». Бәлкыйс әйтте: «Ий Раббым, кояшка табынып үземә золым иттем, инде барча галәмне тәрбия итүче Аллаһуга Сөләйман белән бергә иман китереп мөселман булдым», – дип.

***Сөләйманның зирәклеге һәм кодрәте***

**38 сүрә**

30 Вә Без Давытка Сөләйманны һибә кылдык, нинди хуш бәндәдер ул Сөләйман, ул һәрвакыт тәүбә тәсбих белән Аллаһуга кайтучыдыр.





Сөләйманга бүләкләр китереп, гомер буе аңа хезмәт күрсәтteләр.

22 Сөләйманга китерелә торган көндәлек азык-төлек түбәндәгедән гыйбарәт иде: утыз кор сыйфатлы бодай оны һәм алтмыш кор эре итеп тартылган он,

23 аранда симертелгән ун баш һәм көтүлектә йөргән егерме баш сыер; боланнар, тау һәм кыр кәҗәләре, симертелгән кош-корттан тыш тагын йөз баш сарык.

24 Чөнки ул Типсахтан алып Газага кадәр – Фырат елгасының бирге ягындагы барча патшалар өстеннән идарә итте, шулай ук әйләнә-тирәдәге барча илләр белән дә дус-тату яшәде.

25 Сөләйман идарә иткән дәвердә, Яһүдә һәм Исраил халкы, Даннан алып Беер-Шебага кадәр, хәсрәт күрмичә, һәркайсы үзенең йөзем куагы, үзенең инжир агачы төбендә тыныч гомер кичерде.

26 Сөләйманның арбага җигә торган атлары өчен дүрт мең араны булып, уникe мең арба йөртүчесе бар иде.

27 Билгеләнгән айда өлкә башлыкларының һәркайсы Сөләйман патшага һәм аның белән табын бүлешкән кешеләргә җитәрлек күләмдә азык-төлек китереп торды;



31 Икенде намазына хәтле Сөләйманга Аллаһның рәхмәтеннән гаиптән атлар бирелде, ул атлар бик җиңел, бик тиз йөрүче һәм күрештә бик тә матур атлардыр...

32 Сөләйман үкенеп әйтте: «Мин атлар мәхәббәтенә авышып Раббымның зекере булган намазны кичектердем, хәтта кояш баеды;

33 ул атларны миңа китерегез», – диде; атларны китергәч, Сөләйман муеннарыннан һәм аякларыннан сыйпады.

34 Тәхкыйк, Без Сөләйманны патшалыгын алмак белән бәлаләндердек... аның көрсиенә бер гәүдәне... утырттык, соңра Сөләйман тәүбә итте, Аллаһуга кайтты.

35 Әйтте: «Ий Раббым, мине ярлыкагыл вә миннән соң һичкемгә лаек булмаган олугъ патшалыкны миңа биргел, тәхкыйк, Син һәрнәрсәне һибә кылып бирүчесең».

36 Сөләйманга җилне иректле кылдык, ул җил аның боерыгы белән теләгән җиргә йомшак кына барыр иде.

37 Дәхи диңгез төбенә төшеп энҗе-мәрҗән ташларын чыгара торган җеннәрне вә биек биналар ясый торган җеннәрне аңа буйсындырдык.

28 жигү атлары һәм башка төр
атлар өчен арпа белән са-
ламны да һәркайсы үз нәү-
бәтендә тиешле урынга та-
шыды.
29 Сөләйманга Аллаһы зирәк-
лек, гаять үткер зиһен һәм
тирән гакылны диңгез буен-
дагы ком бөртегедәй мулдан
биргән иде.
30 Аңардагы зирәклек көнчы-
гышның һәм Мисырның
барча акыл ияләренекеннән
өстен булды.
31 Ул җир йөзендәге барча ке-
шедән, шул исәптән эзрахлы
Этаннан да, Махул угылла-
ры Һеман, Кәлкөл вә Дар-
дадан да зирәгрәк иде; аның
исеме әйләнә-тирәдәге ха-
лыклар арасында мәшһүр
булды.
32 Үз гомерендә ул, өч мең гый-
брәтле хикәя сөйләп, мең дә
биш җыр чыгарды;
33 Ливанда үсә торган эрбет ага-
чыннан башлап дивар ярык-
ларыннан баш төртә торган
һүссөпкә кадәр бөтен үсем-
лекләр, шулай ук хайван-
нар, кошлар, сөйрәлүчеләр
вә балыклар хакында сөйләп
калдырды.
34 Сөләйманның зирәклеге ха-
кында ишетеп-белгәннәр
барлык мәмләкәтләрдән,
җир йөзендәге бөтен пат-
шалыклардан аны тыңларга
килә торганнар иде.

ТӘҮРАТ

38 Башка шайтаннарны, кеше-
ләргә зарарлары тимәсен
өчен, бер урынга җыеп кул-
ларын муеннарына богаула-
дылар.
39 Ий Сөләйман, бу әйтелгән
нәрсәләр сиңа биргән нәрсә-
ләребездер, теләгән кешеңә
теләгән нәрсәңне бир яки
һичнәрсә бирмичә үзеңдә
сакла, ул нәрсәләрдә сиңа
хисап юктыр.
40 Дәхи ул Сөләйманга хозуры-
бызда Безгә якын булу һәм
кайта торган күркәм урын
бардыр.

**19 сүрә**

78 Ул... әллә яшерен эшләрне бе-
лә торган булдымы яки мал-
лары вә балалары кайтарып
биреләчәге белән Аллаһудан
гаһед алдымы?
79 Юк, ул... яшерен эшне дә
белмәде һәм Аллаһудан
гаһед тә алмады! Әлбәттә,
Без аның әйткән сүзләрен
язарбыз һәм ахирәттә җә-
за бирербез, имансыз бул-
ганы өчен булган газабы-
на янә газабны арттырыр-
быз.
80 Вә «кыямәттә миңа бирелер»
дигән малына вә балалары-
на башканы варис итәрбез,
Безнең хозурыбызга ялгыз
килер.
81 Мөшрикләр Аллаһудан башка
илаһлар тоттылар үзләренә
дәрәҗә булсын өчен.

КОРЪӘН



СӨЛӘЙМАН ПАТША

**III Патшалар 11**

1 Сөләйман патшаның, фиргa-
вен кызыннан башка, тагын
бихисап күп чит мәмләкәт
хатын-кызларына гыйшкы
төште. Алар арасында Мәаб,
Аммон, Эдом, Сидун, Хит
кызлары да бар иде.
2 Алар хакында Раббы Үзенең
Исраил халкын: «Ул кызларга
өйләнмәгез, юкса алар йөрә-
гегезне үзләренең илаһлары-
на аударыр», – дип, алдан
кисәтеп куйган була. Әмма
Сөләйманның гыйшкы тө-
шеп, күңеле шуларга беректе.
3 Сөләйманның хатыннары ара-
сында җиде йөз патша кызы
вә өч йөз кәнизәк булып,
әлеге хатыннар аның күңе-
лен аздырды.
4 Сөләйман олыгая төшкәч, ха-
тыннары аның күңелен баш-
ка илаһларга аударды; аның
йөрәге, атасы Давытныкы
сыман, үзенең Раббы Алла-
сына тугры булып калмады.
5 Сөләйман Сидун алиһәсе Аш-
торетка һәм аммониләрнең
җирәнгеч илаһы Милкүмгә
табына башлады.
6 Сөләйман, шул рәвешле, Раб-
бы күзенә ятышсыз күренгән
гамәлләр кылды, атасы Да-
выт сыман, ахыргача Раббы
юлында кала алмады.
7 Иерусалимнән көнчыгыш-
ка табарак бер калкулык-
та Сөләйман мәабиләрнең

ТӘҮРАТ

82 Юк, алар уйлаганча булмас!
Сынымнары аларның гый-
бадәтләрен инкяр итәрләр
һәм мөшрикләргә дошман
булырлар.

КОРЪӘН

җирәнгеч илаһы Кемошка
һәм аммониләрнең җирәнгеч
илаһы Молыхка багышлап
гыйбадәт кылу урыны ясады.
8 Шул рәвешле ул, хуш исле
сумала-майлар көйрәтеп, үз
илаһларына корбан китерүче
чит мәмләкәт хатыннары-
ның һәммәсе өчен шундый
урыннар булдырды.
9-10 Ике тапкыр Сөләйман яны-
на иңгән, башка илаһларга
табынмаска боерган Исра-
илнең Раббы Алласыннан
йөз чөергән өчен, Раббының
Сөләйманга нык ачуы чык-
ты, чөнки ул Раббы боерык-
ларын үтәмәде.
11 Шуннан Раббы Сөләйманга
болай диде: «Синең әнә шул
эшләрең өчен, Минем белән
төзегән килешүне саклама-
ган һәм Минем кагыйдәлә-
ремне үтәмәгән өчен, патша-
лыкны синең кулдан алып,
хезмәтчеңә тапшырырмын.
12 Ләкин атаң Давыт хакына
Мин моны син исән чакта
эшләмәм – Мин аны си-
нең улгың кулыннан тартып
алырмын.
13 Мин аңардан бөтен патша-
лыкны алмам, колым Давыт
хакына һәм Үзем сайлап ал-
ган Иерусалим хакына Мин
синең улгың кулында Ис-
раилнең бер ыругын гына
калдырырмын».





## Ильяс

**III Патшалар 18**

21 Шуннан Ильяс, җыелган
халык янына чыгып: «Та-
гын күпмегә кадәр сез ике
аягыгызга да чатанлап йө-
рергә җыенасыз? – диде. –
Әгәр Раббыны Аллаһы дип
танырсыз икән – Аңа ия-
регез; әгәр инде Багалны
алла дип беләсез икән –
аның артыннан барыгыз».
Халык аңа бер кәлимә сүз
катмады.
22 Аннары Ильяс аларга болай
дип әйтте: «Мин – Рабби-
ның исән калган бердәнбер
пәйгамбәре. Багал пәйгам-
бәрләренең саны исә дүрт
йөз илле кешедер.
23 Хәзер безгә ике үгез бозау
китерсеннәр; алар, бозау-
ның берсен сайлап алып,
аны кисәкләргә бүлсеннәр
дә утын өстенә салсыннар,
әмма учакны кабызмасын-
нар; мин дә, икенче бозауны
әзерләп, аны утын өстенә
салырмын, ләкин учакны
кабызмам.
24 Шуннан сез үзегезнең ила-
һыгызның исемен атарсыз,
мин исә Раббы исемен ча-
кырырмын. Безнең догалар
кабул кылынганны белде-
реп, учакка ут салган алла –
хак дөрес Алладыр. Халык
аның белән килешеп: «Яхшы,



## Ильяс

**37 сүрә**

123 Вә Ильяс та Аллаһ тарафын-
нан җибәрелгән пәйгамбәр-
ләрдәндер.
124 Кавеменә: «Аллаһудан ку-
рыкмыйсызмы, Аңа гыйба-
дәт кылмыйсыз, – диде. –
125 Сезне вә һәрнәрсәне күркәм
сурәттә халык кылучы Ал-
лаһуны куеп, Бәгел исемле
сынымга табынасызмы?
126 Ул – Аллаһ – сезнең Рабби-
гыз вә әүвәлге бабаларыгыз-
ның Раббысыдыр».
127 Алар Ильясны ялганга тот-
тылар; үзләре вә сынымнары
җыелып утта булырлар.
128 Мәгәр Аллаһуның ихласлы
коллары утка кермәсләр.
129 Без Ильяска соңыннан кил-
гәннәрнең телләрендә яхшы
сүз калдырдык.
130 Ул сүз Ильяска сәлам булсын
димәкләредер.
131 Гөнаһтан сакланып изге га-
мәлләр кылучыларга әнә
шулай изгелек итәбез.
132 Дөреслектә, Ильяс безнең хак
мөэмин колларыбыздан иде.

**6 сүрә**

85 Янә Зәкәрияне, Яхъяны, Гай-
сәне, Ильясны һидаятькә
салдык, алар һәммәсе из-
геләрдән.

шулай булсын», – дип җавап бирде. <...>

36 Кичке корбан китерер вакыт җиткәч, Ильяс пәйгамбәр якын килеп болай диде: «И Раббы, Ибраһим, Исхак һәм Исраил Алласы! Синең Исраил Алласы булуыңа һәм минем – Синең колыңның – боларны Синең кушуың буенча эшләвемә бөтенесе менә хәзер шушында инансыннар!» <...>

38 Нәкъ шулчакны Раббы ут индерде, һәм ялкын шундук корбанны да, утынны да, ташларны да, җирне дә яндырып бетереп, чокырдагы суны да киптерде.

39 Шушы хәлне күрүгә, бар халык йөзтүбән җиргә капланды һәм: «Раббы – Аллаһы Ул, Раббы – Аллаһы Ул!» – дип тәкрарларга тотынды.

40 «Багал пәйгамбәрләрен тотыгыз, берсе дә качып котыла алмасын», – диде шунда Ильяс халыкка, һәм тегеләрне тотып алдылар. Аннары Ильяс, аларны Кыйшон инешенә таба алып китеп, шунда чәнчеп үтерде.





## Үледән терелтү

**Яхәзкыл 37**

1 Мин үз өстемдә Раббының кулын тойдым, һәм Раббы Рухы мине, шәһәрдән чыгарып, үзән уртасына китереп бастырды. Әлеге үзән сөякләр белән тулы иде.

3 Раббы миңа әйтте: «И адәм углы! Бу сөякләргә җан өреп буламы?» – диде. Мин: «Йа Хуҗа-Раббым! Моны Син генә беләсең», – дидем. <...>

10 Мин Ул кушканча пәйгамбәрлек иттем – аларга сулыш килде, җан керде, һәм алар, күп санлы гаскәр булып, аякларына торып басты.

11 Раббы миңа: «И адәм углы! Ошбу сөякләр – бөтен Исраил халкы. Менә, алар: „Сөякләребез кибеп бетте, өметебез үлде, киләчәгебез юк“, – ди.

12 Шуңа күрә пәйгамбәрлек итеп аларга, Хуҗа-Раббы болай дип әйтә, диген: „Менә, Мин сезнең каберләрегезне ачам һәм сезне, Үземнең халкымны, каберләрегездән кубарып, Исраил җиренә кайтарам.

13 Каберләрегезне ачып, сезне шуннан чыгаргач, и халкым, сез Минем Раббы икәнемне белерсез.

14 Сезгә Үземнең Рухымны салгач, сезгә җан керер, һәм



## Үлеләрне тергезү

**2 сүрә**

259 Янә кешеләре үлгән, йортлары җимерелгән шәһәр яныннан үтеп баручы Гозәер г-мнең хәле белән танышыгыз! Шәһәрнең өсте-аска килгәнне күреп Гозәер г-м әйтте: «Кешеләр шәһәр белән бергә һәлак булганнар инде, боларны Аллаһ ничек тергезсен?» – дип. Гозәер г-м шәһәрдән үтеп ерак киткәч, Аллаһ аны үтерде, йөз ел үткәч тергезде һәм: «Ий Гозәер, үлеп күпме яттың?» – диде. Гозәер г-м әйтте: «Үлеп бер көн яки бер көннән азрак яттым». Аллаһ әйтте: «Ий Гозәер, бер көн түгел, ә йөз ел яттың, кара ашый торган ризыгыңа һәм эчә торган эчемлегеңә – сасымаганнар, һәм ишәгеңә кара», – дип. Гозәернең үзе белән алган ризыгы һәм эчемлеге йөз ел буена ятып бозылмаган, әмма ишәкнең кояшта агарган сөякләре генә калган иде. Боларны күреп Гозәер г-м гаҗәпләнде. Аллаһ Гозәер г-мгә: «Сөякләрне җыеп, аларга ит кундырып һәм тире үстереп ишәкне тергезгәнебезне карап тор», – диде. Ий Гозәер! Үлгәннән соң терелүгә ышаныр өчен кешеләргә дәлил булсын дип кылдык

сезне үз җирегезгә урнаштырырмын, шуннан Минем Раббы икәнемне белерсез. Мин моны әйттем һәм шулай эшләячәкмен». Бу – Раббы сүзе».



сиңа бу эшне. Ишәкнең терелгәнен күргәч Гозәер әйтте: «Мин хәзер Аллаһуның һәрнәрсәгә көче җиткәнен беләмен», – дип.





## Юныс

**Юныс 1**

1 Амиттай углы Юныска Раббы
шушы сүзләрне ирештерде:
2 «Ниневәгә юл ал, шул бөек шәһәргә барып, халкын кисәт! Чөнки Миңа андагы явызлыклар турында хәбәр килеп иреште».
3 Әмма Юныс, Раббыдан качмакчы булып, капма-каршы якка китеп барды. Яфу шәһәренә килеп төшкәч, Таршишка баручы бер корабка юлыкты. Юл бәһасен түләп корабка утырды да, Раббыдан ераграк китү өчен, Таршишка юл тотты.
4 Ләкин Раббы диңгез өстендә шундый көчле җил кузгатты ки, коточкыч давыл кубып, кораб җимерелер хәлгә килде.
5 Диңгезчеләрнең котлары алынып, һәммәсе үз илаһына ялварды. Корабны җиңеләйтү өчен, алар йөкне диңгезгә ыргытырга тотындылар. Юныс исә кораб төбенә төшеп ятты да тирән йокыга талды.
6 Кораб башлыгы, Юныс янына төшеп: «Нишләп йоклап ятасың? Тор! Илаһыңа ялвар! Бәлки, хәлебезгә керер дә, һәлак булмабыз», – диде.
7 Диңгезчеләр: «Әйдәгез, җирәбә салып белик: бу бәлагә



## Юныс

**37 сүрә**

139 Вә Юныс та Безнең җибәргән пәйгамбәрләребездәндер.
140 Юныс, иман китермәгән кавемен ташлап, кешеләр белән тулган зур көймәгә керде.
141 Көймә кузгалмады, шул сәбәпле кешеләр «арабызда качкан кеше бардыр» дип шобага салдылар һәм, шобага Юныска чыгып, аны диңгезгә ташладылар.
142 Аны дәрхаль бер зур балык йотты, вә ул Аллаһ рөхсәтеннән башка кавемен ташлап киткәне өчен үзен үзе шелтәлидер.
143 Әгәр Юныс: «Һич юктыр илаһ, мәгәр Син генә, йа Раббы, мин Сине һәр кимчелектән пакьсең дип беләм, мин, әлбәттә, Синең рөхсәтеңнән башка китеп үземә золым итүчеләрдән булдым», – дип әйтмәсә иде.
144 Әлбәттә, балык карынында Юныс кешеләр терелеп каберләреннән кубарылган көнгә чаклы торыр иде.
145 Без аны берникадәр балык карынында торганнан соң сырхау булганы хәлдә корыга чыгарып ташладык...
146 Вә аның янында киң яфраклы агач үстердек...
147 Без аны йөз меңле яки йөз меңнән артыграк кешеле

кем аркасында тарыдык икән?» — диешә башладылар. Жирәбә салдылар, һәм ул Юныска чыкты.

8 Шуннан соң Юныска: «Сөйләп бир: бу бәла кем аркасында башыбызга төште? — диделәр. — Шөгылең нинди? Кайдан киләсең? Ватаның кайда? Кайсы халыктан буласың?»

9 «Мин гыйбриләрдән, — дип җавап бирде Юныс. — Диңгезне һәм җирне яраткан Күк Алласына, Раббыга табынамын».

10 Диңгезчеләргә ул Раббыдан качуын да әйтте. Диңгезчеләр бик нык куркуга төштеләр һәм Юныстан: «Ни өчен шулай эшләдең?» — дип сорадылар.

11 Диңгез тагы да катырак ярсыганга күрә, Юныстан алар: «Диңгез тынсын өчен, сине нәрсә эшләтик?» — дип сорадылар.

12 Юныс: «Тотыгыз да диңгезгә атыгыз мине, — дип җавап бирде. — Шулвакыт диңгез тынар. Мин беләмен: бу коточкыч давылга сез минем аркада эләктегез».

13 Диңгезчеләр, аның сүзләренә карамыйча, коры җиргә җитү өчен, ишкәкләре белән катырак ишәргә керештеләр, әмма файдасы тимәде, чөнки диңгез



шәһәргә пәйгамбәр итеп җибәргән идек.

148 Һәм бу юлы һәммәсе иман китерделәр, вә Без дә аларны билгеләнгән әҗәлләренә чаклы малларыннан файдаландырдык, тыныч яшәттек.

**21 сүрә**

87 Юнысны да хәтерләгез, ачуланып кавеменнән аерылып китте, ул уйлады, кавемен ташлап киткән өчен Безнең аңа хөкем булмас, дип. Ул караңгыда, ягъни балык эчендә, дога кылып әйтте: «Йа Аллаһ, Синнән башка һич илаһ юк, мәгәр Син генә, Сине һәр кимчелектән пакь дип беләмен, Синең рөхсәтеңнән башка кавемемне ташлап китүем белән үземә золым итүчеләрдән булдым».

88 Аның догасын кабул иттек вә аны кайгысыннан коткардык, әнә шулай мөэминнәрне коткарабыз.

**10 сүрә**

98 Юныс г-м кавеменнән башка һичбер кавемнең газапны күргәч кенә китергән иманнары файда бирмәде. Чөнки Юныс кавеме иман китергәч, алардан дөнья газабын бетердек вә әҗәлләре җиткәнче (малларыннан) файдаландырдык...

**4 сүрә**

163 Ий Мөхәммәт г-м! Сиңа Коръәнне вәхи кылдык Нух





ярсый-ярсый дулавын дәвам итте.

14 Раббыга мөрәҗәгать итеп: «Йа Раббы, ялварып сорыйбыз, — диде алар. — Шушы адәмнең җаны өчен һәлак булмасак иде. Безне гаепсез адәмнең үлеме өчен гөнаһлы итмә. Син, Раббы, инде теләгәнеңне эшләдең!»

15 Шулай дип, алар Юнысны диңгезгә тотып аттылар — ярсыган диңгез шундук тынычланды.

16 Бу хәлдән соң диңгезчеләр, Раббыдан куркып, Аңа корбан китерделәр һәм нәзерләрен әйттеләр.

**Юныс 2**

1 Шуннан соң Раббы бер зур балыкка Юнысны йотарга кушты. Юныс өч көн вә өч төн шул балыкның карынында булды.

2 Юныс балыкның карыныннан Раббы Алласына... дога кылды. <...>

11 Шуннан Раббы балыкка Юнысны коры җиргә косып чыгарырга кушты.

**Юныс 3**

1 Раббы Юныска икенче мәртәбә сүзен ирештерде:

2 «Ниневәгә юл ал! Шул бөек шәһәргә барып, Мин кушканча, халкын кисәт!»

3 Юныс, Раббының сүзен үтәп, Ниневәгә китте. Ниневә шундый бөек бер шәһәр иде



пәйгамбәргә һәм аннан соң килгән пәйгамбәрләргә вәхи кылганыбыз кеби, вә Ибраһим, Исмәгыйль, Исхак, Ягъкуб, Гайсә, Әюб, Юныс, Һарун, Сөләйман пәйгамбәрләргә вәхи кылганыбыз кеби; һәм Давытка Зәбур исемле китап бирдек.

**6 сүрә**

86 Дәхи Исмәгыйльне, Әлйәсәгъне, Юнысны вә Лутны һидаятькә салдык, үз заманаларында бөтен дөнья кешеләреннән аларны дәрәҗәдә артык кылдык.

ки, аны карап чыгу өчен өч көн вакыт кирәк иде.
4 Беренче көнне Юныс, шәһәр буйлап йөреп, халыкны үгетләде: «Кырык көннән соң Ниневә җимереләчәк!» — диде.
5 Ниневәлеләр Аллаһы сүзенә ышандылар һәм олысыннан кечесенә кадәр уразага керделәр, тәүбәгә килгәннәрен күрсәтеп, тупас тукымага төренделәр.
6 Ниневә патшасына бу хәбәр килеп ирешкәч, ул, тәхетеннән торып, өстеннән патша киемнәрен салды да, тупас тукымага төренеп, көл өстенә утырды.
7 Шуннан соң патша Ниневәдә түбәндәге фәрманны игълан итте: «Патша һәм аның түрәләренең боерыгы нигезендә кешеләргә дә, хайваннарга да — сыерлы ул, сарыкмы — ашарга-эчәргә рөхсәт ителми!
8 Бөтен кеше һәм хайван тупас тукыма ябынсын. Һәркайсы чын күңелдән Аллаһыга ялварсын, явызлык һәм җәбер кылудан ваз кичсен.
9 Кем белә, бәлки әле, Аллаһы, күңеле йомшарып, уеннан кайтыр, ачуланудан туктар һәм безне һәлак итмәс».
10 Аллаһы, аларның гамәлләрен — явызлык кылудан туктауларын күргәч, халыкны






кызганды һәм алар өстенә җибәрергә вәгъдә иткән бәла-казасын җибәрми калды.

**Юныс 4**

1 Моны күреп, Юныс бик гарьләнде, аның ачуы чыкты.
2 Раббыга ул шундый дога кылды: «И-и Раббы, шушылай буласын өйдә чакта ук әйтмәдеммени?! Шуңа күрә Таршишка качмакчы булдым да инде, чөнки беләидем: Син кызганучан вә рәхимле, түзем-сабыр вә үтә мәрхәмәтле, бәла-каза җибәрергә дигән уеңнан кире кайтучан Алласың.
3 И-и Раббы, инде хәзер җанымны ал, чөнки минем өчен үлем яшәүдән яхшырактыр».
4 Раббы әйтте: «Синең шулай ачуланырга ни хакың бар?!»
5 Юныс шәһәрдән чыкты да, көнчыгышка таба юл алып, бер урынга килеп утырды. Шунда ул үзенә куыш ясады һәм, күләгәгә утырып, шәһәр белән ниләр буласын көтә башлады.
6 Раббы Алла, Юныснең баш өстенә күләгә төшереп, унайсыз хәлен җиңеләйтер өчен, бер үсемлек үстерде. Юныс моңа бик сөенде.
7 Әмма икенче көнне таң атканда Аллаһы бер кортны җибәрде, һәм шул корт үсемлекне кимереп корытты.

[8] Кояш чыккач, Аллаһы көйдер-
геч көнчыгыш җиле истер-
де. Юнысның башын кояш
шундый кыздырды ки, эссе
сугудан ул һуштан язар хәл-
гә җитте. «Болай яшәгәнче,
үлүең яхшырак», – диде ул,
үзенә үлем теләп.
[9] Ләкин Аллаһы Юныска әйтте:
«Үсемлек корганга, шулай
ачуың чыктымы?» «Әйе, –
диде Юныс, – бик каты ачу-
ым чыкты. Шуңа күрә үләргә
телим дә».
[10] Шунда Раббы Юныска әйтте:
«Син үзең карап үстермә-
гән үсемлекне кызганасың.
Ул бер төндә тишелеп үсте,
икенче төндә юкка да чыкты.
[11] Ә Мин ничек итеп Ниневәне,
шул бөек шәһәрне кызган-
мыйм ди?! Бу шәһәрдә, күп
санлы хайваннарны сана-
маганда, йөз егерме меңнән
артык бәхетсез кеше яши».

ТӘҮРАТ



## Әюб

**Әюб 1**
[12] Шунда Раббы болай диде:
«Ярый, бүгеннән аның бар
мөлкәте синең кулыңда, тик
аның үзенә генә тимә». Шай-
тан аннары Раббы яныннан
китеп барды. <...>
[20] Шулчак Әюб урыныннан си-
кереп торды да, өс киемнәрен
ерткалап, чәчен кырыкты.
Аннары башын җиргә орып
сәҗдә кылды
[21] һәм әйтте: «Мин әнкәм кары-
ныннан шәрә килеш туган
идем, шәрә килеш китәрмен
дә. Раббы бирде, Раббы алды:
Раббыга мактау-шөкерләр
яусын!»
[22] Шундый хәлләргә тарып та,
Әюб гөнаһ кылмады – Ал-
лаһыны гаепләмәде.
**Әюб 2**
[6] Раббы шайтанга әйтте: «Ярый,
бүгеннән ул синең кулда, тик
аның гомерен генә өзмә».
[7] Шуннан соң шайтан, Раббы
яныннан китеп, Әюбне ба-
шыннан аягынача шеш-ку-
тыр белән каплап алды.
[8] Әюб, шеш-кутырларын кырып
тазартмакчы булып, кулына
чүлмәк ватыгы алды да көл
өеменә утырды.
[9] Хатыны аңа: «Син әле һаман,
күңелем саф минем, дип үз
сүзеңдә нык торасыңмы? Ал-
лаңны каһәрлә дә үл!» – диде.

ТӘҮРАТ

## Әюб

**38 сүрә**
[41] Янә колыбыз Әюб пәйгамбәр-
не сөйлә; Әюб Раббысына
дога илә мөрәҗәгать итте:
«Ий Раббым, мине шайтан
авырлык вә каты мәшәкать
илә тотты, малымны вә ба-
лаларымны һәлак итте». Әюб
күп еллар сырхау булды, һич-
нәрсәсе калмады, ул һаман
сабыр итте, зекердән тук-
тамады.
[42] «Ий Әюб, аягың илә җиргә
тип», – дип әйтелде; типкән-
нән соң салкын чишмә, юы-
нырга кайнар чишмә чыкты.
Кайнар чишмәдә юынды,
салкын чишмәдән эчте, шун-
да ук сәламәтләнеп әүвәлге
куәтен тапты.
[43] Вә Без Әюбкә балаларын ике
өлеш арттырып бирдек, Без-
дән аңа рәхмәт булсын өчен
вә гакыллы кешеләргә вәгазь
булсын өчен.
[44] Ий Әюб, бер уч салам алып
хатыныңа сук, Аллаһ исеме
илә әйткән антыңны үтәми-
чә гөнаһлы булып калма...
Без Әюбне бәла-казага вә
сырхауга сабыр итүче тап-
тык...
**21 сүрә**
[83] Вә Әюбне дә хәтерләгез, ул
Раббысына дога кылды: «Ий
Раббым, мине сырхау вә ка-
тылык тотты, вә Син рәхмәт

КОРЪӘН

**Әюб 3**

1-2 Шуннан Әюб, сүз башлап, дөньяга килгән көненә ләгънәт укыды: <...>

11 «Никләргә мин үле булып тумаганмын, һәм тугач та, никләр генә үлмәгәнмен?»

**Әюб 42**

10 Әюб үзенең дуслары хакына дога кылганнан соң, Раббы Әюбкә муллыгын элеккегә караганда ике тапкыр күбрәк итеп кайтарып бирде.

11 Аның янына барлык ир һәм кыз туганнары, элекке дуслары җыелдылар, аның өендә бергәләп мәҗлес корып утырдылар, Раббы тарафыннан җибәрелгән барлык бәла-казалар өчен аны кызгандылар һәм юаттылар; һәрберсе бер кесита көмеш һәм алтын алка бүләк итте.

12 Раббы Әюбнең калган гомерен әүвәлгегә караганда да ныграк фатихалады: хәзер аның ундүрт мең кәҗә һәм сарыгы, алты мең дөясе, мең пар эш үгезе һәм мең ишәге бар иде.



итүчеләрнең иң рәхимлесе, миңа рәхмәт ит».

84 Без аның догасын кабул иттек вә аңарда булган сырхау һәм бәлане җибәрдек вә аңар өй әһелләрен кайтарып бирдек вә балаларын, малларын ике өлеш арттырып бирдек Үз хозурымыздан рәхмәт йөзеннән вә Аллаһ колларына гыйбрәт булсын өчен.

**4 сүрә**

163 Ий Мөхәммәт г-м! Сиңа Коръәнне вәхи кылдык Нух пәйгамбәргә һәм аннан соң килгән пәйгамбәрләргә вәхи кылганыбыз кеби, вә Ибраһим, Исмәгыйль, Исхак, Ягъкуб, Гайсә, Әюб, Юныс, Һарун, Сөләйман пәйгамбәрләргә вәхи кылганыбыз кеби; һәм Давытка Зәбур исемле китап бирдек.

**6 сүрә**

84 Ибраһимга — Исхакны вә аның угълы Ягъкубны бирдек, һәрберсен һидаятькә салдык вә Ибраһимнан элек Нухны һидаятькә салдык һәм Ибраһим нәселеннән — Давытны, Сөләйманны, Әюбне, Йосыфны, Мусаны, Һарунны һидаятькә салдык һәм чын иманлы, изге гамәлле кешене әнә шулай һидаятькә салачакбыз.



## Суга чумдыручы Яхъя

**Лүк 1**

5 Яһүдиядә Һируд патша идарә иткән заманда, Абия нәселеннән булган руханилар төркемендә Зәкәрия атлы бер рухани яши иде. Аның хатыны Элисабет тә руханилар нәселеннән булып,

6 алар икесе дә Раббы әмерләрен һәм Ул кушканнарны төгәл үтәүче тәкъвалардан иде.

7 Инде олы яшькә җиткән бу икәүнең, Элисабет балага уза алмаганлыктан, балалары юк иде.

8 Зәкәрия төркеме үз нәүбәтендә Аллаһы хозурында рухани хезмәте башкарган бер көнне,

9 руханиларда кабул ителгәнчә җирәбә салып, Раббы йортында хуш исле сумала-майлар төтәсләү Зәкәриягә чыкты.

10 Аллаһы йортында хуш исле сумала-майлар көйрәткәндә, бар халык тышкы якта дога кылып торды.

11 Шулвакыт Зәкәрия алдында, хуш исле сумала-майлар көйрәтә торган мәзбәхтән уң якта, Раббы фәрештәсе пәйда булды.

12 Фәрештәне күргәч, Зәкәрия бик нык курыкты.

13 Фәрештә исә аңа: «Курыкма, Зәкәрия, синең доган килеп



## Яхъя

**19 сүрә**

2 Түбәндә укылачак аятьләр Раббыңның колы Зәкәриягә Аның рәхмәтенең бәянедер.

3 Зәкәрия г-м теләгән нәрсәсен сораганда Раббысына яшерен тавыш белән нида кылды.

4 Әйтте: «Ий Раббым, минем сөягем зәгыйфьләнде вә башым ак чәчләр белән тулды, вә мин, ий Раббым, Сиңа кылган догамнан кире кайтарылучы булмадым, һәрвакыт догамны кабул кылдың.

5 Үлгәнемнән соң вәли булып калачак кемсәләрнең золым ителүләреннән куркамын, ә минем хатыным бала тудырмый торган кысыр булды, Үзеңнең фазылыңнан миңа бер изге угыл биргел!

6 Ул угыл миңа варис булыр вә Ягъкуб балаларына варис булыр, вә, Раббы, ул угълымны Үз каршында разый кыл!»

7 «Ий Зәкәрия, Без сине сөендерәбез бер угыл белән, аның исеме Яхъядыр. Моннан элек ул исемдә һичкемне кылмадык».

8 Әйтте Зәкәрия: «Йа Раббы, ничек минем угълым булыр икән, хәлбуки хатыным кысыр, үзем картлыкның ахыр чигенә җиттем?»

ирештe, — диде. — Хатының
Элисабет сиңа ир бала ту-
дырачак, син аңа Яхъя дип
исем кушарсың.
14 Ул сиңа сөенеч һәм шатлык
китерер, аның тууына күп-
ләр куаныр,
15 чөнки Раббы каршында ул
бөек булыр, шәраб һәм исер-
ткеч эчемлекләр эчмәс, ана-
сының карынында вакытта
ук Изге Рух белән сугарылыр.
16 Исраил балаларының күбе-
сен ул Раббыга, аларның үз
Алласына кире кайтарыр.
17 Ильясныкы кебек рухка һәм
кодрәткә ия булып, Раббы
алдыннан барыр, аталарны
һәм балаларны татулашты-
рыр, Аллаһыга буйсынмас-
ларны тәкъвалар юлына бо-
рыр һәм Раббының килүенә
халыкны әзерләр».
18 Зәкәрия фәрештәдән: «Моның
шулай буласын мин ничек
белермен? — дип сорады. —
Мин инде карт, хатыным да
олы яшьтә».
19 «Мин — Аллаһыга хезмәт итү-
че Җәбраилмен, — диде аңа
фәрештә, — һәм мине Ул шу-
шы куанычлы хәбәрне сиңа
җиткерү өчен җибәрде.
20 Вакыты җиткәч, мин әйт-
кәннәр чынга ашар. Ә хәзер,
минем сүзләремә ышанмаган
өчен, әйткәннәрем тормыш-
ка ашканчы, телсез булыр-
сың һәм сөйләшә алмассың».



9 Аллаһ әйтте: «...Раббың болай
әйтте: карт көнегездә сез-
дән бала китерү Миңа бик
җиңел, тәхкыйк, Мин сине
халык кылдым Яхъядан элек,
син ул вакытта һичнәрсә тү-
гел идең».
10 Зәкәрия г-м әйтте: «Йа Раббы,
хатынымның балага калган-
лыгын белдереп миңа бер
галәмәт бир!» Аллаһ әйтте:
«Галәмәт сиңа шул булыр,
чирләмәгән хәлеңдә тоташ-
тан өч көн кешеләр белән
сөйләшә алмассын».
11 ...михрабтан чыгып кавеме
янына барды — сөйләшә ал-
мыйдыр иде, иртә вә кичке
намазларны укырсыз дип
кавеменә ишарәт илә аң-
латты.

**3 сүрә**

38 ...Раббысына ялварып дога
кылды. Әйтте: «Ий Раббым,
рәхмәтеңнән миңа бер бала
биргел! Шиксез, Син минем
догамны ишетәсең».
39 Зәкәрия михрабта намаз укып
торганда Җәбраил килеп
кычкырды: «Ий Зәкәрия,
дөреслектә, Аллаһ сине Яхъя
исемле изге угыл белән шат-
ландыра... Яхъя кавеме ара-
сында хөрмәтле вә олуг бу-
лыр... изге пәйгамбәрләрдән
булыр».
40 Зәкәрия әйтте: «Ий Раббым,
миңа кайдан угыл булсын,
дөреслектә, миңа картлык







21 Халык, Аллаһы йортында Зә-
кәриянең тоткарлануына ап-
тырап, аны көтә бирде.
22 Зәкәрия исә, Аллаһы йор-
тыннан чыккач, сөйләшә
алмады, һәм кешеләр аңа
илаһи күренеш ирешкәнен
аңладылар. Ул алар белән
ишарәләр ярдәмендә аңлаш-
ты һәм телсез килеш кала
бирде. <...>
76 «Һәм син, сабый, Аллаһы
Тәгаләнең пәйгамбәре дип
аталырсың, чөнки, Раббыга
юлны әзерләп, Аның алдын-
нан барырсың,
77 Аның халкына, гөнаһларыгыз
кичерелгәч, сезне котылу
көтә, дип белдерерсең.
78 Аллабызның шәфкате ташып
тора, һәм шуңа күрә безгә
югарыдан таң кояшы иңәчәк;
79 караңгыда һәм үлем күләгә-
сендә утырганнарга яктылык
бирү өчен, аякларыбызны
тынычлык юлына юнәлтү
өчен киләчәк Ул».
80 Ә бала үсә һәм рухи яктан
ныгый бирде. Ул, Исраил
халкына күренер вакыт җит-
кәнче, чүл якларында гомер
сөрде.



ирештe, хатыным да бала ту-
дырмаучыдыр». Аллаһ әйтте:
«Әнә шулай Аллаһу Тәгалә
теләгәнен кылыр».
41 Зәкәрия әйтте: «Ий Раббым,
хатынымның йөкле булуына
миңа бер галәмәт бир». Ал-
лаһ әйтте: «Синең кешеләр
белән сөйләшә алмавың сиңа
галәмәт булыр, кешеләр бе-
лән өч көн сөйләшә алмас-
сың, мәгәр ишарәт белән ге-
нә сөйләшерсең... Раббыңны
күп зекер ит вә көндезләрен
һәм кичләрен намаз укы!»

**21 сүрә**

89 Вә Зәкәрияне дә хәтерләгез,
Раббысына дога кылып әйт-
те: «Йа Раббым, мине ба-
ласыз ялгыз калдырма, бит
Син варисларның иң хәер-
лесесең!»
90 Аның догасын кабул иттек
вә аңа Яхъяны бирдек, вә
аның хатыны бала тудырмый
торган иде, тудыра торган
кылдык, алар яхшы эшләргә
ашыгучы булдылар, вә Без-
нең хозурыбызда булган сә-
вабка кызыгып һәм куркып
дога кылалар иде, һәм Бездән
даим куркучы булдылар.

**19 сүрә**

12 «Ий Яхъя! Ал Тәүратны нык-
лап, куәт белән!» Вә Без
Яхъяга сабый чагында хик-
мәт, гыйлем бирдек.
13 Без Яхъяга бирдек рәхимле
булуны... пакьлекне бирдек.

Вә ул Аллаһудан куркучы тәкъва булды.
14 Вә ата-анасына изгелек итүче иде, вә ул Аллаһуга гөнаһкяр булмады һәм тәкәбберлек кылмады.
15 Вә Яхъяга туган көнендә вә үлгән көнендә һәм дә кабердән кубарылган көндә Аллаһудан сәламнәр булды.

**6 сүрә**

84 ...изге гамәлле кешене әнә шулай һидаятькә салачакбыз.
85 Янә Зәкәрияне, Яхъяны, Гайсәне, Ильясны һидаятькә салдык, алар һәммәсе изгеләрдән.
86 Дәхи Исмәгыйльне, Әлйәсәгъне, Юнысны вә Лутны һидаятькә салдык, үз заманаларында бөтен дөнья кешеләреннән аларны дәрәҗәдә артык кылдык.
87 ...аларны Без сайладык һәм туры юлга күндердек.

КОРЪӘН



## Гайсә

*Сөенечле хәбәр*

**Лүк 1**

26-27 Элисабет балага узып, алтынчы ай киткәч, Аллаһы Җәбраил фәрештәне Гәлиләя өлкәсендәге Насара шәһәренә, Мәрьям исемле гыйффәтле кыз янына җибәрде. Әлеге Мәрьям Давыт нәселеннән булган Йосыф атлы кешегә ярәшелгән иде.
28 Мәрьям янына килеп, фәрештә: «Иминлек сиңа! Аллаһының мәрхәмәтен кабул итүче син. Раббы синең белән!» – диде.
29 Мәрьям исә бу сүзләрнең мәгънәсен аңларга тырышып кыенсынып калды.
30 Фәрештә аңа: «Курыкма, Мәрьям! Аллаһы сиңа мәрхәмәт кылды.
31 Син буйга узарсың һәм Ир Бала табарсың, Аңа Гайсә дип исем кушарсың.
32 Ул бөек булыр, Аны Хак Тәгаләнең Улы дип йөртерләр. Раббы Алла Аңа борынгы бабасы Давытның тәхетен бирер,
33 Ул Ягъкуб халкы өстеннән мәңге патшалык итәр, һәм патшалыгының ахыры булмас», – диде.
34 Мәрьям исә фәрештәдән: «Ничек шулай була алыр

ИНҖИЛ

## Гайсә

*Сөенечле хәбәр*

**3 сүрә**

42 Фәрештә әйтте: «Ий Мәрьям, дөреслектә, Аллаһ сине сайлады вә сине гөнаһтан пакьләде һәм бөтен дөнья хатыннарыннан сине өстен кылды.
43 Ий Мәрьям, Раббыңа итагать кыл һәм рөкүгъ, сәҗдә кылып намаз укучылар белән намаз укыгыл!
44 Бу Мәрьям кыйссасы Коръән иңмәс борын синең өчен яшерен иде, инде вәхи белән белдерәбез: мәсҗид Әкъса мөселманнары шобага өчен каләмнәрен суга салганда, син алар арасында юк идең һәм Мәрьямне тәрбиягә алыр өчен тартышкан вакытларында да яннарында юк идең.
45 Җәбраил әйтте: «Ий Мәрьям, Аллаһ сине бер бала белән шатландырадыр. Ул бала атасыз, Аллаһуның „бар бул“ дип әйтүе белән булыр, ул баланың исеме Гайсә, Мәрьям угълы, булыр, ул бала дөньяда һәм ахирәттә дәрәҗә иясе вә Аллаһуга якыннардан булыр».
47 Мәрьям әйтте: «Ий Раббым, миңа бала кайдан булсын, чөнки миңа ир затының кулы тигәне юк». Аллаһ әйтте:

КОРЪӘН

икән? – дип сорады. – Мин
бит әле кияүдә түгелмен!»
35 «Изге Рух иңеп, сине Аллаһы
Тәгаләнең кодрәте каплап
алачак, шуңа күрә синнән
туачак Бала изге булыр һәм
Аллаһы Углы дип аталыр, –
дип җавап бирде фәрештә. –
36 Менә, кардәшең Элисабет тә
картайган көнендә балага уз-
ды, ул ир бала көтә. Кешеләр
аның турында, авырга уза
алмый, дип әйтәләр иде, ә ул
инде алтынчы аен авырлы,
37 чөнки Аллаһы булдыра алма-
ган эш юк».
38 Шуннан Мәрьям: «Мин – Раб-
бы бәндәсемен, син ничек
әйтсәң, шулай булсын», –
диде. Һәм фәрештә аның
яныннан китеп барды.

**Маттай 2**

13 Алар китү белән, Раббы фә-
рештәсе Йосыфның төшендә
күренеп: «Баланы анасы бе-
лән алып, Мисырга кач. Мин
сиңа әйткәнгә кадәр, шунда
кал, чөнки Һируд Баланы
табып үтерергә ниятли», –
диде.

### *Гайсәнең тууы*

**Лүк 2**

1 Шул көннәрдә Рим кайсары
Август үз кул астындагы



«Әнә шулай Аллаһ Үзе телә-
гән нәрсәне халык кылыр.
Бер нәрсәне булдырырга те-
ләсә фәкать: „Бул!“ – дияр,
ул нәрсә Ул теләгәнчә бар
булыр».
48 Аллаһ Гайсәгә язу белемен,
шәригать хөкемнәрен һәм
Тәүрат, Инҗил китапларын
өйрәтте.
49 Вә Ягъкуб балаларына рә-
сүл кылды. Гайсә пәйгамбәр
булгач, Ягъкуб балаларына
әйтте: «Мин сезгә Раббыгыз-
дан пәйгамбәрлегемә ачык
дәлилләр һәм галәмәтләр
белән килдем. Ул галәмәт-
ләрнең берсе: балчыктан
кош сурәте ясармын да аңа
өрермен, Аллаһ әмере бе-
лән кош булып очар. Янә
Аллаһ әмере белән сукыр-
ларны күзле итәрмен, ала
тәнле кешеләрне сәламәт-
ләндерермен һәм үлекләрне
тергезермен. Янә мин сезгә
нәрсә ашаганыгыздан, өй-
ләрегездә яшереп саклаган
нәрсәләрегездән хәбәр итәр-
мен. Бу нәрсәләрдә, әлбәт-
тә, минем пәйгамбәрлегемә
тасдыйклаучы галәмәтләр
бар, әгәр хаклыкка ышану-
чылардан булсагыз».

### *Гайсәнең тууы*

**19 сүрә**

22 ...Мәрьям Гайсәгә йөкле бул-
ды һәм корсагындагы йөген





барлык җирләрдә халык са-
нын исәпкә алырга фәрман
бирде.
2 Халык санын исәпкә алу бе-
ренче тапкыр уздырылып,
Сүрия өлкәсе белән ул за-
манда Квирини идарә итә
иде.
3 Теркәлү өчен, һәркем үз нә-
селенең шәһәренә кайтырга
тиеш иде.
4 Давыт нәселеннән булганга
күрә, Йосыф та Гәлиләядәге
Насара шәһәреннән Яһүди-
ягә, Давыт шәһәре саналган
Бәйт-Лехемгә китте.
5 Исемлеккә теркәлер өчен, Йо-
сыф үзенә ярәшелгән Мәрь-
ям белән бергә барды. Бу
вакытта Мәрьям авырлы иде.
6 Бәйт-Лехемдә чакта Мәрьям-
нең бала табар вакыты җитте.
7 Мәрьям үзенең беренче Бала-
сын – Ир Бала тапты. Ул Аны
биләүдә дә утлыкка салды,
чөнки аларга кунак йортын-
да урын табылмады.
8 Әлеге төндә шул тирәдә берни-
чә көтүче кырда сарыкларын
саклый иде.
9 Кинәт кенә алар каршын-
да Раббы фәрештәсе пәйда
булып, әйләнә-тирә Раббы
шөһрәтеннән балкып китте.
Көтүчеләр бик нык курык-
тылар.
10 Фәрештә исә аларга: «Курык-
магыз! Мин сезгә куанычлы
хәбәр – бөтен халык өчен



күтәреп, кавеменнән аеры-
лып ерак җиргә китте.
23 Бала табуның авырлыгы ки-
терде ул Мәрьямне хөрмә
агачының кәүсәсенә. Мәрьям
әйтте: «Бу хәлне күрмәс бо-
рын үлгән булсам ни булыр
иде һәм үлеп онытылып бет-
кән булсам».
24 Мәрьямнең урынынан түбән
җирдән Җәбраил кычкырды:
«Ий Мәрьям, кайгырма, тәх-
кыйк, Раббың аяк астында
чишмә кылды.
25 Ий Мәрьям, хөрмә агачының
кәүсәсеннән тотып үзеңә та-
ба селкет, төшерер сиңа яңа
өлгергән хөрмә җимешен.
26 Ул хөрмәне аша һәм чишмә
суын эчкел, ул угълың Гай-
сә белән күзең карарланып,
кайгың бетсен! Әгәр бер ке-
шене... баланың хакында син-
нән сорар күрсәң әйт: „Мин
Аллаһ ризасы өчен һичкем
белән сөйләшмәскә нәзер
әйттем...“»
27 Гайсәне тудыргач кавеме яны-
на күтәреп килде. Кавеме
әйттеләр: «Ий Мәрьям, яра-
маган олугъ эш белән кил-
дең.
28 Ий Һарунның кыз кардәше,
атаң Гимран яман юлда түгел
иде, анаң да азгын түгел иде».
29 Мәрьям, угълы Гайсә белән
сөйләшергә ишарәт ит-
те. Алар әйттеләр: «Безне
мәсхәрә итәсең, бишектәге

зур шатлык алып килдем, —
диде. —
11 Бүген Давыт шәһәрендә сез-
нең Коткаручыгыз — Мәсих,
Хаким туды!
12 Сезгә менә шундый билге:
утлыкта яткан биләүле Ба-
ланы күрерсез».
13 Кинәт фәрештә янында күк
гаскәре — күп санлы фәреш-
тәләр күренде, һәм алар:
14 «Күкләрдәге Аллаһыга дан!
Аллаһы илтифат күрсәткән
кешеләргә җирдә иминлек
булсын!» — дип Аллаһыны
данладылар.
15 Фәрештәләр күккә күтә-
релгәннән соң, көтүче-
ләр бер-берсенә: «Әйдәгез
Бәйт-Лехемгә барыйк, анда
ниләр булганны, Раббы әйт-
кәннәрне күрик», — диделәр.
16 Алар, ашыгып, Бәйт-Лехемгә
килделәр һәм анда Мәрьям
белән Йосыфны, утлыкта
яткан Баланы күрделәр.
17 Баланы күргәннән соң алар
Аның хакында үзләренә әй-
телгән сүзләрне башкаларга
да сөйләделәр.
18 Көтүчеләр сөйләгәнне ишет-
кән кешеләрнең барысы хәй-
ран калды.
19 Мәрьям исә боларның һәммә-
сен күңеленә салып куйды
һәм шул хакта уйлап йөрде.
20 Ишеткән һәм күргән бар-
лык нәрсәләр өчен Алла-
һыны данлап һәм мактап,



сабый бала белән ничек сөй-
ләшик?»
30 Гайсә аларның сүзләрен ишет-
кәч әйтте: «Мин Аллаһу Тә-
галәнең колымын, Ул миңа
китап бирде һәм мине пәй-
гамбәр итте.
31 Кайда гына булсам да, кеше-
ләр өчен мине мөбарәк-фай-
далы итте вә миңа намаз
укырга әмер итте һәм зәкят
бирергә әмер итте терек бул-
ган вакытымда.
32 Янә анама изгелек итүче кыл-
ды, мине тәкәбберләнүче вә
Үзенә гөнаһ кылмаучы ит-
мәде.
33 Туган көнемдә вә үлгән кө-
немдә һәм кабердән куба-
рылган көнемдә Аллаһудан
миңа сәламдер».
34 Ошбу сүзләрне сөйләүче ке-
ше Мәрьям угълы Гайсәдер,
насара ихтыйлаф итә торган
сүзләр арасыннан хак сүз-
ләрне сөйләде.
35 Бала тудырмак Аллаһуга ла-
ек булмады, Ул бала тудыру
кимчелегеннән пакь! Әгәр
бер нәрсәне булдырырга
теләсә, ул нәрсәгә фәкать:
«Бул!» — дип әйтер, ул нәрсә
шундук булыр.
36 Тәхкыйк, Аллаһ минем һәм
сезнең дә Раббыгыз, Аңа
гыйбадәт итегез! Аллаһыга
гыйбадәт кылу, Коръән өй-
рәтүе буенча дин тоту туры
юлдыр.





көтүчеләр үзләренең мал-
лары янына кайттылар. Ба-
рысы да фәрештә әйткәнчә
булды.
21 Сигез көн үтеп, Баланы сөн-
нәткә утырту вакыты җит-
кәч, Аңа Гайсә дигән исем
куштылар. Әнкәсе Мәрьям
авырга узганчы ук, Балага
фәрештә әнә шул исемне
кушкан иде.

***Гайсәнең сүзләре***

**Маттай 11**

5 «...сукырлар янә күрә, аксак-
лар йөри, махаулылар таза-
рына, чукраклар ишетә, үл-
гәннәр терелә һәм фәкыйрь-
ләргә Яхшы хәбәр игълан
ителә».

**Маттай 5**

17 «Минем хакта, Муса канунын
яки пәйгамбәрләр язганнар-
ны юкка чыгарырга килгән,
дип уйламагыз. Мин юкка
чыгарырга дип түгел, баш-
карырга дип килдем!»



37 Мәрьям ирсез бала тудыргач,
кешеләр араларында ихтый-
лаф иттеләр, ни каты үкенеч
хакны инкяр итүчеләргә, га-
забы каты, куркынычы олугъ
булган кыямәт көненең ки-
лүеннән.
38 Алар безнең хозурыбызга кил-
гән көннәрендә яхшы ише-
терләр вә яхшы күрерләр,
ләкин Аллаһуга карышып за-
лим булган кешеләр ул көндә
ачык адашу-алдanудадыр.
39 Газап киләчәге белән хөкем
ителгән хәсрәтле көн белән
аларны куркыт! Алар газап-
ның килүеннән гафләттә-
ләр, алар иман китерәчәк
түгелләр.
40 Әлбәттә, Без җиргә вә җир-
дән булган һәр нәрсәгә варис
булырбыз вә ахирәттә алар
Безгә кайтарылырлар.

***Гайсәнең сүзләре***

**3 сүрә**

49 Вә Ягъкуб балаларына рә-
сүл кылды. Гайсә пәй-
гамбәр булгач, Ягъкуб
балаларына әйтте: «Мин
сезгә Раббыгыздан пәй-
гамбәрлегемә ачык дә-
лилләр һәм галәмәтләр
белән килдем. Ул галәмәт-
ләрнең берсе: балчыктан
кош сурәте ясармын да
аңа өрермен, Аллаһ әме-
ре белән кош булып очар.
Янә Аллаһ әмере белән

**Марк 2**
27 «Кеше шимбә көн өчен түгел, ә бәлки шимбә көн кеше өчен яратылган...»
**Марк 7**
15 «Кеше эченә читтән кергән һичнәрсә аны нәҗесли алмый, киресенчә, эченнән чыккан нәрсә кешене нәҗесли».
**Маттай 5**
1 Халык төркемнәрен күреп, Гайсә тауга менде. Ул утыргач, янына шәкертләре килделәр.
2 Гайсә аларга гыйлем биреп сөйли башлады:
3 «Рухи яктан фәкыйрьләр бәхетле, чөнки Күкләр Патшалыгы аларныкы.
4 Хәсрәт кичерүчеләр бәхетле, чөнки аларны юатырлар.
5 Юашлар бәхетле, чөнки алар җирне мирас итеп алырлар.
6 Тәкъвалыкка ачыккан һәм сусаган кешеләр бәхетле, чөнки аларның ул теләге үтәлер.
7 Шәфкатьлеләр бәхетле, чөнки аларга шәфкать күрсәтелер.
8 Саф күңеллеләр бәхетле, чөнки алар Аллаһыны күрерләр.
9 Татулык урнаштыручылар бәхетле, чөнки аларны Аллаһы балалары дип атарлар.
10 Тәкъва булганнары өчен эзәрлекләнгәннәр бәхетле, чөнки Күкләр Патшалыгы аларныкы.



сукырларны күзле итәрмен, ала тәнле кешеләрне сәламәтләндерермен һәм үлекләрне тергезермен. Янә мин сезгә нәрсә ашаганыгыздан, өйләрегездә яшереп саклаган нәрсәләрегездән хәбәр итәрмен. Бу нәрсәләрдә, әлбәттә, минем пәйгамбәрлегемә тасдыйклаучы галәмәтләр бар, әгәр хаклыкка ышанучылардан булсагыз.
50 Миннән әүвәл индерелгән Тәүратны тасдыйк иткәнем хәлдә һәм сезгә хәрам булган нәрсәләрнең кайберләрен хәләл иткәнем хәлдә, Раббыгыздан галәмәтләр белән сезгә пәйгамбәр булып килдем. Шулай булгач, Аллаһудан куркыгыз, миңа итагать итегез һәм карышудан сакланыгыз.
51 Дөреслектә, Аллаһы мине дә, сезне дә тәрбия кылучыдыр. Тәрбияче булган Аллаһуга, әлбәттә, гыйбадәт кылыгыз! Бит Аллаһуга итагать итү һәм Аңа гына гыйбадәт кылу – иң туры юл».
**25 сүрә**
63 Аллаһуның яхшы бәндәләре җир өстендә тәртип белән вә түбәнчелек белән йөрерләр, әгәр аларны җаһилләр кирәкмәгән сүзләр белән хитаб итсәләр, аларга каршы гөнаһтан пакь сүзне әйтерләр.





11 Кешеләр сезне Минем аркада хурлаганда, эзәрлекләгәндә һәм сезгә каршы төрле явызлык эшләгәндә, сез бәхетле.
12 Шатланыгыз һәм куаныгыз, чөнки күкләрдә сезгә әҗере зур булачак. Сезгә кадәр яшәгән пәйгамбәрләрне дә шулай эзәрлекләгәннәр». <...>
34 «Ә Мин әйтәм: бөтенләй дә ант итмә! Күк белән дә ант итмә, чөнки ул – Аллаһының тәхете.
35 Җир белән дә ант итмә, чөнки ул – Аллаһының аяк басу урыны. Иерусалим белән дә ант итмә, чөнки ул – бөек Патшаның шәһәре». <...>
38 «Сез „Күзгә – күз“ һәм „тешкә – теш“ диелгәнне ишеттегез.
39 Ә Мин сезгә әйтәм: үзеңә явызлык кылучыга каршы килмә. Уң яңагыңа суккан кешегә сул яңагыңны да куй.
40 Берәрсе сине хөкемгә тартып, күлмәгеңне алырга теләсә, аңа өске киемеңне дә бир».
**Маттай 6**
1 «Тәкъва эшләрегезне кешеләргә күрсәтүдән сакланыгыз. Югыйсә Күктәге Атагыздан әҗер алмассыз.
2 Шуңа күрә, сәдака биргәндә, ул хакта кычкырып йөрмә. Кешеләр аларга мактау яудырсын дип, гыйбадәтханәләрдә һәм урамнарда



**21 сүрә**
105 Тәүрат соңында Давытның Зәбурында яздык: «Дөреслектә, җәннәт җиренә Минем изге колларым варис булырлар», – дип.
**39 сүрә**
74 Һәм җәннәткә кергән кешеләр әйтерләр: «Аллаһуга мактау булсын, Ул безгә биргән вәгъдәсендә торды вә безне җәннәт җиренә хуҗа кылды, хәзер без җәннәтнең теләгән җирендә торабыз, ул җәннәт ни хуш, ни яхшы урындыр изге гамәлләр кылучылар өчен».
**42 сүрә**
40 Явызлык илә золым итүчегә үзе золым иткән хәтле генә җәза бирелә, әгәр мәзлум кеше залимне гафу итсә һәм араларын ислях кылса, бу эшнең әҗере Аллаһ хозурында сакланыр, әмма Аллаһ хаксыз золым итүчеләрне сөймидер.
**2 сүрә**
224 Ий мөэминнәр! Антыгызны Аллаһуга сылтау кылмагыз, ягъни гөнаһлы эшләрне эшләр өчен вә яхшы эшләрне эшләмәс өчен Аллаһ исеме илә ант итмәгез... Бит Аллаһ барча сүзләрне ишетүче һәм һәр нәрсәне белүче.
**16 сүрә**
126 Әгәр бер кешегә, үч алып, газап бирергә теләсәгез, ул

икейөзлеләр шулай эшлиләр. Сезгә хак сүз әйтәм: алар тулысынча әҗерләрен алдылар.

3-4 Ләкин син фәкыйрьгә сәдака биргәндә, ярдәмең яшерен эшләнсен өчен, сул кулың уң кулыңның ни эшләгәнен белмәсен. Яшерен кылынган һәммә эшне күрүче Атаң сиңа әҗереңне бирер.

5 Дога кылганда, икейөзлеләр кебек булмагыз. Алар, барысы да күрсен дип, гыйбадәтханәләрдә һәм юл чатында басып дога кылырга яраталар. Сезгә хак сүз әйтәм: алар тулысынча әҗерләрен алдылар». <...>

19 «Җирдә үзегезгә байлык җыймагыз. Анда аны көя тапый, ул тутыга, караклар урлап чыга».

21 «Хәзинәң кайда булса, күңелең дә шунда булыр». <...>

25 «Шуңа күрә, Мин сезгә әйтәм: җан асрар өчен, нәрсә белән тукланыйм һәм нәрсә эчим, тәнемне каплар өчен, нәрсә киим дип борчылмагыз. Җан – ризыктан, тән киемнән мөһимрәк түгелме соң?

26 Кошларга карагыз: алар чәчмиләр дә, урмыйлар да, ашлыкны амбарларга да салмыйлар, шулай да аларны Күктәге Атагыз туендыра. Ә сез кошлардан кадерлерәк түгелме соң?» <...>



кешегә газап бирегез, ул сезгә газап биргән хәтле генә!.. Әгәр үч алмыйча сабыр итеп калсагыз, бу бик тә хәерледер сабыр итүчеләр өчен!

127 Сабыр итү хәерле булгач, сабыр ит! ...фәкать Аллаһу Тәгалә сабырлык куәтен бирсә генә сабыр итә алырсың! Һәм кяферләрнең исламга килмәгәннәре өчен үзеңне кайгыга салма вә аларның хәйлә-мәкерләре өчен күңелең тарыкмасын!

**2 сүрә**

271 Әгәр садакаларыгызны күрсәтеп, әйтеп бирсәгез, ул күркәм эш. Әгәр яшертен бирсәгез, ул эш сезнең өчен тагын да яхшырак. Бу яхшылыкларыгызны Аллаһ гөнаһларыгызга кәффарәт кылыр. Бит Аллаһ сезнең кылган яхшы эшләрегездән хәбәрдар.

**4 сүрә**

142 Әлбәттә, монафикълар Аллаһуны алдыйбыз дип уйлыйлар, Аллаһ исә аларны дөньяда һидаятьтән, ахирәттә җәннәттән мәхрүм итеп алдаучыдыр. Әгәр монафикълар намазга торсалар, кешеләргә рияланып, ялкауланып кына торалар, күңелләре карарланырлык итеп Аллаһуны зекер итмиләр, ләкин гафил күңел белән бик аз гына зекер итәләр.





31 «Шулай итеп: „Ни ашарбыз, ни эчәрбез, ни киярбез?“ – дип борчылмагыз.

32 Мәҗүсиләрнең төп кайгылары шулдыр. Ә боларның һәммәсенә мохтаҗ булуыгызны Күктәге Атагыз белә.

33 Барыннан да бигрәк Аллаһының Патшалыгын һәм гадел ихтыярын эзләгез, һәм боларның барысы да сезгә насыйп ителәр.

34 Иртәгә булачак көн өчен борчылмагыз. Ул үзе хакында үзе кайгыртыр. Һәр көннең үз мәшәкатьләре җитәрлек».

**Маттай 7**

1 «Берәүне дә хөкем итмәгез, сезне дә Аллаһы хөкем итмәс.

2 Нинди хөкем белән хөкем итсәгез, сез дә шундый хөкем белән хөкем ителерсез. Нинди үлчәм белән үлчәсәгез, сезгә дә шундый үлчәм белән үлчәп бирелер.

3 Ничек син туганың күзендәге чүп бөртеген күрәсең, ә үз күзеңдәге бүрәнәне сизмисең?

4 Үз күзеңдә бүрәнә булганда, син ничек туганыңа: „Күзеңдәге чүпне алыйм әле“, – дип әйтә аласың?

5 Икейөзле! Элек үз күзеңдәге бүрәнәне чыгар, аннары инде күзләрең яхшырак күрер һәм туганыңның күзендәге чүпне ала алырсың.



**107 сүрә**

4 Ни үкенеч вә һәлакәтлелек ихлассыз намаз укучыларга.

5 Алар намазларыннан гафилләр, вакытында укымаслар һәм намазның рөкеннәрен хөрмәт кылмаслар, намазларының вакытыннан кичегүенә кайгырмаслар.

6 Әле алар укыган намазларын да рия белән укырлар...

7 Ул рияче тиешле садакаларны бирмәс...

**3 сүрә**

49 ...мин сезгә нәрсә ашаганыгыздан, өйләрегездә яшереп саклаган нәрсәләрегездән хәбәр бирермен.

**29 сүрә**

60 Күпме хайваннар, кошлар үзләренә ризык хәзерләп куя алмыйлар, Аллаһ аларны да, сезне дә ризыкландырадыр, Ул – Аллаһ – сүзләрегезне ишетүче, күңелләрегезне белүчедер.

**16 сүрә**

79 Әллә ул гафил кешеләр һавадагы кошларга карап гыйбрәт алмыйлармы? Ул кошлар күктә һава эчендә Аллаһ әмере белән очалар... Аллаһуның бу эшендә дә гыйбрәтләр бар иман китергән кешеләр өчен.

**49 сүрә**

12 Ий мөэминнәр, күп гөманнан сакланыгыз, тәхкыйк, бәгъзе гөманда гөнаһ бардыр. Вә кешеләрнең гаепләрен

6 Изге нәрсәне этләргә бирмәгез: алар, сезгә борылып, үзегезне ботарлар. Энҗегезне дуңгызлар алдына сипмәгез: алар энҗегезне аяклары белән таптарлар.
7 Сорагыз – сезгә бирерләр, эзләгез – табарсыз, шакыгыз – сезгә ачарлар.
8 Чөнки һәр сораучы ала, эзләүче таба һәм шакучыга ачалар.
9 Арагыздан кайсыгыз икмәк сораучы углына таш тоттырыр?
10 Ул балык сораганда, кайсыгыз елан бирер?
11 Әгәр сез, явыз кешеләр булып та, балаларыгызга яхшы бүләкләр бирә беләсез икән, Күктәге Атагызның Үзеннән сораганнарга яхшы нәрсәләрне бирүе шөбһәсездер.
12 Кешеләрнең сезгә нәрсә эшләүләрен теләсәгез, үзегез дә аларга шуны эшләгез. Муса канунының һәм пәйгамбәрләр язганнарның мәгънәсе шундадыр.
13 Тар капкадан керегез, чөнки һәлакәткә илтүче юл җиңел, капкасы да киң, һәм күпләр шул капкадан керәләр.
14 Ә тормышка керә торган капка кысан, юлы тар, һәм аны азлар гына таба.



тикшермәгез, кеше гаебен эзләмәгез, вә бәгъзегез бәгъзегезне гайбәт кылмасын! Әллә сезнең берәрегез үлгән кардәшенең итен ашауны сөярме? Сез, әлбәттә, аны мәкруһ күрдегез, гайбәт сөйләүне дә шулай мәкруһ күрегез! Аллаһудан куркыгыз, гайбәт эшләреннән тәүбә итегез! Шиксез, Аллаһ тәүбә итеп төзәлгән кешеләрне гафу итүче вә рәхимледер.

**13 сүрә**

29 Бит иман китереп тә изге гамәлләр кылган кешеләргә, шиксез, шатлык, хушлык вә туба агачы астында күләгәләнү булыр вә күркәм урыннар булыр.

**90 сүрә**

8 Әллә Без ул кешегә ике күз бирмәдекме?
9 Дәхи аны телле вә ике иренле кылмадыкмы?
10 Дәхи кешене ике юлның берсенә: йә һидаятькә, йә азгынлыкка күндердек түгелме?
11 Ул бөек таулардан үтмәде.
12 Ул бөек таулар юлын сиңа нәрсә белдерде?
13 Ул юл – кол азат итмәктер.
14 Яки ачлык көннәрендә аш бирмәктер
15 якын кардәш булган ятимгә.
16 Яки гаять тә фәкыйрь булган мескенгә аш бирмәктер.
17 Янә хәерле эш: чын мөэмин булып, мөэминнәрне







15 Яныгызга сарык тиресе ябынып килүче ялган пәйгамбәрләрдән сакланыгыз: эчендә ерткыч бүреләр алар.
16 Сез аларны җимешләренә карап танырсыз. Күгән куагыннан – йөзем, тигәнәктән инҗир җыялармыни?
17 Менә шулай, яхшы агач – яхшы җимеш, ә начар агач начар җимеш бирә.
18 Яхшы агач – начар җимеш, начар агач та яхшы җимеш бирә алмый.
19 Яхшы җимеш бирми торган һәр агачны, кисеп, утка ташлыйлар.
20 Шулай итеп, ялган пәйгамбәрләрне җимешләренә карап танырсыз». <...>
24 «Шулай итеп, сүзләремне ишетеп, аларны үтәүче һәркем үзенең йортын таш өстенә салган акыллы кешегә охшаган.
25 Яңгыр явып, елгалар ташып, көчле җилләр исеп, шул йортка ябырылган, әмма ул җимерелмәгән, чөнки таш нигез өстенә салынган булган ул.
26 Ә инде ишетеп тә, сүзләремне үтәмәүче кеше үзенең йортын ком өстенә төзегән акылсыз кешегә охшаган.
27 Яңгыр явып, елгалар ташып, көчле җилләр исеп, шул йортка ябырылган. Ул йорт



сабырлы, чыдамлы булырга һәм үзара мәрхәмәтле, шәфкатьле булырга өндәүче кинәш бирүче булудыр.

**14 сүрә**

24 Беләсеңме, «Ля Иләһә Илләллаһ» сүзенә Аллаһ нинди гаҗәп мисал китерә, ул сүз яхшы үскән агач кебек, аның тамырлары җирдә мәхкәм, ботаклары күккә үрелгән...

**9 сүрә**

109 Әгәр берәү мәсҗидне Аллаһудан куркып вә Аның ризалыгын эстәп бина кылса, ягъни динен Коръән өйрәтүе буенча дөрес итеп тотса, шулмы хәерле булыр? Яки бинасын җимерелә торган яр өстенә салган монафикъның бинасы хәерлеме? Ягъни Коръәннән башка ялган динне тотучының дине хәерлеме? Коръән хөкемнәре йөрми торган мәсҗидләрне төзүчеләр мәсҗидләре белән бергә җәһәннәмгә ишелеп төшәрләр, шулай ук бидгатьләрдән төзелгән батыйль динне тотучылар диннәре белән бергә җәһәннәмгә ишелеп төшәрләр. Әлбәттә, Аллаһ Коръән белән гамәл кылмаучы залимнәрне һидаятькә салмас.

**2 сүрә**

264 Ий мөэминнәр! Биргән садакаларыгызны миннәт кылып яки рәнҗетеп биреп, савабын югалтмагыз! Рия белән

җимерелгән, һәм аның җимерелүе коточкыч булган».

**Маттай 19**

24 «Тагын сезгә әйтәм: бай кешегә Аллаһы Патшалыгына керүгә караганда, дөягә энә күзе аша үтү җиңелрәк».

**Маттай 18**

20 «Чөнки икәү яки өчәү Минем хакка җыелса, Мин дә алар белән булачакмын».

биргән кешеләр – кяферләр кебек, алар Аллаһуга һәм ахирәт көненә ышанмыйлар, шулай да кешеләргә яхшы күренер өчен садака бирәләр. Рия белән яки рәнҗетү белән бирелгән садаканың мисалы – өстенә туфрак кунган шома таш кебек, яңгыр суы туфракны юып төшерә дә, таш тап-такыр булып, ялангач кала. Алар биргән садакаларының әҗеренә ирешергә һич кадир булмаслар. Алар Коръән белән гамәл кылмыйча кяфер булган кешеләрне туры юлга күндермәс.

265 Аллаһ ризалыгын эстәп, сәвабын өмет итеп һәм сәваб булачагына күңелдән нык ышанып, Аллаһ күрсәткән урыннарга садака бирүчеләрнең мисалы – эре яңгырлы явым яуган калку җирдәге бакча кебек. Ул бакча башка бакчаларга караганда җимешне ике өлеш бирә. Әгәр ул бакчага эре яңгыр яумаса, вак яңгырява, һәрхәлдә яумый калмас. Аллаһ сезнең кылган эшләрегезне күрүче.

**7 сүрә**

40 Бәгъзе кешеләр аятьләребезне ялган диделәр вә аятьләребез белән гамәл кылудан тәкәбберләнделәр, аларга күк ишекләре ачылмас... һәм





*Аллаһы һәм Гайсә*

**Марк 8**

27 Гайсә Үзенең шәкертләре белән Филип Кайсариясе шәһәре тирәсендә урнашкан авылларга китте. Юлда барганда, Ул шәкертләреннән: «Кешеләр Мине кем дип белә?» – дип сорады.

28 «Берәүләр Сине – Чумдыручы Яхъя, икенчеләр – Ильяс,

җәннәткә кермәсләр, хәтта дөя энә күзеннән чыкканчы, ягъни дөянең энә күзеннән чыгуы мөмкин булмаса, аларның да җәннәткә керүе мөмкин түгел. Залимнәрне әнә шулай җәза кылырбыз.

**58 сүрә**

7 Йә беләсеңме, тәхкыйк, Аллаһ җирдә вә күкләрдә булган нәрсәләрне беләдер, булмас өч кешенең яшерен сөйләшүләре, мәгәр Аллаһ дүртенчесе булып сүзләрен тыңлар, булмас биш кешенең яшерен сөйләшүләре, мәгәр Аллаһ алтынчысы булып сүзләрен ишетер, дәхи болардан азрак бер кеше, яки күбрәк алты, җиде кеше сөйләшмәсләр, мәгәр кайда гына булсалар да, Ул – Аллаһ – алар белән бергәдер, соңра аларның эшләгән эшләреннән хәбәр бирер кыямәт көнендә, әлбәттә, Аллаһ һәрнәрсәне белүчедер.

*Аллаһы һәм Гайсә*

**3 сүрә**

52 Гайсә, мөшрикләрнең һаман көферлекләрендә дәвам иткәннәрен күргәч: «Аллаһ diненә миңа кем ярдәмче була?» – диде. Гайсәгә ияргән мөэминнәр: «Аллаһ диненә без ярдәмче булабыз, без Аллаһуга нык ышандык. Аллаһуга итагать итүче хак

кайберәүләр исә пәйгамбәрләрнең берсе дип исәпли», — диде алар.
29 «Ә сез, сез Мине кем дип беләсез?» — дип сорады Ул алардан.
«Син — Мәсих», — дип җавап бирде Петер.
30 Гайсә аларга Үзе хакында беркемгә дә сөйләмәскә кушты.

**Яхъя 15**

26 Яхъя аларга: «Мин чумдыру йоласын су белән башкарам. Әмма арагызда сез белмәгән Берәү тора,
27 Артымнан Килүче нәкъ менә Ул инде, ә мин Аның аяк киеме каешын чишәргә дә лаек түгелмен», — дип җавап бирде.

**Яхъя 17**

1 Гайсә бу сүзләрдән соң күккә күтәрелеп карап: «Атам! Вакыт җитте, — диде. — Углың Сине данласын өчен, Углыңны данла». <...>
19 «Алар да хакыйкать белән изге ителсеннәр дип, Үземне алар хакына изге итәм.
20 Мин алар өчен генә түгел, аларның сүзе аркылы Миңа иман китерүчеләр өчен дә үтенәм:
21 бөтенесе бер булсын иде. Атам, Син Миндә һәм Мин Синдә булгандай, Синең Мине җибәргәнеңә дөнья ышансын өчен, алар да Бездә булсыннар».



мөселман икәнлегебезгә шаһит бул», — диделәр.
53 Ий Раббыбыз, Син индергән китапларга ышандык һәм пәйгамбәргә иярдек. Безләрне Синең берлегең вә исламның хаклыгы белән шәһадәт бирүче мөселманнар белән бергә кыл!
58 Ий Мөхәммәт г-м, Без сиңа укыган кыйссалар синең пәйгамбәрлегеңә ишарәт итүче дәлилләр. Вә Без вәхи кылган сүзләр — барча хикмәтләрне зекер итүче Коръән кәримдер.
59 Гайсәнең атасыз халык кылынуының мисалы Аллаһ хозурында Адәм г-м кебектер. Адәмнең тәнен балчыктан төзеде дә соңрак аңа: «Адәм бул!» — дип әйтүе белән булды.
60 Гайсә хакында булган хак сүзләр Раббыңнан — шикләнүчеләрдән булма!
61 Ачык дәлилләр килгәннән соң берәү Гайсә хакында синең белән бәхәсләшсә, син аларга әйт: «Без үзебез, балаларыбыз һәм хатыннарыбыз һәм сез үзегез, балаларыгыз һәм хатыннарыгыз бер урынга җыелыйк, аннары Гайсә хакында кем ялган сөйләсә, аңа Аллаһуның ләгънәте булсын дип Аллаһудан сорап бер-беребезгә дога кылышырбыз», — дип.





**Маттай 25**

40 Патша аларга җавабында: «Сезгә хак сүз әйтәм: кечкенә туганнарымның берсенә нәрсә генә эшләгән булсагыз да, Миңа эшләгән буласыз», — дип әйтер.

**Филиппуйлыларга хат 2**

5 Фикер йөртүегез Мәсих Гайсәнекедәй булсын.
6 Табигате буенча Аллаһы булып та, Ул Аллаһыга тиң булуын күрсәтергә тырышмады,
7 бар нәрсәдән Үз теләге белән баш тартты. Кол табигате алып, Ул кешегә охшаш булды. Кеше кыяфәтендә яшәп,
8 Ул Үзен түбәнсетте һәм үлеменә кадәр, хәтта хачтагы үлеменә кадәр, Аллаһыга күндәм булды.
9-11 Шуңа күрә күктә, җирдә һәм җир астында булганнарның барысы да Гайсә исеме алдында тез чүксен, һәм Атабыз Аллаһының даны өчен һәрбер тел Гайсә Мәсихне Хаким дип танысын өчен, Аллаһы Аны барысыннан да югары күтәрде һәм Аңа бөтен исемнәрдән бөегрәк исем бирде.

**Яхъя 1**

1 Иң башта Сүз булган, Сүз Аллаһы белән булган, һәм Сүз Аллаһы булган.
2 Сүз иң башта ук Аллаһы белән булган.



**19 сүрә**

33 «Туган көнемдә вә үлгән көнемдә һәм кабердән кубарылган көнемдә Аллаһудан миңа сәламдер».
34 Ошбу сүзләрне сөйләүче кеше Мәрьям углы Гайсәдер, насара ихтыйлаф итә торган сүзләр арасыннан хак сүзләрне сөйләде.
35 Бала тудырмак Аллаһуга лаек булмады, Ул бала тудыру кимчелегеннән пакь! Әгәр бер нәрсәне булдырырга теләсә, ул нәрсәгә фәкать: «Бул!» — дип әйтер, ул нәрсә шундук булыр.
36 Тәхкыйк, Аллаһ минем һәм сезнең дә Раббыгыз, Аңа гыйбадәт итегез! Аллаһуга гыйбадәт кылу, Коръән өйрәтүе буенча дин тоту туры юлдыр.

**4 сүрә**

171 Ий китап әһелләре! Динегездә хактан тышкары чыкмагыз, Аллаһ хакында ялганны сөйләмәгез, мәгәр Аңа әйтергә тиешле хак сүзләрне генә әйтегез! Мәрьям углы — Гайсә — Аллаһуның рәсүленнән башка һичкем түгел, ул — Гайсә — Аллаһуның: «Бар бул!» — дигән сүзе белән бар булды, ул сүзне Аллаһ Мәрьямгә ишеттерде вә ул сүз Мәрьям карынына рух булып иреште. Аллаһуга вә рәсүлләренә ышаныгыз!

[3] Бар нәрсә Сүз аша яратылган, һәм яратылган һәр нәрсә Аңардан башка яратылмаган. <...>

[14] Сүз Кеше булды, безнең арада яшәде, мәрхәмәт вә хакыйкать белән тулы иде Ул. Без Аның данын, Атаның бердәнбер Углына биргән данын күрдек. <...>

[18] Аллаһыны беркем, беркайчан күрмәгән. Аны Ата өчен иң якын, бердәнбер Углы безгә танытты.



Һәм «Аллаһ өч» дип һич тә әйтмәгез! Ул сүздән тыелыгыз, әгәр тыелсагыз, үзегез өчен хәерледер. Дөреслектә, Аллаһ тиңдәше юк бер Аллаһудыр, баласы булудан Аллаһ гаять пакь, янә җирдә, күкләрдәге һәрнәрсә аныкы һәм дә кешеләр өстеннән вәкил булырга Аллаһ җитә.

**2 сүрә**

[116] Яһүдләр һәм насаралар әйттеләр: «Аллаһ бала тудырды», — дип. Аллаһ бала тудыру кимчелегеннән пакь, җирдә һәм күкләрдә булган барча мәхлук Аныкы. Барчасы да Аллаһуга итагать итәләр һәм Аңа гына гыйбадәт кылалар.

**4 сүрә**

[157] Янә аларны Аллаһ ләгънәт кылды: «Без, әлбәттә, Аллаһ рәсүле Мәрьям угълы Гайсәне үтердек», — дигән сүзләре өчен. Алар Гайсәне үтермәделәр һәм асмадылар, ләкин аларның бер юлдашы аларга Гайсә сурәтендә күренде... Яһүдләр, әлбәттә, Гайсә хакында ихтыйлафта булдылар, әгәр Гайсәне үтергән булсак, юлдашыбыз кайда? Аларның бу ихтыйлафлары, әлбәттә, занга иярүләреннән булды, алар һичшиксез Гайсәне үтермәделәр.

[158] Бәлки Аллаһ аны Үз хозурына күтәрде. Аллаһу Тәгалә







***Гайсәнең кыяфәте үзгәрү***

**Марк 9**

[2] Алты көн узганнан соң, Петер, Ягъкуб һәм Яхъяны Үзе белән алып, Гайсә биек тауга күтәрелде. Анда алар үзләре генә иде. Шулчак аларның күз алдында Гайсәнең кыяфәте үзгәреп китте.

[3] Аның киеме җир йөзендә һичкем шулай агарталмаслык, күз чагылдырырлык ак төскә керде. <...>

[7] Шулчак аларны болыт каплап алып, болыт эченнән «Бу Минем сөекле Углымдыр, тыңлагыз Аны!» дигән өн килеп иреште.

[8] Шәкертләр кинәт кенә як-якларына каранып алдылар, әмма яннарында Гайсәдән башка һичкемне күрмәделәр.

[9] Таудан төшкән чакта, Гайсә аларга, Адәм Углы үледән терелгәнчегә кадәр бирердә күргәннәрегезне һичкемгә әйтмәгез, дип боерды.

[10] Алар әлеге боерыкны үтәделәр, әмма үзара: «Аның „үледән терелү“ дигәне нәрсә аңлата икән?» — дип баш ваттылар.



һәр эштә галиб һәм хикмәт белән эшләүче булды.

***Гайсәнең кыяфәте үзгәрү***

**3 сүрә**

[54] Кяферләр Гайсәгә явыз хәйлә кордылар. Аллаһ аларга каршы көчле хәйләне корды. Бит Аллаһ хәйлә коручыларның хәерлесе вә көчлеседер...

[55] Аллаһ әйтте: «Ий Гайсә, Мин, әлбәттә, сине үтерүче һәм Үз хозурыма күтәрүчемен һәм сине кяферләрнең явыз хәйләсеннән саклап пычрак йогынтыларыннан пакьләүчемен. Янә, ий Гайсә, сиңа ияргән мөэминнәрне кыямәт көненә чаклы кяферләрдән өстен кылучымын. Кяферләр белән арагызда булган ихтыйлаф эшләрдә хөкем итәрмен.

[56] Әмма Коръән белән гамәл кылмыйча кяфер булган кешеләрне дөньяда һәм ахирәттә каты газап белән газап кылырмын, Минем газабымнан котылырга аларга ярдәмче булмас».

[57] Әмма иман китереп изге гамәлләр кылучы мөэминнәрнең әҗерен тулысынча Аллаһ Үзе бирер. Ләкин Коръән белән гамәл кылмаучы залимнәрне Аллаһ һич тә сөйми.

*Кыямәт көне*

**Марк 13**
24 «Ул көннәрдә, шул афәттән
соң, „кояш каралыр, ай як-
тыртмас,
25 йолдызлар күктән коелып,
күк җисемнәре тетрәнер“».
**Маттай 24**
45 «Шулай итеп, хезмәтчеләргә
ризыкны үз вакытында өлә-
шү өчен, хуҗа тарафыннан
башлык итеп куелган ыша-
нычлы һәм акыллы хезмәтче
нинди була соң?
46 Хуҗасы әйләнеп кайтып,
аның шулай эшләвен күрсә,
менә шул хезмәтче сәгадәтле.
47 Сезгә хак сүз әйтәм: хуҗасы
аны бөтен милкенә башлык
итеп куяр.
48 Ләкин ул хезмәтче начар бул-
са һәм: „Хуҗам тиз кайтмас
әле“, – дип уйлап,
49 башка хезмәтчеләрне кыйный,
үзе эчкечеләр белән ашап-эчә
башласа,
50 хуҗасы ул көтмәгән көндә һәм
уйламаган сәгатьтә кайтып
керер дә
51 аны җәзага тартыр һәм ике-
йөзлеләр белән бер язмышка
дучар итәр: анда елау һәм теш
шыкырдату булыр».
**Ишагыйя 34**
1 Әй халыклар, якынрак килеп
тыңлагыз! Кавемнәр, игъ-
тибар итегез! Җир вә анда
булган һәр нәрсә, дөнья вә



*Кыямәт көне*

**52 сүрә**
7 Тәхкыйк, Раббыңның газабы
вакыйга булучыдыр, ягъни,
әлбәттә, булачактыр.
8 Бу газапны кире җибәрүче һич
юктыр.
9 Аллаһуның газабы вакыйга бу-
лыр, күк каты әйләнеп каты
селкенгән көндә.
10 Вә таулар каты йөргән көндә.
11 Ни үкенеч һәм ачы хәсрәт, ка-
ты газаптыр ул көндә Коръ-
әнне ялган диючеләргә яки
аның белән гамәл кылмау-
чыларга.
12 Алар хакны инкяр итеп, бозык
эшләрне эшләү белән һәм
ялган сөйләү белән уйнау-
чылардыр.
13 Ул көндә куллары-аяклары
богауланып җәһәннәмгә өс-
терәлерләр.
14 Вә аларга әйтелер: «Бу ут – сез
аны ялганга тоткан идегез,
15 сез дөньяда вакытта Коръәнне
„сихер“ диядер идегез, бу ут
газабы да сихерме? Әллә ут
газабын күрмисезме? Бик ях-
шы күрәсез, ләкин дөньяда
хакны күрергә теләмәдегез.
16 Инде керегез ул утка һәм га-
забын татыгыз! Кирәк – чы-
дагыз, кирәк – чыдамагыз,
сезнең өчен бертигездер,
газабыгыз җиңеләймәс, сез
фәкать кылган явызлыгыгыз
өчен җәзаланырсыз», – дип.





ГАЙСӘ

анда туган һәр нәрсә тыңлап
торсын!
2 Раббының барча халыкларга
ачуы чыкты, аларның барлык
гаскәрләренә каһәре төште
Аның. Ул аларны тулысынча
кырып ташлады, бугазларга
хөкем итте.
3 Аларның мәетләре күмелмичә
ятып калачак, алардан авыр
ис таралачак, түгелгән кан-
нарыннан таулар юпь-юеш
булачак.
4 Барлык күк җисемнәре янып
бетәчәк, күкләр кулъязма
төргәгедәй бөтерелеп килә-
чәк; бөтен күк җисемнәре,
йөзем куагының яфрак-
лары вә инҗир агачының
җимеше кебек, саргаеп ши-
ңәчәк.
5 Раббы болай ди: «Минем
кылычым күктә кан эчеп
туйды; менә ул, хөкем ясар
өчен, Эдомга – Мин тәмам
юк итәргә хәл кылган халык
өстенә төшә».
6 Раббының кылычы канга һәм
терлек маена – бәрән вә кәҗә
тәкәсе канына, сарык тәкә-
сенең бөер маена буялган,
чөнки Раббы Босрада корбан
китерә – эдомиләр җирендә
зур кырылыш бара.
7 Алар белән бергә кыргый үгез-
ләрнең яше дә, көчлесе дә
егылачак, җир аларның ка-
ны белән туеначак, майлары
туфракка сеңәчәк.



17 Тәхкыйк, Аллаһуга вә рә-
сүлгә итагать итүче тәкъва
мөэминнәр җәннәтләрдә һәм
нигъмәтләр эчендәдерләр.
18 Раббыларының биргән нигъ-
мәтләренә шатланган хәлдә,
Раббылары саклар аларны
җәһәннәм газабыннан.
19 Ашагыз вә эчегез тыныч вә
мәшәкатьсез генә тәкъвалык
белән кылган гамәлләрегез
өчен.
**81 сүрә**
1 Кайчан кояшның нуры китә-
релсә, чорналса...
2 Вә йолдызлар җиргә коелса-
лар...
3 Вә таулар урыннарыннан куз-
галсалар.
4 Вә ун айлык буаз дөяләр игъ-
тибарсыз калдырылсалар.
5 Вә кыр хайваннары бер урынга
җыелсалар.
6 Вә дәрьялар бер урынга тү-
гелсәләр.
7 Вә яхшы кешеләр яхшыларга
вә яман кешеләр яманнарга
кушылсалар.
8 Вә тере хәлдә күмелгән кыз
балалар соралсалар...
9 Ни сәбәпле үтерелдең дип,
нинди гөнаһы бар иде, нигә
үтердегез дип.
10 Вә гамәл дәфтәре хисап өчен
тартылса.
11 Вә күк урыныннан күчерелсә.
12 Вә җәһәннәм каты кызды-
рылса.
13 Вә җәннәт якын китерелсә.

8 Чөнки Раббының үч алу көне, Сионны рәнҗеткән өчен түләү елы җитте.

**Ишагыйя 13**

10 Күктәге йолдызлардан вә йолдызлыклардан якты төшмәс, чыккан чагында, кояш сүрән булыр, ай да үз яктысын бирмәс.

ТӘҮРАТ

14 Шул вакытта һәркем үзенең хәзерләгән яхшы вә яман эшләрен белер.

**99 сүрә**

1 Әгәр җир үзенең селкенүе илә селкендерелсә.

2 Вә җир үзенең эчендәге үлекләрне, йөкләрне, хәзинәләрне чыгарса.

3 Һәм кеше әйтсә: «Ни булды бу җиргә», — дип.

4 Шул көндә җир үзенең өстендә эшләнгән эшләрдән хәбәр бирер.

5 Тәхкыйк, җирнең сөйләмәге Раббыңның аңа «сөйлә» дип әйтүе беләндер.

6 Ул көндә кешеләр, каберләреннән кубарылып, хисап җиренә гамәлләренә күрә төрле фиркаләргә бүленеп барырлар, дөньяда кылган гамәлләренең җәзасын күрмәк өчен.

7 Берәү тузан бөртеге хәтле генә яхшылык кылган булса, аның җәзасын күрер.

8 Вә берәү тузан бөртеге хәтле генә гөнаһ эшләсә, аның җәзасын күрер.

**101 сүрә**

1 Катылыгы вә куркынычы белән җирне вә күкләрне кагучы кыямәт көне!

2 Никадәр каты куркынычлыдыр ул, кыямәт көне!

3 Ул кыямәт көненең катылыгы вә куркынычы ни дәрәҗәдә икәнлеген сиңа кем белдерде?

КОРЪӘН





*Акыллылар һәм ахмаклар турында*

**Маттай 25**

1 «Күкләр Патшалыгы ул вакытта менә нәрсәгә охшар. Күз алдыгызга китерегез: ун кыз, кулларына яктырткычлар тотып, кияү каршыларга чыккан.

2 Бишесе — ахмак, калган бишесе исә акыллы булган.

3 Ахмаклары яктырткычларын алганнар, ә май алмаганнар.

ИНҖИЛ

4 Ул көндә кешеләр каты куркуларыннан тузылган чикерткәләр кебек тузылып таралып китәрләр һәм бер-берсен күрмәсләр.

5 Вә таулар буялган вә тетелгән йон кебек булырлар.

6 Берәүнең ягъни мөселманның үлчәүдә гөнаһына караганда сәвабы авырырак, күбрәк булса.

8 Вә бер мөселманның үлчәүдә сәвабына караганда гөнаһы авыр килсә, ягъни яхшылыгына караганда яманлыгы күбрәк булса.

9 Аның анасы — мәрхәмәтсез булган, Һавийә исемле җәһәннәм аңа урын булыр.

10 Ул Һавийәнең нәрсә икәнен сиңа нәрсә белдерде?

11 Ул Һавийә кыздырылган уттыр.

*Акыллылар һәм ахмаклар турында*

**57 сүрә**

12 Кыямәт көнендә мөэмин ирләрне вә мөэминә хатыннарны күрерсең, һидаять нурлары алларыннан вә уңнарыннан барыр. Фәрештәләр әйтер: «Бүген сөенеч сезләргә, сезгә асларыннан татлы елгалар ага торган бакчалар, ул бакчаларда сез мәңге калырсыз, нурга чорналып бакчаларда мәңге калу зур уңыштыр».

КОРЪӘН

4 Акыллылары исә яктырткыч-
лар белән бергә чүлмәкләрдә
май да алганнар.
5 Кияү тоткарланганлыктан,
кызлар йокымсырый башла-
ган һәм йоклап та киткәннәр.
6 Төн уртасында: „Кияү килә,
аны каршыларга чыгыгыз!“ –
дип кычкырган тавыш ише-
телгән.
7 Шул вакытта бөтен кызлар
уянып китеп, яктырткыч-
лары яхшырак янсын өчен,
аларны рәтләгәннәр.
8 Ахмаклары акыллыларга:
„Безнең яктырткычлары-
быз сүнә, безгә бераз май
бирегезче“, – дип әйткән-
нәр.
9 Ә акыллылары: „Юк, безнең
май бөтенебезгә дә җитмәс.
Иң яхшысы, сатучыларга
барып, май сатып алыгыз“, –
дигәннәр.
10 Әмма алар сатып алырга дип
киткән арада, кияү килеп
җиткән. Кияүне каршылау
өчен, барын да әзерләп куй-
ган кызлар аның белән бергә
туй мәҗлесенә киткәннәр,
һәм алар артыннан ишек
ябылган.
11 Аннан соң калган кызлар да
килгәннәр. „Әфәнде, безгә
ач әле!“ – дип әйткәннәр
алар.
12 Ләкин ул: „Хак сүз сезгә әй-
тәм: мин сезне белмим“, –
дип җавап кайтарган».



13 Кыямәт көндә монафикъ
ирләр вә монафика хатын-
нар мөэминнәргә әйтерләр:
«Безне көтегез, нурыгыздан
файдаланып артыгыздан ба-
рыйкчы», – дип. Аларга әй-
телер: «Артыгызда калган
дөньяга кайтыгыз вә нурны
анда эзләгез», – дип. Ул мо-
нафикъләр белән мөэминнәр
арасына бер ишекле дивар
корылыр, ул диварның эчен-
дә җәннәт вә тышында җә-
һәннәмдер.
14 Монафикъләр мөэминнәргә:
«Әллә дөньяда без сезнең
белән бергә түгел идекме,
ник хәзер бездән аерыла-
сыз», – дип кычкырырлар.
Мөэминнәр әйтерләр: «Дө-
рес, күренештә тыштан гына
безнең кебек булдыгыз, лә-
кин икейөзле булып үзегезне
имансызлыкка салдыгыз, вә
мөэминнәрнең сугышта һә-
лак булуларын көттегез, вә
Аллаһ, пәйгамбәр сүзләренә
шөбһә иттегез, вә сезне дө-
нья кирәкләре алдады, хәтта
Аллаһ әмере үлем килгәнче
алданып йөрдегез, һәм шай-
тан сезне Аллаһ исеме илә
алдады: Аллаһ гафу итүче,
дип, барча кабахәт эшләрне
кылдырды.
15 Инде кыямәт көнендә гөнаһ-
ларыгызны җуяр өчен сездән
фидия алынмас һәм кяфер-
ләрдән дә алынмас, сезнең





***Гайсәнең хачка кадаклануы
һәм үлеме***

**Лүк 23**
32 Үтерергә дип, җәза урыны-
на Гайсә белән бергә ике
җинаятьчене дә алып бар-
дылар.
33 «Баш сөяге» дип атал-
ган урынга җиткәч, Аны
да, теге җинаятьчеләрне
дә – берсен Аның уң, ә
икенчесен сул ягына хач-
ка кадакладылар. 34 Гайсә
шунда: «И-и Атам! Кичер
бу кешеләрне, чөнки нәрсә
эшләгәннәрен белмиләр», –
диде. Гаскәриләр, җирәбә
салып, Аның киемнәрен бү-
лештеләр.
35 Халык карап торды. Башлык-
лар исә, Гайсәне мыскыллап:
«Башкаларны коткарып йөр-
де бит! Әгәр Аллаһы тара-
фыннан сайланган Мәсих
булса, Үзен коткарсын!» –
дип көлделәр.
36 Гаскәриләр дә Аңа әче шәраб
тәкъдим итеп:
37 «Әгәр яһүдиләр Патшасы бул-
саң, Үзеңне коткар!» – дип
мыскылладылар.
38 Аның баш өстенә хачка «Бу –
яһүдиләр Патшасы» дигән
язу беркетелгән иде.



урыныгыз уттыр, ул сезнең
хуҗагыздыр, ничек теләсә
шулай яндырыр, вә ул ут
ни яман барачак урындыр».

***Гайсәнең Аллаһы хозурына
ашуы***

**4 сүрә**
155 Гаһедләрен бозулары, Алла-
һуның аятьләрен инкяр итү-
ләре, хаксыз пәйгамбәрләрне
үтерүләре һәм күңелләребез
пәрдәләнгән дип әйтүләре
сәбәпле аларга төрле газап-
лар бирдек. Көферлек кылу-
лары сәбәпле бәлки Аллаһ
аларның күңеленә мөһер
баскандыр, инде ул яһүдләр
иман китермәсләр, мәгәр бик
азлары иман китерер.
156 Аллаһ аларны ләгънәт кылды
хакны инкяр итүләре һәм
Мәрьямгә зур ялган яла як-
каннары өчен. Ягъни Мәрь-
ям Гайсә г-мне тудыргач
яһүдләр: «Мәрьям зинадан
бала тудырды», – дип ялган
хәбәр тараттылар.
157 Янә аларны Аллаһ ләгънәт
кылды: «Без, әлбәттә, Аллаһ
рәсүле Мәрьям угълы Гайсә-
не үтердек», – дигән сүзләре
өчен. Алар Гайсәне үтермә-
деләр һәм асмадылар, ләкин
аларның бер юлдашы аларга
Гайсә сурәтендә күренде...
Яһүдләр, әлбәттә, Гайсә ха-
кында ихтыйлафта булды-
лар, әгәр Гайсәне үтергән

[39] Хачка асып куелган җинаятьчеләрнең берсе, Аны хурлап: «Син Мәсих түгелме соң? Шулай икән, Үзеңне дә, безне дә коткар!» – диде.
[40] Икенчесе исә: «Аллаһыдан курык! Син үзең дә – Аның кебек үк хөкемгә дучар ителгән кеше бит, – дип тегене тыйды. –
[41] Безне гадел хөкем иттеләр, кылган эшебез өчен тиешлесен алдык, ә Ул һичбер начарлык эшләмәгән, – диде.
[42] Аннары Гайсәгә мөрәҗәгать итеп: – Гайсә, Үз Патшалыгыңа килгәч, мине искә ал», – дип өстәде.
[43] Гайсә аңа: «Хак сүз әйтәм: син бүген үк Минем белән бергә җәннәттә булырсың», – дип җавап кайтарды.
[44-45] Көн урталары җиткән иде инде. Шулвакыт кояш сүнеп, бөтен җир йөзен караңгылык каплап алды, һәм шушы хәл көндезге өчкә кадәр дәвам итте. Аллаһы йортындагы пәрдә исә урталай ертылып төште.
[46] Гайсә шунда: «Атам! Рухымны Синең кулыңа тапшырам», – дип, каты итеп кычкырды һәм шул сүзләрдән соң җан бирде.
[47] Бу хәлләрне күреп торган йөзбашы, Аллаһыны данлап: «Чыннан да, бу Кеше гаепсез булган икән», – диде.



булсак, юлдашыбыз кайда? Аларның бу ихтыйлафлары, әлбәттә, занга ияргүләреннән булды, алар һичшиксез Гайсәне үтермәделәр.
[158] Бәлки Аллаһ аны үз хозурына күтәрде. Аллаһу Тәгалә һәр эштә галиб һәм хикмәт белән эшләүче булды.
[159] Китап әһелләре, әлбәттә, һәммәсе дә Гайсәгә ышанырлар үлүеннән әүвәл, вә Гайсә кыямәт көнне аларга шаһит булыр...

**5 сүрә**

[116] Янә Аллаһу Тәгалә кыямәт көнендә әйтер: «Ий Мәрьям угълы Гайсә! Син кешеләргә әйттеңме, мине һәм анамны Аллаһудан башка илаһ тотыгыз», – дип. Гайсә әйтте: «Ий Раббым! Син һәрбер кимчелектән пакьсең, Синең хакта миңа муафыйк түгел сүзне әйтмәк лаек түгелдер, әгәр андый сүзләрне әйткән булсам, әлбәттә, Син аны беләсең. Йа Раббы, Син минем күңелемдә булган нәрсәне, әлбәттә, беләсең, әмма мин Синдә булган нәрсәне белмимен. Әлбәттә, Син яшерен нәрсәләрне бик яхшы белүчесең».
[117] Янә Гайсә: «Ий Раббым! Мин аларга Син әмер иткәннән башканы әйтмәдем, бәлки „Мине вә сезне тәрбия итүче Аллаһуга гына гыйбадәт







[48] Тамаша кылырга җыелган халык та шушы вакыйганы күргәннән соң күкрәгенә суга-суга өенә таралды.
[49] Гайсәнең бар дуслары, шулай ук Гәлиләядән Аңа ияреп килгән хатыннар да бу хәлне читтән карап тордылар.



кылыгыз“, – дидем. Дәхи мин алар арасында булганда бөтен эшләренә шаһит булдым, мине күккә күтәреп үтергән чагында Син аларны күзәттең. Бит Син һәрнәрсәгә шаһитсең», – диде.

## Дога кылу һәм иманны икърар итү

**Маттай 6**

9 «Ә сез болай дога кылыгыз: Күктәге Атабыз! Исемең изге дип икърар ителсен,

10 Синең Патшалыгың килсен. Күктәге кебек җирдә дә Синең ихтыярың гамәлгә ашсын.

11 Көндәлек икмәгебезне безгә бүген бир.

12 Без дә үзебезгә явызлык кылучыларны кичергәндәй, безнең явыз эшләрне Син кичер.

13 Безне сынауга дучар итмә, ә явыздан сакла».

**Гыйбриләргә хат 4**

14 Күкләр аша узган бөек Олуг Руханиебыз – Аллаһы Углы Гайсә бар, шуңа күрә үзебез тоткан иманга тугры булып калыйк.

15 Олуг Руханиебыз җитешмәгән якларыбызны аңламаучы, безгә теләктәшлек итә белмәүче Зат түгел, чөнки Ул безнең кебек үк һәр яклап сыналды, тик һич кенә дә гөнаһ кылмады.

16 Шулай итеп, ярдәм кирәк булганда шәфкать алу һәм мәрхәмәт табу өчен, кыю рәвештә мәрхәмәт тәхете янына барыйк.

**II Көринтлеләргә хат 5**

10 Тәндә яшәгәндә кылган яхшы яки яман эшләренә карап



## Дога кылу һәм иманны икърар итү

**1 сүрә**

1 Рәхимле, шәфкатьле Аллаһ исеме белән башлыйм эшемне.

2 Чын мактау галәмнәрне, бөтен мәхлукларны тәрбияләүче Аллаһу Тәгаләгә тиешле.

3 Аллаһу Тәгалә бу дөньяда барча кешеләргә мәрхәмәтле, ягъни мөэминнәргә дә, кяферләргә дә нигъмәтләрен бирә, әмма ахирәттә мөэмин бәндәләренә генә бирәчәк.

4 Аллаһу Тәгалә гаделлек белән хөкем итүче, кыямәт көненең патшасыдыр.

5 Ий тәрбиячебез Аллаһ! Без Сиңа гына гыйбадәт кылабыз һәм һәр эшебездә Синнән генә ярдәм сорыйбыз.

6 Ий тәрбиячебез Аллаһ! Безне туры юлга күндер!..

7 Ул юлны Син әүвәлгеләргә ингам итеп бирдең, безне Синең ачуың төшкән вә адашкан кешеләрнең бидгать һәм зәлаләт юлыннан башка юлга күндер, ягъни Сине ачуландырмаган һәм хак юлдан адашмаган кешеләр юлына күндер! Амин.

**112 сүрә**

1 Әйт, әй Мөхәммәт: «Ул – Аллаһ – һич тиндәше вә охшашы булмаган ялгыз бер генә Аллаһудыр.



һәркемгә кылганнары буенча бирелсен өчен, безнең барыбызга да Мәсихнең хөкем итү урыны алдына килергә туры киләчәк.

**I Яхъядан хат 2**

1 Балаларым! Боларны сезгә, гөнаһ кылмагыз, дип язам. Ә инде берәү гөнаһ кылса, Атабыз алдында Яклаучыбыз – һәрвакыт гадел гамәл кылучы Гайсә Мәсих бар.

2 Ул гөнаһларыбызның, безнең генә түгел, бәлки бөтен дөньяның да гөнаһлары кичерелүен алып килүче корбан булды.

**Көлессәйлеләргә хат 1**

15 Мәсих – күзгә күренмәс Аллаһының чагылышы, Ул – беренче Угыл, яратылганнарның барысыннан да әүвәлрәк,

16 чөнки күктә һәм җирдә булган, күренгән һәм күренмәгәннәрнең һәммәсе Аның аркылы яратылган: җитәкче көчләрме, өстен көчләрме, башлыкларны, хакимлекләрме – барысы Аның аша һәм Аның өчен яратылган.

17 Ул һәрнәрсәдән элек булган, һәм Аның аркасында бар нәрсә бергә тора.

18 Ул – тәннең Башы, ә тән – Аңа иман итүчеләр бердәмлеге. Һәрнәрсәдә беренче булсын өчен, Ул – Башлангыч,



2 Һичнәрсәгә, һичбер мәхлукка ихтыяҗы юк, бәлки һәр мәхлукның хаҗәтен үтәүче Аллаһудыр.

3 Ул һичкемне тудырмады һәм һичкемнән тудырылмады.

4 Вә һичкем Аңа тиң булмады.

**57 сүрә**

1 Җирдәге вә күкләрдәге барча мәхлук «һәр кимчелектән пакь» дип Аллаһуны мактап зекер итәләр. Ул – Аллаһ, һәр эштә өстен вә белеп эшләүчедер.

2 Җирдә вә күкләрдә булган һәр нәрсәгә патша булу Аллаһуга хастыр, тергезә вә үтерәдер, вә Ул – Аллаһ, һәр нәрсәгә кадирдер.

3 Ул – Аллаһ – һәр нәрсәдән элек бардыр вә һәр нәрсәдән соң да бардыр, Ул бакыйдыр, Аның бетү ихтималы юктыр, барча галәмне төзүе белән Аның барлыгы ачыктыр вә Аның сыйфаты яшерендер, Аның сыйфатын һичкем белә алмас. Вә Ул һәр нәрсәне белүчедер.

4 Ул – Аллаһ, җирне вә күкләрне алты көн эчендә төзеде, соңра гарешне касд кылып аңа бәйләнеше булган эшне йөртте, Ул беләдер җиргә кергән нәрсәне вә җирдән чыккан нәрсәне, дәхи күктән ингән нәрсәне һәм күккә ашкан нәрсәне беләдер вә Ул кайда гына

үледән тереләселәр арасыннан иң беренче булып терелгән.
19 Аллаһы бөтен тулылыкның Аңарда яшәвен,
20 һәм Аның аркылы, Аның хачта түгелгән каны белән тынычлык урнаштырып, җирдәге, күктәге һәр нәрсәне Үзе белән татуландыруны мәгъкуль күрде.

ИНҖИЛ

булсагыз да сезнең белән бергәдер. Ул — Аллаһ, сезнең эшләгән эшләрегезне күрүчедер.
5 Җиргә вә күкләргә хуҗа булу Аллаһуга хастыр, вә һәр эш Аллаһуга кайтарыладыр.
6 Кичне көндезгә кертер вә көндезне кичкә кертер, вә Ул — Аллаһ — күкрәктәге яшерен уйларны белүчедер.
7 Ий кешеләр, Аллаһуга вә Аның рәсүленә иман китерегез вә малларыгыздан Аллаһ күрсәткән урыннарга садака бирегез, ул маллар сезгә ата-бабаларыгыздан калды! Сезләрдән иман китереп дин тоткан хәлдә садака бирүчеләр — аларгадыр олугъ әҗерләр.
8 Ий кешеләр, ни булды сезгә: Аллаһуга иман китермәссез вә Аңа итагать итмәссез, бит пәйгамбәр сезне Раббыгызга иман китерергә чакырадыр вә ул сездән Аллаһуга иман китереп Аңа итагать итәрсез дип гаһед алды, әгәр Аллаһуга, Коръәнгә вә пәйгамбәргә ышанган булсагыз?

**19 сүрә**

30 Гайсә аларның сүзләрен ишеткәч әйтте: «Мин Аллаһу Тәгаләнең колымын, Ул миңа китап бирде һәм мине пәйгамбәр итте».

КОРЪӘН





31 Кайда гына булса да кешеләр өчен мине мөбарәк-файдалы итте вә миңа намаз укырга әмер итте һәм зәкят бирергә әмер итте терек булган вакытымда.

КОРЪӘН

## Боерыклар, азатлык һәм җаваплылык

**Римлыларга хат 7**
14 Без Канунның рухи икәнен
беләбез. Мин исә дөньяви,
гөнаһка кол итеп сатылган-
мын.
15 Нәрсә эшләвемне дә аңла-
мыйм: теләгәнемне түгел,
нәфрәт иткәнемне эшлим.
16 Ә инде үзем теләмәгәнне эш-
лим икән, Канунның яхшы
булуы белән килешәм.
17 Шулай булгач, инде моны үзем
түгел, миндә яши торган гө-
наһ эшли.
18 Мин бит беләм: миндә,
ягъни гөнаһлы табигатем-
дә, һичнинди яхшы нәрсә
юк, хәер, миндә яхшы-
лык кылу теләге бар, әм-
ма аны тормышка ашыра
алмыйм.
19 Эшләргә теләгән яхшылыкны
түгел, теләмәгән явызлыкны
эшлим мин.
20 Димәк, теләмәгән нәрсәне
эшлим икән, инде аны мин
түгел, миндә яши торган гө-
наһ эшли.
21 Моннан шундый кагыйдә
килеп чыга: мин яхшылык
эшләргә телим, ләкин явыз-
лыктан арына алмыйм.
**Римлыларга хат 9**
15 Ул Мусага болай дип әйтә:
«Кемгә теләсәм, шуңа шәф-
кать күрсәтермен; кемне



## Боерыклар, азатлык һәм җаваплылык

**2 сүрә**
15 Аллаһ аларны үзләрен каты
мәсхәрә кылыр һәм аларны
алдашу юлында калдырыр,
хак юлны таба алмыйча хәй-
ран булып йөрерләр.
**2 сүрә**
253 ...Аллаһ Үзе теләгән эшне
кыладыр. <...>
255 ...кешеләр Аллаһ белемен-
нән һичнәрсәне чолгап ала
алмаслар, мәгәр Аллаһ бел-
дергәнне генә белерләр...
**6 сүрә**
25 Алардан кайберләре синең
сүзеңне тыңларлар, ләкин
сүзнең төп мәгънәсенә тө-
шенмәсләр, шул сәбәпле
Аллаһ хөкемнәрен кабул
итмәсләр. Соңра күңеллә-
ренә аңламаулык пәрдәсен
кордык, хак сүзне ишетмәс-
ләр. Әгәр алар Аллаһының
могҗизаларын күрсәләр,
берсенә дә ышанмыйлар,
бу Коръән әүвәлгеләрдән
калган хикәяләрдән башка
нәрсә түгел, диюче кяфер-
ләр хәтта яныңа килсәләр
хакны инкяр итеп, ялганны
яклап синең белән бәхәслә-
шәләр.
**17 сүрә**
46 Үзләре шуны ихтыяр иткән-
нәре өчен Коръәнне аңла-
масыннар өчен күңелләрен





кызганырга теләсәм, шуны
кызганырмын».
16 Шуңа күрә кешенең теләге йә
тырышлыгы түгел, ә Алла-
һының шәфкатьлеге мәгъ-
нәгә ия. <...>
18 Димәк, Аллаһы теләгән ке-
шеләренә шәфкать күрсә-
тә һәм теләгән кешеләрен
үҗәтләндерә.
**Марк 10**
18 «Нигә син Мине игелекле дип
атыйсың? — диде Гайсә. —
Аллаһыдан башка һичкем
игелекле түгел.
19 Аның әмерләрен син беләсең:
кеше үтермә, зина кылма,
урлашма, ялган шаһитлык
бирмә, алдашма, атаң белән
анаңны хөрмәт ит».
20 «Остаз, мин боларның бары-
сын яшьтән үтәп киләм», —
дип җавап бирде тегесе.
21 Гайсә аңа карап куйды, һәм
әлеге кеше Аның күңеленә
хуш килде. Шуннан Гайсә
аңа: «Сиңа бер генә нәрсә
җитми: бар да, булган һәммә
нәрсәңне сатып, фәкыйрь-
ләргә өләш. Шулай эшләсәң,
күктәге хәзинәгә ия булыр-
сың. Аннары яныма кил һәм
Миңа ияр», — диде.
**Амос 9**
7 «Әй Исраил халкы! Минем
өчен хәбәшиләрдән сезнең
ни аермагыз бар?! Исраи-
лиләрне Мисыр җирен-
нән алып чыккан кебек,



пәрдәләдек вә колакларын
саңгырау кылдык...
**7 сүрә**
179 Тәхкыйк, кешеләрдән вә
җеннәрдән күпләрне җәһән-
нәм өчен бар иттек, аларның
акыллары бар, ләкин хакны
аңламыйлар, аларның күзлә-
ре бар, ләкин гыйбрәтләрне
күрмиләр, аларның колакла-
ры бар, ләкин Аллаһ сүзлә-
рен ишетмиләр, алар хайван
кебекләр, бәлки хайваннарга
караганда да файда белән
зарарны аера алмауда гакыл-
сызраклар... Алар камил га-
филләр, үз киләчәкләрен һич
тә уйлап карамыйлар.
**28 сүрә**
56 Ий Мөхәммәт г-м, син сөйгән
кешеңне һидаятькә күндерә
алмассың, ләкин Аллаһ те-
ләгән бәндәсен туры юлга
күндерер, вә Ул туры юлга
күнүчеләрне белүчерәктер.
**39 сүрә**
23 Аллаһ сүзләрнең күркәмрәген
индерде, ул сүзләр аятьләре
бер-берсенә охшаган китап-
тыр, анда хөкеми аятьләр
икешәр мәртәбә зекер ител-
мештер, газапларны сөйлә-
гән аятьләрне укыганда Ал-
лаһудан курыккан кешеләр-
нең тиреләре тетрәр, соңра
күңелләре вә тиреләре Аллаһ
зекере илә карарланыр. Ошбу
Коръән Аллаһ һидаятедер,
аның илә Үзе теләгән кешене

пелештиләрне — Кәфтурдан, арамиләрне Кыйрдан Мин алып чыкмадыммы?!» — ди Раббы.

**Канун 30**

16 «Бүген мин сезгә әйткәннәрне — Раббы Аллагыз кушканнарны үтәсәгез, Раббы Аллагызны яратсагыз, Аның юлыннан йөреп, әмерләрен, кагыйдәләрен вә кануннарын үтәсәгез, Раббы Аллагыз фатихасы белән үзегез билисе җирдә яшәрсез һәм күп санлы булырсыз.

17 Әгәр инде йөрәгегез белән Раббыдан читләшеп, аны тыңламасагыз, адашсагыз, башка илаһларга сәҗдә кылып, аларга табына башласагыз, —

18 мин сезне хәзер кисәтеп куям! — сез һәлак булырсыз, Үрдүн аръягында билисе җирегездә озак яши алмассыз».

**Амос 3**

6 «Шәһәрдә быргы кычкыртсалар, халыкны курку алмасмы?! Шәһәргә бәла килсә, Раббы кулы белән эшләнмиме бу?»

**Амос 4**

12 «Әнә шуның өчен Мин сине җәзага тартам, и Исраил! Сиңа шуны эшләргә җыенганга, Аллаңны каршыларга әзерлән, и Исраил!»

13 Менә Ул — тауларны хасил иткән, җилләрне бар кылган



туры юлга күндерер. Вә берәүне Аллаһ адаштырса, аңа туры юлны бирүче булмас.

**16 сүрә**

93 Әгәр Аллаһ теләгән булса иде, әлбәттә, барчагызны бер диндә кылыр иде, ләкин Аллаһ теләгән кешеләрен адаштыра вә теләгән кешеләрен туры юлга сала, кылган эшләрегездән, әлбәттә, соралырсыз, сакланып эш кылыгыз!

**49 сүрә**

17 Бәдәви гарәпләре мөселман булулары белән сиңа миннәт итәрләр, ягъни мөселман булуларын пәйгамбәр файдасына дип уйларлар, син аларга әйт: «Мөселман булуыгыз белән миңа миннәт итмәгез, бәлки Аллаһ сезгә миннәт итәр, сезне иманга күндергәне өчен, әгәр иманыгызда ышанычлы кешеләрдән булсагыз», — дип...

**10 сүрә**

100 Аллаһ теләгеннән башка иман китерергә һичкемгә мөмкин түгел. Хак белән батыйльне аеру өчен гакылын эшләтмәгән кешеләргә Аллаһ көфер-имансызлык ләззәтен салыр.

**28 сүрә**

68 Раббы теләгәнне вә ихтыяр иткән нәрсәне халык итәр, югыйсә мөшрикләр өчен





Зат! Кешегә Ул Үзенең уй-ниятен белдерә, таң яктысын караңгыга әйләндерә, тау башларыннан гизеп йөри. Аның исеме — Раббы, Күкләр Хуҗасы Алла!

**Амос 5**

6 Раббыга сыеныгыз — шул чагында яшәрсез! Юкса Йосыф йортына Ул ут кебек ябырылыр һәм аны ялмап алыр — Бәйт-Элдә янгын сүндерердәй кеше табылмас.

7 Әй сез, гаделлекне әче әремгә әйләндерүчеләр, хаклыкны җиргә салып таптаучылар — кайгы сезгә!

**Римлыларга хат 11**

32 Үзенең шәфкатьлелеген күрсәтер өчен, Аллаһы кешеләрнең һәммәсен дә буйсынмаучылык тоткыны итте.

**I Көринтлеләргә хат 10**

13 Сез гадәти, кешеләргә хас сынауга дучар булдыгыз. Аллаһы ышанычлы, Ул сез чыдый алмаслык сынауга юл куймас. Сыналганда түзеп тору өчен, сезгә котылу юлын да күрсәтәчәк.

**Ягъкубтан хат 1**

13 Коткыга төшкәннәрнең берсе дә: «Бу коткы Аллаһы тарафыннан җибәрелгән», — дип әйтергә тиеш түгел, чөнки явызлык Аллаһыны вәсвәсәләндерә алмый һәм Аллаһы Үзе беркемне дә вәсвәсәләндерми.



бернәрсәне ихтыяр итмәк юктыр, Аллаһу Тәгалә пакь һәм бөек булды мөшрикләр Аллаһуга шәрик иткән нәрсәләрдән.

69 Раббың аларның күңелләрендә яшергән имансызлык һәм башка бозык уйларын һәм телләре белән изһар иткән нәрсәләрен дә беләдер.

70 Вә Ул — Аллаһ, юктыр Аңардан башка илаһ, мәгәр Ул Үзе генәдер, дөньяда вә ахирәттә мактау Аңа хастыр, вә һәр эштә булган хөкем янә Аллаһуга хастыр һәм ахырда Аңа кайтарылмыш булырсыз.

**10 сүрә**

107 Әгәр Аллаһ сиңа бер зарарны бирсә, ул зарарны синнән алырга Аңардан башка зат юк, әгәр сиңа бер нигъмәт бирергә теләсә, Аның юмартлыгыннан биреләчәк нигъмәтне кире алучы юк. Бәндәләреннән Үзе теләгәннәренә бирер ул нигъмәтне. Вә Ул ярлыкаучы вә рәхимле.

**76 сүрә**

29 Тәхкыйк, бу Коръән... кешеләргә кирәк нәрсәләрне сөйләп белдерүче көчле вәгазь, ачык дәлилләр. Теләгән кеше Коръән белән гамәл кылсын да үзенә Раббысының җәннәтләренә бара торган юлны алсын!

**Яхәзкыл 18**

20 «Гөнаһ кылган җан үләчәк; атасының гаебен углы үз өстенә, ә атасы углының гаебен үз өстенә алмаячак, тәкъва кешенең тәкъвалыгы үзе белән калачак, явыз кешенең явызлыгы да үз өстендә булачак.

21 Әгәр инде явыз кеше, барлык кылган гөнаһларын ташлап, Минем бөтен кагыйдәләремне сакласа һәм дөрес вә гадел гамәлләр кылса, һичшиксез яшәячәк, үлмәячәк».

**I Тессалуникәлеләргә хат 4**

3 Аллаһы сезнең изге булуыгызны, азгынлыктан тыелып торуыгызны тели.

**Ягъкубтан хат 2**

14 Әгәр кем дә булса: «Мин иман итәм», — дип әйтә, ә эштә күрсәтми икән, имандашларым, моннан ни файда? Андый иман аны коткара аламы? <...>

17 Иман да шулай. Гамәлсез иман үзе үк үле була. <...>

24 Күрәсез, кеше иман белән генә түгел, бәлки кылган гамәлләре белән Аллаһы тарафыннан аклана.

**Титуска хат 3**

8 Бу сүзләр хак. Синең бу нәрсәләр турында басым ясап әйтүеңне телим, Аллаһыга иман итүчеләр үзләрен яхшы эшләргә багышласын. Болар

**48 сүрә**

25 Аллаһ... Үзе теләгән кешеләрне рәхмәтенә вә Ислам диненә кертмәклеге өчен.

**18 сүрә**

58 Синең Раббың гөнаһларны ярлыкаучы, вә рәхмәт иясedер, әгәр эшләгән гөнаһлары өчен аларны газап белән тотарга теләсә иде, әлбәттә, дөньяда ук ашыктырып газап бирер иде. Бәлки аларны газап итәр өчен вәгъдә ителгән кыямәт көне бардыр, вә алар Аллаһудан башка качачак урын һич тә тапмаслар.

**2 сүрә**

286 Аллаһу Тәгалә һичкемгә көче җитмәгән эш белән көчләмәс, мәгәр көче җиткән эш белән көчләр. Берәү Аллаһуга буйсынып изге гамәлләр кылса, файдалы эшләрне генә эшләсә — файдасы үзенәдер, әгәр берәү Аллаһуга карышып гөнаһларны, явыз эшләрне кәсеп итсә — газабы үзенә. Аллаһуга итагать итүче мөэминнәр әйтәләр: «Ий Раббыбыз, лязим булган изге гамәлләрне онытып калдырсак, яки хаталанып гөнаһ эшләсәк, болар өчен безләрне газап белән тотма! Ий Раббыбыз! Әүвәлге өммәтләргә йөкләгән авыр йөкләрне безгә йөкләмә! Ий Раббыбыз! Көчебез җитмәслек, сабыр итә алмаслык









һәммәсе яхшы һәм кешеләр өчен файдалы.

**Эфеслеләргә хат 6**

8 Хакимебезнең һәркемгә — кол булса да, ирекле булса да — эшләгән игелеге өчен әҗер түләячәген беләсез.

**I Көринтлеләргә хат 15**

19 Мәсихкә бу тормышта гына өмет багласак, без — иң кызганыч кешеләр.

**Гәләтиялеләргә хат 6**

2 Бер-берегезнең авыр йөкләрен күтәрешегез, шулай итеп Мәсих канунын үтәрсез. <...>

5 Һәркем үз йөген үзе йөртергә тиеш бит.

авыр бәла-казаларны безгә йөкләмә! Безләрне гафу ит һәм ярлыка һәм дә безгә рәхәт кыл! Ий Раббыбыз, Син безнең хуҗа, барча хаҗәтләребезне Син генә үтисең, кяферләргә каршы торырга, аларны җиңәргә безгә ярдәм бир!»

**2 сүрә**

134 Зекер ителгән пәйгамбәрләр һәм аларның өммәтләре дөньядан үтеп киттеләр, кәсеп иткән сәваблары һәм гөнаһлары үзләренә. Сезнең дә кәсеп иткән сәвабларыгыз һәм гөнаһларыгыз үзегезгәдер. Аларның эшләгән эшләреннән соралмассыз. <...>

139 Ий сез, яһүдләр вә насаралар һәм бидгатьче мөселманнар! Аллаһ хөкемнәре хакында безнең белән тартышасызмы? Батыйль гамәлләрегезне, ялган дәлилләрегезне дөрес димәкче буласызмы? Бит Аллаһ сезнең дә, безнең дә Раббыбыз. Без Коръән белән гамәл кылсак, файдасы үзебезгә булыр. Сез Коръән белән гамәл кылмасагыз, зарары үзегезгә булыр. Без Аллаһуга гыйбадәт кылуда һәм Коръән белән гамәл кылуда ихласбыз.

**28 сүрә**

67 Әмма берәү исән һәм куәтле чагында ширектән һәм башка гөнаһлардан тәүбә

итсә һәм иман китереп изге гамәлләр кылса, әнә шул кешенең котылучылардан булып Аллаһуның рәхмәтенә ирешмәклеге якындыр.

**2 сүрә**

256 Диндә көчләү юк...

257 Аллаһу Тәгалә — хак мөэминнәрнең хуҗасы, аларны бидгать, хорафат караңгылыгыннан чыгарып...

**16 сүрә**

90 Тәхкыйк, Аллаһу Тәгалә һәр эштә гадел булырга һәм дин вә гадел мөселманнар файдасына яхшы эшләр кылырга вә якын кардәшләрнең хакын үтәргә боерадыр, вә Аллаһ сезне тыядыр фәхеш, хәрам эшләрдән вә шәригать белән сабит булмаган бидгать гамәлләрдән һәм зураеп хактан качудан, хаксыз золым итүдән. Аллаһ сезне вәгазьли, шаять, вәгазьләнерсез!

91 Әгәр Аллаһуга гаһед яки вәгъдә бирсәгез, әлбәттә, аны үтәгез! Аллаһ исеме белән әйткән антларыгызны бозмагыз! Тәхкыйк, сез Аллаһ исеме белән ант иткәндә Аллаһуны кәфил иткән буласыз. Әлбәттә, Аллаһ сезнең кылган эшләрегезне беләдер.

**6 сүрә**

158 ...Раббының бәгъзе галәмәтләре килгән көндә һичкемнең иман китерүе файда







бирмәс, ягъни үлем куркынычларын күргәч кенә яки картлык зәгыйфьлегенә ирешкәч кенә иман китереп маташуның һич файдасы булмас яки әүвәлрәк иман китергән, ләкин хәрамнардан тәүбә итмәгән һәм фарызларны үтәмәгән, коры иман сүзләрен әйтеп яшәү янә файда бирмәс...

**2 сүрә**

143 ...Шиксез, кыйбланы алыштыру иманы зәгыйфь кешеләргә авыр булды, хәтта кайберләре диннән чыгып кяфер булдылар... Аллаһ әйтте: «Аллаһ сезнең иманыгызны һәм сәвабыгызны югалтыр булмады». Дөреслектә, Аллаһ кешеләргә рәхмәт кылучы, аларны кызганучы.

**53 сүрә**

38 ...берәүнең сәвабы да, гөнаһы да икенче кешегә бирелмәс.

## Иблис – шайтан

**Әюб 1**

[12] Шунда Раббы болай диде: «Ярый, бүгеннән аның бар мөлкәте синең кулыңда, тик аның үзенә генә тимә». Шайтан аннары Раббы янынннан китеп барды.

**Зәкәрия 3**

[1] Аннары ул миңа Раббы фәрештәсе каршындагы баш рухани Ешуаны һәм, аны гаепләр өчен, аның уң ягында басып торган шайтанны күрсәтте.

[2] Раббы шайтанга әйтте: «Раббы гаепләүдән туктатыр сине, шайтан! Әйе, Иерусалимне сайлаган Раббы туктатыр сине!..»

**I Елъязма 21**

[1] Бервакыт шайтан, исраилиләргә каршы чыгып, Давытны Исраил халкының исәбен алырга котыртты.

**I Яхъядан хат 3**

[7] Балаларым, сезне һичкем алдамасын. Хак эш кылучы кеше Мәсих кебек үк хак була.

[8] Гөнаһ кылучы исә иблистәндер, чөнки иблис баштан ук гөнаһ кылып килде. Аллаһы Углы нәкъ менә иблис эшләрен җимерергә дип килде. <...>

[10] ...хаклык кылмаучы... Аллаһыдан түгел.



## Иблис – шайтан

**38 сүрә**

[71] Раббың фәрештәләргә әйтте: «Мин балчыктан Адәмне халык кылачакмын».

[72] Аны халык кылып тәмам иткәч, аңа җан кертеп тергездем, фәрештәләр Адәмне зурлап сәҗдәгә бардылар.

[73] Фәрештәләрнең барчасы берьюлы сәҗдә кылдылар.

[74] Мәгәр Иблис сәҗдә кылмады. Тәкәбберләнде һәм кяферләрдән булды.

[75] Аллаһу Тәгалә әйтте: «Ий Иблис, Мин Үз кодрәтем илә яраткан Адәмгә сәҗдә кылудан сине нәрсә тыйды? Тәкәбберләндеңме? Яки бөекләрдән булдыңмы?»

[76] Иблис әйтте: «Мин Адәмнән хәерлерәкмен, чөнки мине уттан яраттың, Адәмне исә балчыктан яраттың».

[77] Аллаһ әйтте: «Алай булса җәннәттән чык, тәхкыйк, син рәхмәтемнән сөрелмешсең.

[78] Әлбәттә, кыямәт көненә чаклы Минем синә ләгънәтемдер».

[79] Иблис әйтте: «Ий Раббым, кешеләрнең кубарылачак көннәренә чаклы мине дөньяда калдыр, үтермә».

[80] Аллаһ әйтте: «Әлбәттә, син дөньяда калучысың.







**Яхъя 12**

[31] «Бу дөнья хәзер хөкем ителә, хәзер бу дөньяның түрәсе куып чыгарылачак».

**Яхъя 14**

[30] «Сезнең белән күп сөйләшмәм инде, чөнки бу дөньяның түрәсе килә. Минем өстән аның һичнинди хакимлеге юк».

**Эфеслеләргә хат 2**

[1] Сез яман эшләрегез һәм гөнаһларыгыз аркасында үле идегез.

[2] Сез элек бу дөньядагы явыз гадәтләргә, һава киңлекләрендәге рухи көчләр белән идарә итүче рухка буйсынып яшәдегез. Ул рух Аллаһыга буйсынмаучы кешеләрдә хәзер дә гамәлдә.

**Ягъкубтан хат 4**

[7] Шулай икән, үзегезне Аллаһыга буйсындырыгыз. Иблискә каршылык күрсәтегез, һәм ул сездән качар.

[8] Аллаһыга якынлашыгыз, шунда Ул да сезгә якынаер. Әй гөнаһлылар, кулларыгызны чистартыгыз! Әй икеләнүчеләр, йөрәкләрегезне пакьләндерегез!

**Зәбур 129**

[3] Әгәр гөнаһ эшләрне теркәп барсаң, кем аяк өсте кала алыр икән, и Хуҗа-Раббым?!

[4] Син безне ярлыкыйсың, Син – дәһшәт ияседер!



[81] Аллаһ хозурында мәгълүм булган көнгә чаклы, ягъни дөнья беткәнче».

[82] Иблис әйтте: «Ий Раббым, гыйззәтең хакы өчен әйтәмен, кешеләрне һәммәсен аздырачакмын.

[83] Мәгәр ихлас булган мөэмин бәндәләреңне аздырырга көчем җитмәс».

[84] Аллаһ әйтте: «Хакны „хак“ дип әйтермен.

[85] Җәһәннәмне синең илә вә синә ияргән кешеләрнең һәммәсе илә тутырачакмын».

**41 сүрә**

[36] Әгәр явызлык итүчегә изгелек итәргә шайтан сиңа ирек бирмәсә, шайтанның шәреннән Аллаһуга сыгын, Ул сине шайтан вәсвәсәсеннән саклар, аннары явызлыкка каршы изгелек итә алырсың. Бит Ул – Аллаһ, ишетүче вә белүчедер.

## Күтәрүче һәм түбән төшерүче – Аллаһы

**I Патшалар 2**

3 «Һавалы әңгәмәләр куертма-
гыз, дорфа сүзләрегез эче-
гездә калсын, чөнки Раббы
бар нәрсәдән дә хәбәрдар
Аллаһы, Ул барлык эш-га-
мәлләрне үлчәүгә сала.
4 Баһадирның угы сына, ә бете-
решкән бер адәмнән гайрәт
ташый.
5 Берәү әүвәл тук булса да, бү-
ген әнә икмәк хакына маң-
гай тире түгә, ә тамагы ач
булганы сый-хөрмәттә йөзә.
Карыны кысыр җиде тапкыр
бала тапты, күп балалы әнә
япа-ялгыз бүген!
6 Раббы – гомер кисүче дә, тор-
мыш бүләк итүче дә. Үлеләр
аймагына озатучы – Ул, кү-
тәреп торгызучы да – Ул.
7 Хәерче дә ясый Ул бездән,
байлыкка да күмә, түбән дә
төшерә, югары да чөя.
8 Мескен бәндәне Ул – тузан
арасыннан, фәкыйрь-юксыл-
ны көл-туфрактан күтәреп
торгыза. Түрәләр арасына
утыртып, мирас итеп данлы
урын бирә аларга. Җирнең
нигезе Раббыныкыдыр, дө-
ньяны Ул шул нигезгә ур-
наштырган.
9 Үзенә тугрыларның һәр ады-
мын Ул дөрес юлда тота,
явызларны исә караңгылык



## Күтәрүче һәм түбән төшерүче – Аллаһы

**35 сүрә**

44 Әллә алар гыйбрәт күзе бе-
лән карап җир өстендә
йөремиләрме, үзләреннән
әүвәлге кяферләрнең ахыр
хәлләренә карамыйлармы –
ничек һәлак булганнар, ул
һәлак булган кешеләр куәт-
тә болардан артык иделәр.
Җирдә вә күкләрдә Аллаһу-
ны һичбер зат, һичбер нәр-
сә гаҗиз, көчсез итә алачак
түгел. Аллаһ барча нәрсәне
белүче вә һәр нәрсәгә көче
җитүче.
45 Әгәр Аллаһ кешеләрне Аллаһ
хөкемнәрен бозып бозыклык
кылганнары өчен дөньяда
газап кыла торган булса, әл-
бәттә, һәммәсен һәлак итәр
иде, җир өстендә хәрәкәт-
ләнә торган бер хайван да
калмас иде. Ләкин газапка
тиешлеләрнең газабын кы-
ямәт көненә чаклы кичекте-
рә, кешеләрнең билгеләнгән
әҗәлләре килсә яки кыямәт
килсә, Аллаһ бәндәләрен
күрүче вә аларның эшен бе-
лүче булды.

**41 сүрә**

43 ...синең Раббың мөэминнәрне
ярлыкаучы вә кяферләрдән
каты рәнҗетүче газап илә
үч алу иясе.



йотачак. Чөнки адәмдәге
ныклык аның көч-гайрә-
тендә түгел.
10 Үз дошманнарын Раббы
тар-мар итә, аларга күкләр
күкрәтеп ябырыла. Раббы
бөтен дөньяны хөкем итәчәк.
Үзе куйган патшага ныклык
бирүче Ул, Үзе ихтыяр кыл-
ган патшага кодрәт бирүче».

**Лүк 1**

52 «Түрәләрне тәхетләреннән
төшерде, ә түбәндәгеләрне
күтәрде».



**31 сүрә**

33 Ий кешеләр, Раббыгыздан
куркыгыз, Аңа гөнаһ булу-
дан сакланыгыз вә кыямәт
көненнән куркыгыз, ул көн-
дә ата үз угълының гөнаһын
өстенә алмас, һәм баласы
атасының гөнаһысыннан аз
гынасын да өстенә алмас.
Аллаһуның вәгъдәсе хактыр,
сезне дөнья рәхәте алдап
ахирәттән мәхрүм итмәсен,
һәм сезне шайтан фәхеш,
хәрам эшләрне вә бидгать
гамәлләрне эшләтеп, фарыз
гамәлләрдән тыеп, «Аллаһ
ярлыкаучы» дип Аллаһ исеме
белән алдамасын!
34 Әлбәттә, кыямәтнең кайчан
булачагын белү Аллаһ хозу-
рындадыр...

**3 сүрә**

97 ...Берәү хаҗның фарызлыгын
инкяр итсә, көче җитеп тә
хаҗ кылмаса, зарары үзе-
нә. Аллаһ бөтен галәмнәр
мәхлугыннан мөстәгънидер,
һичберсенең гамәленә мох-
таҗ түгел...

**53 сүрә**

43 Тәхкыйк, Ул – Аллаһ, кеше-
ләрне көлдерде һәм елатты.
44 Һәм Ул – Аллаһ, үтерде вә
терелтте.

**3 сүрә**

26 Ий Аллаһ, Син – барча
байлыкка патшасың, Үзең
теләгән кешегә байлыкны
бирәсең һәм Үзең теләгән

кешедән байлыкны аласың, теләгән бәндәңне... хөрмәтле итәсең һәм теләгән бәндәңне... хур итәсең. Барча хәйрият Синең кулыңдадыр, шиксез, Синең һәр нәрсәгә көчең җитә...

27 Ий Аллаһ! Син... үлекне терекләрдән чыгарасың һәм терекне үлектән чыгарасың, һәм дә теләгән бәндәләреңә хисапсыз ризык бирәсең.

КОРЪӘН



## Аллаһыдан иңгән сүз һәм Изге Язмалар

**Ишагыйя 55**

10 «Күктән яуган яңгыр яки кар кире күккә кайтмаган, бәлки, сугарып, җирне уңдырышлы иткән, чәчкән кешегә – орлык, ашаган кешегә икмәк биргән кебек,

11 Минем авызымнан чыккан сүз дә Миңа файдасыз булып кире кайтмый, ә бәлки Мин теләгәнне башкара: Мин аны нинди йомыш белән җибәргән булсам, шул эшне үтәп чыга».

**Иремия 1**

9 Шуннан соң Раббы, кулын сузып, иренемә тидерде дә: «Менә, сүзләремне Мин синең телеңә салдым, – диде. –

10 Кара, бүгеннән Мин сине халыклар вә патшалыклардан өстен куям: берәүләрен син тамырлары белән йолкырсың, бөлгенлеккә төшерерсең, юкка чыгарырсың һәм җимерерсең, икенчеләрен ныгытырсың һәм төпләндерерсең».

**III Патшалар 22**

21 «Шунда бер рух, алга чыгып, Раббы каршына килде дә: „Мин күндерә алам“, – диде. „Ничек итеп?“ – дип сорады аңардан Раббы.

22 „Мин барам да аның пәйгамбәрләре теленә ялган

ТӘҮРАТ

## Аллаһыдан иңгән сүз һәм Изге Язмалар

**31 сүрә**

27 Әгәр җир йөзендәге агачлар каләмнәр булсалар иде, дәхи бер диңгезгә җиде диңгез кушылып яза торган кара ясалса, шул кара белән Аллаһуның сүзләре язылса, яза-яза кара бетәр иде, әмма Аллаһуның сүзләре бетмәс иде, Аллаһ көчле вә хөкемчедер.

**43 сүрә**

2 Барча хәлне ачык бәян итүче Коръән белән ант итеп әйтәмен!

3 Без бу Коръәнне гарәп телендә кылдык – шаять, ий кешеләр, аңлап иман китерерсез!

4 Тәхкыйк, ул Коръән ләүхелмәхфузда китаплар анасында сабиттер, сакланадыр Безнең хозурыбызда, ул гаять бөектер һәм гадел хөкем итүчедер.

5 Ий мөшрикләр, сез чиктән үткән фасикъ кавем булганыгыз өчен сезгә Коръән индерүдән вә сезне хәрам фәхеш эшләрдән тыюдан һәм фарыз эшләргә өндәүдән туктап калырбызмы?..

**6 сүрә**

92 Бу Коръән – Без индергән мөбарәк китап. Ул Коръән үзеннән элек иңгән китапларны дөресләүче (раслаучы)...

93 Аллаһуга ялган сүзне ифтира итүчедән дә залимрәк кеше

КОРЪӘН

сүз салучы бер рухка әйләнәм“, – диде теге рух. Раббы аңа: „Син аны күндерерсең һәм бу эшне башкарып чыгарсың. Бар, шулай эшлә“, – диде.
23 Шулай итеп, Раббы әлеге ялганчы рухның сүзләрен шушындагы бөтен пәйгамбәрләреңнең теленә салды; Раббы сине һәлакәткә дучар итте»...

**Зәбур 1**

1 Бәхетледер кеше, яманнар үгете белән йөрмәсә, гөнаһлылар юлына басмаса, мыскыллап көлүчеләр арасында утырмаса!
2 Раббы канунында булыр аның ирке, көне-төне өйрәнер шул Канунны.
3 Агымсу ярында үскән агач кебек ул: җимешен үз вакытында бирер, яфраклары шиңмәс-корымас; һәр эшендә уңышка ирешер ул.

**Канун 4**

2 «Мин әйткән сүзләргә берни өстәмәгез дә, аларны киметмәгез дә. Раббы Аллагызның сезгә минем аша ирештергән әмерләрен үтәгез».

**IV Патшалар 23**

3 Багана янында басып торган патша: «Әлеге китапта язылган Килешүнең сүзләрен үтәр өчен, мин Раббы юлыннан йөрермен, бар йөрәгем вә җаным белән Аның



бармы? Яки ул залим: «Миңа вәхи килде», – дип ялганлар, хәлбуки аңа һичнинди вәхи килгәне юк; яки, Аллаһ индергән аятьләрне мин дә индерә алам, дияр. Әгәр залимнәрнең үлгән вакытларын күрсәң, бик авыр хәлдә, каты газап астында булырлар. Фәрештәләр аларга: «Җаннарыгызны чыгарыгыз», – дип, кулларын сузып каты сугарлар. Бүген хур итүче газап белән җәза ителәсез, Аллаһуга тиешсез сүзләр әйткәнегез һәм Аның аятьләре белән гамәл кылудан тәкәбберләнгәнегез өчен. <...>
155 Без индергән бу Коръән аның белән гамәл кылучыга мөбарәк, шулай булгач, аның һәр хөкеменә иярегез, әмма башка юлга китеп адашудан сакланыгыз, шаять, рәхмәт ителерсез.

**16 сүрә**

101 Әгәр Без бер аятьнең хөкемен бетереп, аны икенче аять белән алыштырсак, Аллаһ белүчерәктер нинди аять индерергә, шулай итеп, Аллаһ бер аятьне алыштырса, мөшрикләр Мөхәммәт г-мгә, син Аллаһуга ифтира кылучысың, диләр, бәлки аларның күбрәге аятьнең алышуының хикмәтен белмиләр.





АЛЛАҺЫДАН ИҢГӘН СҮЗ ҺӘМ ИЗГЕ ЯЗМАЛАР

боерыкларына, күрсәтмәләренә һәм кагыйдәләренә буйсынырмын», – дип, Раббы белән Килешүне раслады. Бар халык әлеге Килешүгә кушылды.

**Маттай 5**

17 «Минем хакта, Муса канунын яки пәйгамбәрләр язганнарны юкка чыгарырга килгән, дип уйламагыз. Мин юкка чыгарырга дип түгел, башкарырга дип килдем!
18 Сезгә хак сүз әйтәм: җир һәм күк юкка чыкканчы, Канунның бер генә сызыгы да юкка чыкмаячак – барысы да тормышка ашырылачак!»

**Лүк 16**

16 «Муса кануны чоры һәм пәйгамбәрләр заманы Чумдыручы Яхъя килгәнче дәвам итте. Хәзер исә Аллаһы Патшалыгы хакында Яхшы хәбәр вәгазь кылына, һәм һәркем шунда омтыла, шунда аяк басарга тырыша.
17 Әмма күк һәм җир юкка чыкканда да, Канунның бер генә сызыгы да юкка чыкмаячак».

**Яхъя 10**

34 Ә Гайсә болай дип әйтте: «Аллаһының „Сез – илаһлар, дидем Мин“ дигән сүзләре сезнең Кануныгызда язылган түгелме?
35 Аллаһы Үзенең сүзе бирелгән кешеләрне илаһлар дип



102 Әйт: «Алышынган аятьне Җәбраил г-м Аллаһудан хаклык белән индерде, мөэминнәрнең күңелен хаклыкка беркетер өчен вә аларга һидаять һәм сөенеч булсын өчен».

**4 сүрә**

82 Ни өчен күп кешеләр Коръәннең мәгънәсен фикерләп, уйлап карамыйлар? Чын күңелдән фикерләп укысалар, әлбәттә, Коръәннең Аллаһ сүзләре икәнлеген белер иделәр. Әгәр бу Коръән Аллаһудан башка бер кешенең сүзләре булса иде, әлбәттә, кешеләр ул Коръәндә бер-берсенә каршы булган сүзләрне күп табар иде.

**2 сүрә**

106 Әгәр кайбер аятьләрнең хөкемнәрен үзгәртсәк яки оныттырсак, ул аятьләргә охшашлы аятьләрне яки яхшыракны бирербез. Әллә белмисеңме Аллаһуның һәр нәрсәгә көче җиткәнен?

**32 сүрә**

2 Коръән Кәримнең барча галәмне тәрбия итүче Аллаһудан индерелгәнлегенә шик юктыр.
3 Югыйсә Мөхәммәт г-м аны үзеннән чыгарып Аллаһуга ифтира итте диярләрме; бәлки аның Раббыңнан булуы хактыр, синнән элек аларга

атады, ә Изге язма юкка чыгарыла алмый.

36 Мине Ата Үзе, изге эшкә аерып, дөньяга җибәрде. Ничек соң сез „Мин – Аллаһы Углы“ дигәнемә: „Көфер сөйлисең“, – дип әйтәсез?»

**Канун 18**

20 «„Ләкин Мин сөйләргә кушмаганны Минем исемнән сөйләргә батырчылык иткән яки башка илаһлар исеменнән сөйләгән пәйгамбәр үләргә тиеш“.

21 Бәлки, күңелегездән: „Моның Раббы тарафыннан әйтелмәвен без ничек белербез икән?“ – дип уйлыйсыздыр.

22 Әгәр пәйгамбәр: „Раббы исеменнән сөйлим“, – дип әйтеп, ул әйткәннәр чынга ашмаса, димәк, бу сүз Раббыныкы түгел, ә пәйгамбәр үз белдеге белән сөйләгән була – курыкмагыз аңардан».

**Иремия 28**

8 «...миннән һәм синнән элгәрәк килгән пәйгамбәрләр борын заманнардан бирле байтак илләрне вә бөек патшалыкларны сугышлар, афәтләр һәм үләт зәхмәтләре турында алдан кисәтә торан булганнар.

9 Әмма иминлек-тынычлык киләсен алдан хәбәр иткән пәйгамбәрнең әйткәннәре тормышка ашканнан соң

куркытучы пәйгамбәр килмәгән кавемне Аллаһ газабы белән куркытмаклыгың өчен сиңа Коръән индерелде, шаять Коръән белән вәгазьләнеп туры юлга күнәрләр.

**5 сүрә**

67 Ий Аллаһуның рәсүле! Раббыңнан индерелгән Коръән хөкемнәрен кешеләргә ирештер! Әгәр Коръән хөкемнәрен ирештереп бетерсәң, Аллаһ йөкләгән пәйгамбәрлек бурычын үтәгән булырсың, әмма ирештереп бетермәсәң – пәйгамбәрлек бурычын үтәмәгән булырсың. Аллаһ сине дошман кешеләрнең шәреннән саклар, мөшрикләрдән курыкма, үз эшеңне эшлә! Имансыз кешеләрне Аллаһ, әлбәттә, туры юлга күндермәс.

68 Әйт: «Ий китап әһелләре! Сез хак диндә түгелсез, хәтта Тәүрат, Инҗил һәм Раббыгыздан индерелгән Коръән белән гамәл кылганыгызга чаклы», – дип. И Мөхәммәт г-м, сиңа Раббыңнан индерелгән Коръән хөкемнәре: әлбәттә, аларның күпләре явызлыкны һәм хакны инкяр итүне арттырадыр. Кяферләрнең хакны инкяр итүләре өчен хәсрәтләнмә!

69 Дөреслектә, гамәлсез коры ышанучылар һәм яһүдиләр, һәм насаралар, һәм ай,



АЛЛАҺЫДАН ИҢГӘН СҮЗ ҺӘМ ИЗГЕ ЯЗМАЛАР

гына, аны Раббы җибәргән чын пәйгамбәр дип таныганнар».

**Зәкәрия 13**

2 «Ул көнне потларның исемнәрен бу җирдән юк итәчәкмен, инде аларны бүтән искә алмаячаклар; ялган пәйгамбәрләрне вә әшәке рухны да җир өстеннән юкка чыгарачакмын.

3 Шул вакытта кем дә булса яңадан пәйгамбәрлек итә башласа, тудырган ата-анасы аңа: „Син яшәргә тиеш түгелсең, чөнки син, Раббы исемен телгә алып, ялган сөйлисең“, – дип, пәйгамбәрлек иткән чагында аны чәнчеп үтерәчәк».

**II Петердән хат 1**

19 Шуның өчен без пәйгамбәрләр сөйләгән Аллаһы хәбәренә тагын да ныграк ышана алабыз. Сез дә, караңгы урында балкып торган яктылыкка игътибар иткәндәй, бу хәбәргә әһәмият биреп, дөрес эшлисез. Көн житеп, йөрәкләрегезне таң йолдызы балкытканга кадәр, аңа әһәмият бирүегезне дәвам итәргә тиешсез.

20 Иң элек шуны аңлагыз: Изге язмадагы бер генә пәйгамбәрлек сүзен дә һичкем үз сәләтенә таянып аңлата алмый.

кояшка яки йолдызларга табынучылар – алардан Аллаһуга һәм ахирәт көненә ышанып, Коръән өйрәтүе буенча изге гамәлләр кылганнарына ахирәттә газап куркынычы булмас, һәм алар көенмәсләр.

**41 сүрә**

2 Ошбу Коръән рәхимле вә шәфкатьле Аллаһудан индерелгән хак китаптыр.

3 Ошбу китапның аятьләре ачык аңлатылды вә Коръәндә һәрнәрсә ачык өйрәтелде, гарәп телендә укылганы хәлдә, Аллаһудан индерелгән хак китап дип белгән кешеләр өчен.

4 Ул Коръән аның белән гамәл кылучыларны шатландырыр вә аның белән гамәл кылмаучыларга, җәһәннәм газабы хәзерләнде, дип хәбәр бирер. Бәлки кешеләрнең күбрәге Коръәннән баш тартты, алар Коръәннең хак сүзләрен ишетмәсләр. Баш тарткач ничек ишетсен?

5 Коръәнгә ышанмаучылар әйттеләр: «Ий Мөхәммәт г-м, син безне Коръәнгә чакырасың, безнең күңелебездә пәрдә бар ки – аны аңламас вә колакларыбызда саңгыраулык бар – аны ишетмәс вә синең илә безнең арабызда пәрдә бардыр, син үз динең илә гамәл кыл вә без дә үз

21 Пәйгамбәрлек сүзе беркайчан да кеше ихтыяры белән бирелмәде, кешеләр Аллаһыдан килгән хәбәрне Изге Рух белән рухландырылып сөйләделәр.

**II Тимутэйгә хат 1**

14 Син исә нәрсәгә өйрәндең һәм нәрсәгә инандың, шуларны дәвам ит, чөнки кемнән өйрәнгәнеңне беләсең.

15 Син Изге язмалар белән балачактан ук таныш. Алар сиңа, Мәсих Гайсәгә иман итү аша, котылуга алып баручы акыл бирә ала.

16-17 ...бөтен Язма Аллаһы тарафыннан рухландырылган һәм өйрәтү, шелтәләү, төзәтү һәм Аллаһыга яраклы булып яшәү турында үгет-нәсыйхәт бирү өчен файдалы.

**Яхъя 5**

39 «Мәңгелек тормышка ия булырга теләп, сез Изге язмада язылганнарны тикшерәсез, ә алар нәкъ Минем хакта шаһитлык бирәләр».

**Ишагыйя 40**

8 «...ә Аллабызның сүзе мәңге булачак».

**Марк 13**

31 «Күк һәм җир юкка чыгар, әмма Минем сүзләрем һичкайчан юкка чыкмас».

**Маттай 28**

18 ...«Күктә дә, җирдә дә бөтен хакимлек Миңа бирелде. <...>



динебез илә гамәл кылабыз», – дип.

6 Син аларга әйт: «Мин дә сезнең кебек үк бер адәм баласымын, ләкин миңа Аллаһудан вәхи киләдер, сезнең илаһыгызның ялгыз бер генә Аллаһ икәнлеге илә Аңа чын, иман китереп туры итагать итүче булыгыз һәм тәүбә итеп Аңардан гафу сорагыз! Мөшрикләргә һәлак булудыр».

**46 сүрә**

9 Син аларга әйт: «Мин пәйгамбәрләрдән әүвәлге пәйгамбәр түгелмен, дөньяда һәм ахирәттә сезгә вә миңа Аллаһ ни кылыр – белмим, мин Аллаһудан үземә вәхи ителгән аятьләргә генә иярәмен һәм мин Коръәнне кабул итмәүчеләрне җәһәннәм газабы илә куркытучы гынамын».

10 Әйткел: «Әйә беләсезме, хәбәр бирегез миңа, әгәр Коръән Аллаһудан иңгән булса, вә сез аны инкяр итсәгез вә Ягъкуб балаларыннан Габдулла Коръәндәге хөкемнәр Тәүратта барлыгы белән шәһадәт бирсә вә ул Коръәнне яхшы белгәне өчен аңа иман китерсә, ә сез исә наданлыгыгыздан Аңа иман китерүдән тәкәбберләндегез, инде сез кешеләрнең иң явызрагы буласыз түгелме?» Бит Аллаһ



АЛЛАҺЫДАН ИҢГӘН СҮЗ ҺӘМ ИЗГЕ ЯЗМАЛАР

20 ...Мин, дөнья беткәнгә тикле, һәрвакыт сезнең белән булам».

**II Көринтлеләргә хат 3**

4 Мәсих аша Аллаһы каршында менә шундый ышанычыбыз бар.

5 Безгә сәләт үзеннән-үзе килә дип дәгъва итә алмыйбыз: сәләтебез Аллаһыдан килә.

6 Ул безгә яңа килешү хезмәтчеләре булу сәләтен бирде. Яңа килешү – язылган Канунга түгел, Рухка нигезләнгән. Язылган Канун исә үтерә, ә Рух тормыш бүләк итә.

**Гәләтиялеләргә 3**

6 Ибраһимны исегезгә төшерегез. Изге язмада аның турында: «Ул Аллаһыга ышанды, һәм шуның белән тәкъва булып саналды» диелгән.

7 Моннан шуны аңлагыз: иманга таянучылар – Ибраһимның чын балалары.

8 Изге язма, Аллаһының башка халыкларны иман аркылы аклаячагын алдан күреп, Ибраһимга: «Бар халыклар синең аша фатиха алачак» дигән Яхшы хәбәрне белдерде. <...>

22 Әмма Изге язма бөтен дөньяны гөнаһ әсире дип игълан итә, шуңа күрә вәгъдә ителгән нәрсә иман итүчеләргә Гайсә Мәсихкә инану аша бирелә.



залимнәрне туры юлга һич тә күндермидер.

11 Коръәнгә ышанмаучылар әйтәләр: «Әгәр Коръән хәерле нәрсә булса, бу ышанучылар безне узмаслар иде...», – дип. Алар Коръән күрсәткән туры юлга кермәгәч, ошбу Коръән Мөхәммәттән чыккан иске ялган сүздер, диделәр.

12 Коръәннән элек Муса китабы Тәүрат индерелмеш иде, ул китап ышанучыларга имам вә рәхмәт иде. Вә ошбу Коръән әүвәлге китапларны тасдыйк итүче китаптыр, гарәп телендә индерелде, аның илә гамәл кылмаучы залимнәрне җәһәннәм илә куркытмак өчен вә аның илә гамәл кылучы яхшы мөэминнәрне җәннәт илә шатландыру өчен.

**6 сүрә**

50 Әйт: «Мин сезгә әйтмимен Аллаһ хәзинәләре минем кулымда һәм яшерен нәрсәләрне беләмен вә һәм мин фәрештәмен», – дип... Диндә һичкемгә, һичнәрсәгә иярмимен, мәгәр миңа Аллаһудан вәхи ителгән сүзләргә генә иярәмен. Әйт: «Күзле белән сукыр бертигез булырмы? Коръән сүзләрен аңлар өчен фикерләп карамыйсызмы?» – дип.

51 Үлгәннән соң кубарылып, Раббылары алдында хөкем

**Маттай 16**

1 Аннан соң Гайсә янына фарисейлар һәм саддукейлар килделәр. Сынарга теләп, Аңардан күктән берәр илаһи билге күрсәтүен үтенделәр.

2 Әмма Ул: «Кич белән сез: „Күк йөзе кызыл, шуңа күрә һава торышы яхшы булыр“, – дисез. <...>

4 Аллаһыга иман итмәүче явыз буын кешеләре! Илаһи билгеләр таләп итәсез, әмма сезгә Юныс пәйгамбәр галәмәтеннән башка билге бирелмәс», – дип җавап бирде.



ителүдән куркучыларны – җәһәннәм газабының катылыгы белән куркыт! Аларга анда Аллаһудан башка хуҗа һәм шәфкать итүче булмас, шаять, Аллаһуга тәкъвалык кылырлар...

**10 сүрә**

64 Аларга дөньяда һәм ахирәттә дә шатлыктыр. Аллаһ сүзләренә алышынмак юк, Ул ни әйтсә шул була, Аллаһуга дус булу – мәңгелек бәхеткә ирешү.

**75 сүрә**

16 Ул Коръән аятьләрен тәкрар әйтү белән телеңне тибрәтмә, Җәбраил г-м сиңа укыган аятьләрне ашыгып яныңа алыр өчен.

17 Тәхкыйк, Безнең өстебездәдер ул Коръәнне синең күңелендә җыймак һәм телендә укытмак.

18 Ул Коръәнне һәркайчан Җәбраилдән сиңа укытсак, аның укуына ияр!

19 Соңра ул Коръәнне яхшылап аңлатмак вә читеннәрен чишмәк Безнең өстебездәдер.

**17 сүрә**

82 Без мөэминнәрнең күңелләренә шифалы аятьләрне вә Коръәннән рәхмәтле хөкемнәрне индерәбез, әмма Коръән белән гамәл кылмаган залимнәргә Коръән аятьләре хәсрәтне вә һәлакәтне генә арттырыр. <...>







85 Синнән рух турында сорашалар, син аларга әйт: «Рух Аллаһуның бер мәхлукы ки, аны Аллаһудан башка һичкем белмидер, сезгә, ий кешеләр, белемнән өлеш бик аз бирелде».

86 Ий Мөхәммәт г-м, әгәр теләсәк, сиңа индергән Коръәнне кәгазьдән һәм күңелеңнән алыр идек, соңра бу эштән Безне тыярга ярдәмче тапмас идең. <...>

88 Акыллы кешеләргә әйт: «Әгәр кешеләр һәм җеннәр барчасы бер урынга җыелып Коръән кебек бер китап иҗат итәргә теләсәләр, бер-берсенә ярдәмләшеп Коръәнгә охшатып бер китап иҗат итәргә тырышсалар да, һич тә иҗат итә алмаслар».

89 Тәхкыйк, Без бу Коръәндә кешеләр өчен һәртөрле мисалларны вә гаҗәеп гыйбрәтләрне күрсәттек, хөкемнәрен ачык аңлаттык, шулай булса да кешеләрнең күбрәге Коръән белән гамәл кылудан баш тарталар, мәгәр кяфер булудан баш тартмыйлар.

90 Кяферләр әйттеләр: «Син безгә җирдән чишмә чыгарып бирмичә торып, сиңа, ягъни пәйгамбәрлегеңә, ышанмыйбыз.

91 Яки йөзем, хөрмә бакчаң булып, араларыннан чишмәләр агызганыңча.

92 Яки үзең әйткәнеңчә, күкне кисәк-кисәк итеп өстебезгә төшергәнеңчә, яки Аллаһуны вә фәрештәләрне алдыбызга китереп бастырганыңча.

93 Яки синең алтыннан өең булгангача яки күккә менгәнеңчә, күккә менсәң дә ышанмабыз, аннан китап алып килеп безгә укытмасаң, шушы нәрсәләрне эшләмәсәң сиңа иман китермибез», – диделәр. Син аларга әйт: «Минем Раббым һәр кимчелектән пакьтер, мин үзем дә әүвәлге рәсүлләр кебек кешедән булган бер рәсүлмен, сез сораган нәрсәләрне мин эшли алмыйм, андый эшләрне фәкать Аллаһ эшли». <...>

96 Әйт: «Сезнең белән минем арамда һәм пәйгамбәрлегемне исбат итүдә шаһит булырга Аллаһ җитәдер». Әлбәттә, Аллаһ бәндәләренең хәлләрен белүче вә күрүче булды.





## Хатын-кызлар турында

**Чыгыш 22**

16 «Әгәр бер ир кеше ярәшелмәгән гыйффәтле кызны алдап, аның белән якынлык кыла икән, ул, кызның атасына мәһәр түләп, кызны хатынлыкка алырга тиеш.

17 Әгәр атасы үзенең кызына бу кешегә кияүгә чыгарга рөхсәт бирми икән, теге ир кеше ул кыз өчен акчаны барыбер түләргә тиеш».

**Канун 24**

1 «Әйтик, берәр кеше хатын ала да, нинди дә булса ярамаган ягын табып, аннан күңеле кайта, һәм ир, аның кулына талак хаты тоттырып, өеннән куып җибәрә,

2 ә ул хатын, аның өеннән китеп, икенче кешегә кияүгә чыга.

3 Әгәр бу ир дә, күңеле кайтып, хатынга талак хаты биреп өеннән куып җибәрсә, яки шушы хатынга өйләнгән соңгы ир үлә калса,

4 ул чакта беренче ире бу хатынга яңадан өйләнә алмый, чөнки бу хатын аның өчен нәҗес санала. Шундый никах Раббыга җирәнгеч. Мондый гөнаһ белән Раббы Аллагыз сезгә биләмә итеп бирәсе җирне пычратмагыз».



## Хатын-кызлар турында

**2 сүрә**

226 Хатыннарына якынлык кылмаска ант иткән ирләргә дүрт ай көтмәк тиешле, әгәр тору нияте белән шул дүрт ай эчендә якынлык кылса, Аллаһ ярлыкаучы һәм рәхмәт итүче. <...>

228 Талак кылынган хатыннар икенче иргә барганчы, өч күрем үткәнче көтәрләр. Хәләл булмас ул хатыннарга Аллаһ халык кылган карыннарындагы баланы һәм күремне яшермәкләре, әгәр Аллаһуга һәм ахирәт көненә ышансалар. Ул талак кылынган хатыннарны үз ирләре өч күрем эчендә кайтарып алырга хаклы, әгәр яхшы торырга теләсәләр. Хатыннарның ирләре өстендә хаклары бар, ирләрнең хатыннары өстендә хаклары булган кебек. Ир һәм хатын бер-берсен хөрмәтләп һәм хакларын ригая кылып, Аллаһ кушканча яшәргә бурычлы булалар. Ирләр дәрәҗәсе хатыннар дәрәҗәсенә караганда өстенрәк. Аллаһ барча эштә галиб һәм белеп хөкем итүче.

229 Талак ике мәртәбә – ягъни ир хатынын бер мәртәбә талак кылгач та, икенче мәртәбә талак кылгач та бергә торырга теләге булса, кайтарып

**Маттай 5**

28 «Ә Мин сезгә әйтәм: ха-
тын-кызга җенси теләк белән
караучы күңеленнән инде
зина кылган була».

**Саннар 5**

29 «Көнчелек турындагы канун
әнә шундый. Хатын үзенең
иренә хыянәт итсә һәм нә-
җесләнсә,
30 яки ирендә, шик туып, хаты-
нына карата көнчелек хисе
уянса, ул үзенең хатынын
Раббы алдына китереп бас-
тырсын. Рухани исә бу хатын
белән алда әйтелгән канун
нигезендә эш итсен.
31 Шул очракта ир кеше гөнаһ-
тан азат булачак, хатын исә
кылган гөнаһы өчен җәза
алачак».

**Марк 10**

2 Гайсә янына фарисейлар кил-
деләр һәм, Аны сынарга те-
ләп: «Ир кешегә хатынын
аерып җибәрергә Канун
рөхсәт итәме?» — дип сора-
дылар. <...>
9 «Аллаһы кушканны кеше аер-
масын». <...>
11 «Ир кеше, хатыны белән
аерылышып, башкага өй-
ләнә икән, беренче хатыны
алдында зина кыла дигән
сүз, — диде Гайсә. —
12 Шулай ук хатын кеше дә,
иреннән аерылып, башкага
кияүгә чыкса, зина кыла,
димәк».

ИНЖИЛ, ТӘҮРАТ

алырга хаклы була... Икенче
талактан соң кайтарып алса,
шәригать кушканча гадел-
лек белән хатын итеп тот-
мак лязим, аерып җибәрсә
дә яхшылык белән җибәрү
тиештер. Хатыннарыгызны
талак кылгач, аларга бир-
гән мәһәрләрегездән аз гы-
на нәрсәне алу да сезгә һич
хәләл булмый, мәгәр хәләл
булыр Аллаһ чикләгән чик
эчендә генә яши алмаудан
курыксалар. Аллаһ чигендә
каим булудан курыксагыз...
шундый хәлдә хатын ирдән
алган мәһәрне яки башка
малын биреп, үзен талак
кылдырыр, икесе дә гөнаһ-
лы булмас. Бу бәян ителмеш
хөкемнәр Аллаһ чикләгән
чиктер, бу чиктән үтмәгез!
Берәү Аллаһ чигеннән үтеп
китсә, ул, әлбәттә, залимдер.

**4 сүрә**

35 Әгәр ир белән хатын арасын-
да фетнә һәм дошманлык
туса, шул вакытта тормыш-
лары бозылудан курыксагыз,
гаделлек белән тикшереп
араларын төзәтү өчен ир-
нең якыннарыннан бер гадел
кешене һәм хатын ягыннан
бер гадел кешене билгеләгез.
Әгәр билгеләнгән кешеләр
ир белән хатын арасын чын
күңелдән төзәтергә теләсә-
ләр һәм төзәтү өчен бөтен
чараларны кылсалар, Аллаһ,

КОРЪӘН



ХАТЫН-КЫЗЛАР ТУРЫНДА

**Маттай 19**

9 «Сезгә әйтәм: ир кеше, зина
кылудан башка сәбәп арка-
сында хатыны белән аерылы-
шып, башкага өйләнә икән,
ул зина кыла».

**Маттай 5**

32 «Ә Мин сезгә әйтәм: әгәр ир
кеше, зина кылудан башка
сәбәп аркасында хатыны бе-
лән аерылышса, ул хатынын
зина кылуга этәрә. Аерылган
хатынга өйләнгән кеше дә
зина кыла».

**Чыгыш 20**

17 «Башка берәүнең өенә, ха-
тынына, ир яки хатын-кыз
колына, үгезенә яки ишәге-
нә — гомумән, кеше малына
нәфесеңне сузма».

**Левиләр 12**

2 «Исраилиләргә игълан ит:
„Әгәр берәр хатын, балага
узып, ир бала тудырса, ул
хатын, күрем вакытындагы
кебек, җиде көн нәҗес булыр.
3 Ир баланы сигезенче көндә
сөннәткә утыртырга кирәк;
4 ә хатын-кыз, кан килүдән чис-
тарынганчы, утыз өч көн
дәвамында һичнинди изге
нәрсәгә кагылмаска, Изге
чатырга кермәскә тиеш.
5 Кыз бала тудыручы хатын, кү-
рем вакытындагы кебек, ике
атна нәҗес булыр; алтмыш
алты көн узып, кан килү тук-
талганнан соң гына, пакь
саналыр“».

ИНҖИЛ, ТӘҮРАТ

тәүфыйк биреп, ир белән ха-
тын арасына дуслыкны са-
лыр. Дөреслектә, Аллаһ ке-
шеләрнең гамәлләрен белүче
һәм күңелләрендәге теләклә-
реннән хәбәрдар булды. <...>
129 Карт хатын белән яшь хатын
арасын тигезләргә такатегез
җитмәсә, тигезләү өчен нык-
лап тырышсагыз да, шулай
да яшь хатыннарыгыз ягы-
на бөтенләй авышып, карт
хатыннарыгызны нәүбәт-
тән өлешсез итеп, ирсез ха-
тыннар кебек калдырмагыз!
Әгәр хатыннарыгыз арасын-
да төзеклек белән торсагыз
һәм золымнан саклансагыз!
Шулай булганда, әлбәттә,
Аллаһ кимчелекләрегезне
ярлыкаучы вә рәхмәт итүче
булды.
130 Әгәр ир белән хатын киле-
шә алмыйча аерылышсалар,
Аллаһ Үзенең рәхмәте белән
икесен дә моңсыз кылыр, бит
Аллаһ киң рәхмәтле вә мәс-
лихәтчә эш кылучы булды.

**4 сүрә**

3 Ятимнәрне гаделлек белән
тәрбия кылырга курыкса-
гыз, ятим булган кызлардан
күңелегезгә хуш килгәнен
үзегезгә никах кылып алы-
гыз: икешәр, өчәр һәм дүртәр
кылып, әгәр гаделлек кыла
алмабыз дип курыксагыз,
фәкать берне генә никахла-
ныгыз, әгәр бергә дә гаделлек

КОРЪӘН

**Левиләр 20**

18 «Әгәр берәр кеше күрем күрүче хатын-кыз белән якынлык кылса, алар икесе дә нәҗеслектән арыну канунын бозган булып исәпләнә, һәм алар икесе дә халыктан читләштерелергә тиеш». <...>

26 «Минем алда изге булыгыз, чөнки Мин, Раббы, изгемен. Мин сезне Үзем өчен башка халыклардан аерып алдым».

**Канун 22**

5 «Хатын-кыз – ирләр кебек, ә ирләр хатын-кыз кебек киенмәсеннәр, шулай эшләүче һәркем Раббы Аллагызга җирәнгеч».

**Левиләр 20**

14 «Әгәр нинди дә булса ир үз хатыны өстенә аның анасын да хатын итеп ала икән, бу – бозыклык; сезнең арагызда бозыклыклар булмасын өчен, ул ир дә, әлеге хатыннар да яндырып үтерелсен».

**Левиләр 21**

9 «Әгәр руханиның кызы, фәхешлек кылып, үзен нәҗесли икән, ул үзенең атасын хур итә, һәм ул кыз яндырып үтерелергә тиеш».

**I Көринтлеләргә хат 14**

34 ...хатыннар бердәмлек җыелышларында дәшмәсеннәр, чөнки аларга анда сөйләргә рөхсәт ителми. Муса



кыла алмасагыз, ул вакытта сатып алган кәнизәкләрегез җитәр. Югарыдагы хөкемнәр ышанычлырактыр хактан үтеп китмәвегез өчен.

4 Сөйләшеп, ризалык белән бирергә өстегезгә алган мәһәрне хатыннарыгызга бирегез, әгәр хатыннарыгыз риза булып мәһәрдән бер өлеш бирсәләр, рәхәтләнеп ашагыз. <...>

6 Ятимнәрнең акылларын тәҗрибә кылыгыз никахланырга яраклы булганга чаклы, аларның акыллары камилләшкәнен күрсәгез, малларын үзләренә кайтарып бирегез. Хыянәт вә мәкер юл белән ятимнәр малын аз гына да ашамагыз...

**2 сүрә**

222 Янә синнән хатыннарның күрем каны хакында сорыйлар. Әйт: «Күрем каны нәҗес кан», – дип. Күремле вакытларында хатыннарыгыздан киселеп торыгыз, күремнәре бетеп, пакьләнгәннәренә чаклы. Күремнәреннән пакьләнсәләр, Аллаһ әмер иткән урыннан якынлык кылыгыз. Дөреслектә, Аллаһ тәүбә итеп төзәлүчеләрне һәм күңел, тән нәҗесләреннән пакьләнүчеләрне сөядер.

223 Хатыннарыгыз сезгә игенлек урыны, үзегез теләгән яктан игенлекләрегезгә килегез!..





канунында әйтелгәнчә, алар буйсынучан булырга тиеш.

35 Алар нәрсә булса да белергә тели икән, өйләрендә ирләреннән сорасыннар, чөнки бердәмлек җыелышында хатыннарның сөйләве урынлы түгел.

36 Аллаһы сүзе сездән чыктымы әллә? Әллә сезгә генә килеп ирештеме?

**I Көринтлеләргә хат 11**

8 Ир – хатыннан түгел, хатын – ирдән,

9 һәм ир хатын өчен түгел, хатын ир өчен яратылган.

**I Тимутәйгә хат 2**

8 Инде шуны телим: ир-атлар һәр җирдә рухи яктан саф булып, ярсымыйча вә бәхәсләшмичә, кулларын күтәреп дога кылсыннар.

9 Хатын-кызларга исә әдәплелек саклап, тыйнак һәм килешле киенергә кирәк. Алар үзләрен алтын, энҗе, кыйммәтле кием белән һәм чәчләрен үреп түгел,

10 ә игелекле эшләр белән бизәсеннәр....

11 Хатын-кыз күндәмлек белән тавыш-тынсыз гына өйрәнсен.

12 Хатын-кызга ир-атны өйрәтергә, аның өстеннән баш булырга рөхсәт итмим, ул тавыш-тынсыз булсын.

13 Башта Адәм, аннан соң Һава яратылган бит,



Аллаһудан куркыгыз, Аның хөкемнәрен бозудан сакланыгыз! Яхшы белегез, ахирәттә, әлбәттә, Аллаһуга юлыгырсыз...

**16 сүрә**

58 Әгәр ул мөшрикләрнең берсенә «кыз балаң туган» дип сөенеч бирелсә, хатынына ачуланып, дусларыннан оялып, йөзе каралып китәдер.

59 Кыз белән сөенеч бирелгәнлектән хурланып кавеменнән качадыр, уйлап торадыр: бу кызны хурланып кына асрыйммы икән? Яки тереләтә туфракка күмеп таптыйммы икән, дип. Агаһ булсыннар, кылган эшләре нинди яман кабахәт эштер! <...>

72 Аллаһ сезнең өчен үз җенесегездән хатыннар халык кылды вә хатыннарыгыздан сезгә балалар вә балаларның балаларын яратты вә сезне хәләл яхшы ризыклар белән ризыкландырды, әллә кире кешеләр ялганга ышанып Аллаһ нигъмәтләрен инкяр итәләрме?

**4 сүрә**

7 Ата-анасы вә якын кардәшләре калдырган малдан ирләргә өлеш булыр вә хатыннарга да ата-анасы вә якын кардәшләре калдырган малдан өлеш булыр, мал күп булса да, аз булса да. Калган малны

14 һәм Адәм алданмаган, хатын-кыз, алданып, әмерне бозган.

15 Әмма әдәплелек белән иман, мәхәббәт һәм әүлиялектә торса, ул ана булу вазифасын үтәп котылачак.

**I Петердән хат 3**

7 Ирләр, сез дә хатыннарыгызның үзегездән көчсезрәк булуын истә тотып, аларга игътибарлы булып яшәгез. Аларны хөрмәт итегез, алар да сезнең кебек үк Аллаһыдан тормыш бүләген кабул итеп алалар бит. Шул рәвешчә догаларыгызга тоткарлык булмас.

**I Көринтлеләргә хат 11**

11 Хәер, Хаким Гайсә алдында ир – хатыннан, хатын ирдән бәйсез түгел,

12 чөнки хатын ирдән яратылгандай, ир дә хатыннан туа. Ә һәрнәрсә Аллаһыдан килә.

**Гәләтиялеләргә 3**

26 Гайсә Мәсихкә булган иманыгыз аша барыгыз да – Аллаһы балалары. <...>

28 Инде яһүди белән грек, кол белән ирекле, ир-ат белән хатын-кыз арасында аерма юк, чөнки сез барыгыз да Мәсих Гайсәдә бер.

**Саннар 27**

8 «Ә исраилиләргә аңлат: „Әгәр берәү үлсә һәм аның улы булмаса, мирасы аның кызына тапшырылырга тиеш“».

ИНЖИЛ, ТӘҮРАТ

тиешле кешеләргә тапшыру диндә фарыз булды. <...>

11 Аллаһ балаларыгыз хакында булган мирасны бәян итәдер: үзегез үлеп, балаларыгыз калганда, ир балага хатыннарга биргәннең ике өлеше бирелер. Әгәр бар да хатын булып икедән артык булсалар, аларга малның өчтән бер өлеше бирелер, әгәр бер генә кыз булса, аңа калдырган малның яртысы бирелер. Әгәр мәетнең баласы булмаса, ата-анасы варис булыр, анага өчтән бер өлеше, калганы атага булыр. Әгәр мәетнең бертуган кешеләре булса, анасына алтыдан бер өлеш тияр. Мәетнең әйткән васыятен вә бурычларын үтәгәннән соң гына мирас малы бүленер. Ата-ана һәм угылларыгызның кайсылары сезгә якынрак файда итү йөзеннән, сез белмисез һәм кайсысына күпме мал тиешле икәнне дә белмисез. Әлбәттә, Аллаһ белеп хөкем итүче.

12 Әгәр хатыныгыз үлеп, малы калса, баласы булмаса, калган малның яртысы сезгә булыр. Әгәр баласы булса, калган малның сезгә дүрттән бере тияр, васыятьләрен вә бурычларын үтәгәннән соң. Калдырган малыгыздан хатыныгызга дүрттән бере тияр, әгәр балагыз булмаса.

КОРЪӘН





**Лүк 8**

2 Гайсә явыз рухлардан һәм авырулардан савыктырган хатын-кызларның берничәсе – Гайсә җиде җенне куып чыгарган магдалалы Мәрьям...

**Маттай 22**

30 «Үлеләр терелгәндә, алар өйләнмәсләр дә, кияүгә дә чыкмаслар. Алар күктәге фәрештәләрдәй булачаклар».

ИНЖИЛ

Әгәр балагыз булса, хатыныгызга калдырган малның сигездән бере тияр, әйткән васыятегезне вә бурычларыгызны үтәгәннән соң...

**4 сүрә**

176 Ий Мөхәммәт г-м, мирас малы хакында синнән фәтва сорыйлар. Син аларга әйт: «...Әгәр бер ир үлсә, аның ата-анасы һәм баласы булмаса, бертуган кыз кардәше калса, бу кыз кардәшенә үлгән кәләлә малының яртысы тияр, әгәр кәләлә ир исән калып, әлеге кыз кардәше үлсә, ул кыз кардәшенең баласы калмаса, ул чагында калган малга кәләлә варис булыр. Әгәр кәләлә ир үлеп аның ике бертуган кыз кардәшләре калса, аларга кәләләдән калган малның өчтән ике өлеше тияр, әгәр кәләлә ирнең калган бертуган кардәшләре ирләр һәм хатыннар булса, иргә ике хатынның өлеше тияр. Болар кәләләдән калган малның өчтән ике өлешен бүләрләр». Аллаһ сезгә ачык бәян кылыр мирас хөкемнәрен, мал бүлүдә адашмавыгыз өчен. Аллаһ һәрнәрсәне белүче.

**3 сүрә**

195 Аллаһ мөэминнәрнең сорауларын кабул итте, сезләрдән гамәл кылучының гамәлен

КОРЪӘН

Мин, әлбәттә, юкка чыгармыйм, ул гамәл кылучы кирәк – ир, кирәк – хатын булсын, гамәлдә барыгыз да бертигезсез...

**16 сүрә**

97 Изге гамәлләр кылган хак мөэминнәр кирәк – ир булсыннар, кирәк – хатын булсыннар, аларга дөнья вә ахирәт, хуш тереклек бирербез, вә аларга кылган гамәлләреннән күркәмрәк әҗерен бирербез.





## Сугыш турында

**Канун 20**

1 «Дошманнарыгызга каршы сугышка чыккач, сез атларны, арбаларны һәм сан ягыннан сездән күпкә артык сугышчыларны күрерсез, ләкин курыкмагыз, чөнки сезне Мисыр җиреннән алып чыккан Раббы Аллагыз сезнең яныгыздадыр.

2 Сугыш башланганчы, иң элек гаскәр алдына сүз әйтергә рухани чыксын

3 һәм: „И исраилиләр, тыңлагыз! Бүген сез дошманга каршы сугышка барасыз: батыр булыгыз, курыкмагыз, борчылмагыз һәм алар алдында коелып төшмәгез.

4 Сезгә җиңү китерергә, дошманыгызга каршы сугышырга сезнең белән бергә Раббы Аллагыз бара“, – дип әйтсен.

5 Җитәкчеләр гаскәргә: „Кемдер, яңа йорт төзеп, анда яшәргә өлгермәгән булса, йортына кайтсын, чөнки сугышта үлә калса, йортына башка кеше кереп урнашыр.

6 Кемдер, йөзем бакчасы утыртып, аннан файдаланмаган булса, ул кеше үзенең йортына кайтсын, чөнки сугышта үлә калса, аннан башка кеше файдаланыр.

7 Кемдер, кыз белән ярәшеп тә, әле аңа өйләнмәгән булса,



## Сугыш турында

**109 сүрә**

1 Ий Мөхәммәт г-м, әйт: «Ий сез кяферләр, иман китермәгән кешеләр!

2 Сез гыйбадәт кыла торган сыннарга мин гыйбадәт кылмыймын.

3 Һәм сез дә мин гыйбадәт кыла торган Аллаһуга гыйбадәт кылмыйсыз.

4 Вә мин сезнең гыйбадәт кыла торган сыннарыгызга гыйбадәт кылучы түгелмен.

5 Вә сез мин гыйбадәт кыла торган Аллаһуга гыйбадәт кылучы түгелсез.

6 Сезнең батыйль ялган динегез үзегезгә булсын вә минем хак динем үзебезгә булсын!

**22 сүрә**

38 Аллаһ мөэминнәрдән кяферләрнең золымын җибәрер, Аллаһ, әлбәттә, хыянәтче, кяферлек кылучыны яратмый.

39 Кяферләр өстенә сугыш белән барырга мөэминнәргә Аллаһудан рөхсәт бирелде, кяферләрдән золым күргәннәре өчен, тәхкыйк, Аллаһ мөэминнәргә ярдәм бирергә кадир.

40 Ул кяферләрдән золым күрүче мөэминнәр: «Безнең Раббыбыз – Аллаһ», – дип әйткән өчен йортларыннан чыгарылдылар. Әгәр Аллаһу

йортына кайтсын, чөнки сугышта үлә калса, аның кәләшенә башка кеше өйләнер“, – дип әйтсеннәр.

8 Җитәкчеләр гаскәргә тагын шуны әйтсеннәр: „Әгәр кемдер курка һәм аның кыюлыгы җитми икән, иптәшләренең йөрәген дә үз йөрәге кебек кыюсыз итмәсен өчен, өенә кайтып китсен“.

9 Җитәкчеләр боларның барысын да гаскәргә җиткергәннән соң, сугышчылар өстеннән гаскәрбашлары куелсын.

10 Сез шәһәрне яуларга килгәч, башта аңа солых төзергә тәкъдим итегез.

11 Әгәр шәһәр, сезнең тәкъдимне кабул итеп, капкаларын ачса, бу шәһәрдәге бар халык сезгә хезмәт итәргә мәҗбүр булыр.

12 Әгәр инде ул сезнең белән солых төзергә риза булмыйча сугыша башласа, ул вакытта шәһәрне камап алыгыз.

13 Раббы Аллагыз аны сезнең кулга тапшыргач, андагы барлык ирләрне кылычтан уздырыгыз.

14 Хатын-кызларны, балаларны һәм терлекне, шәһәрдәге бөтен нәрсәне исә үзегезгә алыгыз һәм Раббы Аллагыз сезгә биргән, дошманыгыздан яулап алган шушы малдан файдаланыгыз.

15 Шактый еракта урнашкан, әйләнә-тирәгездәге



Тәгаләнең залим кешеләрне гадел кешеләр белән бастырып мәзлумнарны яклавы булмаса иде, әлбәттә, монахларның сумгалары, насараларның чиркәүләре, яһүдләрнең гыйбадәт йортлары вә мөселманнарның Аллаһуның исеме күп зекер ителә торган мәсҗидләре егылып җимерелер иде. Аллаһ... диненә нинди юл белән булса да ярдәм итүчегә, әлбәттә, Аллаһ ул кешегә ярдәм бирер, Аллаһ куәт иясе вә һәр эштә җиңүче.

**3 сүрә**

146 Пәйгамбәр белән бергә Аллаһуга бирелгән күпме мөэминнәр сугышларга чыктылар. Алар сугышларның катылыгыннан ирешкән авырлыктан курыкмадылар, дошманның гаскәре күплегеннән зәгыйфьләнмәделәр вә гаҗизлек тә, мескенлек тә күрсәтмәделәр, бәлки гайрәт белән сугыштылар. Гайрәт белән сугышучыларны вә авырлыкны күтәрүче сабырларны Аллаһ сөяр.

**60 сүрә**

1 Ий мөэминнәр, Минем дошманым вә сезнең дошманыгыз булган кяферләрне дус тотмагыз, ул кяферләрне яшерен дус тотасыз вә дуслык сәбәпле пәйгамбәрнең эшеннән аларга





халыкларныкы булмаган шәһәрләр белән шулай эш итегез.

16 Раббы Аллагыз сезгә биләмә итеп бирәсе җирдәге халыкларның шәһәрләрендә исә бер җан иясен дә исән калдырмагыз.

17 Раббы Аллагыз сезгә кушканча, бу халыкларны – хиттиләрне, амориләрне, кәнганиләрне, фәризиләрне, хиввиләрне, явүсиләрне – тәмам юк итегез.

18 Юкса алар сезне үз илаһларына табынганда кылган җирәнгеч гадәтләренә өйрәтерләр, һәм сез, шулай итеп, Раббы Аллагыз каршында гөнаһлы булырсыз.

19 Әгәр ниндидер шәһәрне яулап алмакчы булып, озак вакыт камалышта тотасыз икән, әйләнә-тирәдәге агачларга балта тидермәгез – сез аларның җимешен ашый аласыз. Кырдагы агач – камалышта калган кеше түгел бит.

20 Бары җимеш бирми торган агачларны гына кисәргә мөмкин. Шәһәр җиңелгәнче, сез алардан һөҗүм вакытында ярдәм итүче корылмалар ясый аласыз».

**Канун 21**

10 «Дошманнарыгызга каршы сугышка чыккач, Раббы Аллагыз аларны сезнең кулга



хәбәр җибәрәсез... Тәхкыйк, (алар)... сезгә Раббыгыздан килгән, хак булган Коръәнне инкяр иттеләр, рәсүлне вә сезне Мәккәдән чыгардылар фәкать Аллаһуга иман китергәнегез өчен, әгәр сез Минем юлыма җиһад өчен һәм ризалыгымны эстәп чыксагыз, кяферләргә яшерен дуслык кыласыз. Мин сезнең яшергән нәрсәгезне дә һәм әшкярә кылган эшләрегезне дә белүчерәкмен. Сездән берәрегез кяферләргә яшерен дус булса яки мөселманнарның серен кяферләргә ирештерсә, дөреслектә, ул кеше туры юлдан адашты, ягъни имансыз калды.

**3 сүрә**

103 Ий мөэминнәр! Барчаларыгыз да берләшкән хәлегездә Аллаһ арканына, ягъни Коръән хөкемнәренә ныклап ябышыгыз! Аннары Коръән хөкемнәреннән һич тә аерылмагыз һәм бер-берегездән киселеп төрле юлларга китмәгез! Янә Аллаһ сезгә биргән нигъмәтләрен күңелегездә саклагыз, бит мөселман булмас борын бер-берегезгә дошман идегез. Аллаһ ислам дине белән күңелегезгә дуслык, өлфәт мәхәббәт салды да, бер-берегезгә дин кардәше булып әверелдегез...

тапшырыр, һәм сез әсирләр алырсыз.
11 Әгәр берәрегезнең әсирләр арасындагы чибәр хатын-кызга күзе төшеп, аны яратса һәм хатынлыкка алырга теләсә,
12 аны үзенең йортына алып кайтсын; ул хатын-кыз башындагы чәчен һәм тырнакларын киссен,
13 элеккеге киемнәрен салып ташласын һәм, ире йортында яши башлап, бер ай буена ата-анасын уйлап еласын. Шуннан соң ир кеше аның белән якынлык кыла ала, һәм ул аның хатыны булыр».

**Йоил 3**

9 «Бар халыкларга игълан итегез: „Сугышка әзерләнегез, яугирләрегезне орышка чакырыгыз – бөтен сугышчылар күтәрелеп чыксын.
10 Сукадан – кылыч, уравтан сөңге очлыклары коегыз. Иң көчсезе дә, мин көчле, дип әйтсен“».

**Зәбур 143**

1 Раббыга – Кыяташыма мактау-шөкерләр! Кулларымны Ул сугышка, бармакларымны орышка өйрәтә.
2 Ул миңа Мәрхәмәт итүче, минем Ныгытмам вә Кальгам, Коткаручым вә Калканым! Мин Аңа сыенам, халкымны Ул миңа буйсындырып тота.



**16 сүрә**

125 Ий Мөхәммәт г-м һәм аның өммәте! Раббыңның юлы булган ислам диненә кешеләрне чакыр вә чакырыгыз Коръән дәлилләре белән, дәхи тәэсирле яхшы вәгазьләр белән, дәхи кешеләргә хаклыкны төшендерү өчен алар белән тартыш вә көрәш иң күркәм юл белән! Әлбәттә, синең Раббың Аның юлыннан адашкан кешеләрне белә; һәм Ул Коръән юлында булган хак мөэминнәрне дә белә.

**60 сүрә**

7 Ихтимал, Аллаһ мөшрикләрдән дошман булган якын кардәшләрегез белән сезнең арагызда дуслыкны булдырыр... Аллаһ кадирдер, бу эшкә көче җитәдер, һәм Аллаһ ярлыкаучы вә рәхимле.
8 Аллаһ сезне тыймыйдыр ислам диненә каршы сезнең белән сугыш кылмаган вә сезне йортыгыздан куып чыгармаган кавемнәр белән яхшы мөгамәләдә булудан һәм аларга гаделлек кылудан. Тәхкыйк, Аллаһ гадел кешеләрне сөядер.
9 Аллаһ, әлбәттә, сезне тыядыр ислам диненә каршы сезнең белән сугышкан вә сезне йортыгыздан куалап чыгарган һәм кяферләргә дус булып сезне йортыгыздан чыгарырга ярдәм иткән





3 И Раббы, ни-нәрсә ул кеше токымы?! – Алай да Син аны кайгыртасың! Адәм нәселе ни-нәрсә ул?! – Алай да Син аңа игътибар итәсең!
4 Кеше гомере – исеп киткән җил кебектер, аның яшәү көннәре – юкка чыгып барган күләгә генә.
5 И Раббы, күкләрне авыштыр да түбән төш, тауларга кагыл – төтәсеннәр;
6 яшен яшьнәт – тарат дошманнарны, укларыңны ат – качып китсеннәр!
7 Югарыдан кулыңны суз да коткар мине, тирән су төпкеленнән чыгар, чит-ят угыллар кулыннан азат ит:
8 аларның авызы ялган чәчә, уң куллары алдашуга хезмәт итә.

**Саннар 10**

35 Аллаһы сандыгы юлга чыккан саен, Муса: «Әй Раббы, күтәрел! Дошманнарың таралып бетсен, Сине өнәмәүчеләр алдыңнан качып китсен!» – дип әйтә иде.

**I Патшалар 17**

47 «Бирегә җыелганнарның да һәммәсенә мәгълүм булыр: Раббы кылыч вә сөңге белән коткармый. Бу сугыш Раббыныкы, һәм Ул сезне безнең кулга тапшыра»...

**Левиләр 26**

7 «Дошманнарыгызны сез куып җибәрерсез – алар сезнең кылычтан һәлак булырлар.



монафикъларга дус булудан. Кяферләргә һәм монафикъларга дус булган мөселманнар алар залимнәрдер.

**48 сүрә**

29 Мөхәммәт г-м Аллаһуның рәсүледер, ул рәсүл илә бергә булган хак мөэминнәр кяферләргә катылардыр, аларга һич шәфкать итмәсләр, вә үз араларында бер-берсенә шәфкатьлеләрдер...

**4 сүрә**

74 Мөэминнәр Аллаһ юлында сугыш кылсыннар ахирәтне дөньяга саткан – алыштырган кешеләр белән. Әгәр бер мөэмин Аллаһ юлында сугышып үтерелсә яки кяферне җиңсә, ул мөэмингә тиздән җәннәт нигъмәтләрен бирербез.
75 Ий мөэминнәр! Ни булды сезгә, кяферләр кулында әсир булган зәгыйфь ирләрне, хатыннар һәм балаларны коткару өчен сугышмыйсыз? Ул зәгыйфь ирләр: «Ий Раббыбыз, хуҗалары залим булган шәһәрдән безне чыгар», – диләр. Янә ул зәгыйфьләр: «Ий Раббыбыз, безне залимнәр кулыннан коткаручы бер вәли бир һәм Үз хозурыңнан безгә ярдәм дә бир», – диләр.
76 Иманлы кешеләр Аллаһ юлында сугышырлар. Әмма имансызлар шайтан юлында

8 Сезнең бишегез — йөз дошманны, ә йөзегез ун мең дошманны куар, сугышта дошманнарыгыз сезнең кылычтан кырылыр».

**Канун 32**

41 «„...ялтырап торган кылычымны үткенләгәч, кулым хөкем итәргә күтәрелгәч, дошманнарымнан үч алырмын, Мине күрәлмаучыларга тиешлесен бирермен.

42 Минем укларым һәлак булганнарның вә әсирләрнең канына манчылып кәефләнер, кылычым дошманнарның озын чәчле башларын кисеп канәгатьләнер“.

43 Аның халкы белән куаныгыз, әй чит халыклар! Чөнки Ул Үз колларының каны өчен үч алыр, дошманнарын Ул җавапка тартыр, Үз халкының җирен пакьләр».



сугышырлар. Шайтан дуслары — имансызлар белән сугышыгыз! Дөреслектә, шайтанның хәйләсе зәгыйфь булды, шуның өчен иманлы кешеләрне куркыта алмас.

**8 сүрә**

59 Кяферләр рәсүлдән алга чыктык дип хисап итмәсеннәр! Тәхкыйк, алар Аллаһу Тәгаләне гаҗиз кыла алмаслар.

60 Кяферләр белән сугышу өчен көчегез җиткән хәтле куәт белән хәзерләнегез вә яхшы атлар хәзерләгез! Шундый хәзерлек белән Аллаһ дошманнарын вә үзегезнең дошманнарыгызны куркыта алырсыз вә гарәп кяферләреннән башка кяферләрне дә куркытырсыз, башка кяферләрне сез белмисез, аларны Аллаһ белә. Сезнең Аллаһ юлына биргән атларыгыз, дөяләрегез, коралларыгыз һәм башка нәрсәләрегезгә сәвабы камил бирелер вә аларның сәвабын киметеп сезгә золым итү булмас.

**28 сүрә**

28 Муса әйтте: «Ошбу шарт синең белән минем арабыздадыр, ике мөддәтнең кайсын гына үтәсәм дә, арттыру белән мине димләү булмасын яки золым итү булмасын, ошбу сөйләшүләребезгә Аллаһ шаһиттер».





**9 сүрә**

29 Аллаһуга вә ахирәт көненә иман китермәгән кешеләр белән сугышыгыз вә Аллаһ һәм Аның рәсүле хәрам кылган нәрсәләрнең хәрамлыгына ышанмаган вә хак дин — исламны дин итеп алмаган кешеләр белән сугышыгыз! Алар китап бирелгән кешеләрдер, кимсетелгән хәлдә үз куллары белән җәза-түләү биргәнчегә чаклы алар белән сугышыгыз! <...>

36 ...барчагыз бер булып мөшрикләр белән сугышыгыз, бер-берегезгә ярдәмдә булыгыз, ташламагыз! Мөшрикләр сезнең белән барчасы бер булып сугышканнары кебек, вә белегез, Аллаһ тәкъвалар белән бергә. <...>

60 Садакалар — фәкыйрьләргә, мескеннәргә, әмир тарафыннан куелган зәкят җыючыларга, вә зәкят өчен исламга күңелләре өлфәт хасыйл иткән кешеләргә: тоткында булган кешеләргә, бурычын түләргә көче җитмәгән бурычлы кешеләргә, ислам дине өчен Аллаһ юлына һәм малсыз калган мөсафирләргәдер, шул күрсәтелгән урыннарга бирмәк Аллаһудан фарыз ителде. Аллаһ белүче вә хөкем итүче.

**3 сүрә**

157 Әгәр Аллаһ юлында үтерелсәгез яки үлсәгез, Аллаһ тарафыннан гафу ителү һәм рәхмәт кылыну, әлбәттә, сезнең җыйган дөнья малыгыздан хәерледер.

**2 сүрә**

190 Аллаһ юлында сугышыгыз, сезгә каршы сугыш башлаган кяферләр белән! Ләкин чиктән үтмәгез, ягъни үзегез сугыш башламагыз, сугыш башламау килешүен бозмагыз, сугышка катнашмаган кешене үтермәгез һәм әсирләрне җәберләмәгез! Аллаһ, әлбәттә, чиктән үтүчеләрне сөйми.

191 Кяферләр сезгә каршы сугыш башласалар, кайда очратсагыз шунда үтерегез һәм алар сезне чыгарган кеби, аларны өйләреннән чыгарыгыз, ягъни алар сезгә нинди золым кылсалар, сез дә аларга шулай җавап бирегез. Кяферләр мәсҗид Хәрам янында сезгә каршы сугыш башламасалар һәм сезне үтермәсәләр, аларны анда үтермәгез. Әгәр үзләре мәсҗид Хәрам тирәсендә сезгә каршы сугыш башласалар, ул вакытта аларны үтерегез! Кяферләрнең һәм мөшрикләрнең җәзасы шулдыр.

192 Әгәр ул мөшрикләр, сугыштан туктап, ислам динен







кабул итсәләр, Аллаһ, әлбәттә, ярлыкаучы һәм рәхимле.

193 Кяферләрне һәм мөшрикләрне үтерегез җир өстендә фетнә беткәнгә чаклы һәм җир өстендә Аллаһ дине – ислам гына калганга чаклы. Әгәр кяферлекне ташлап исламга керсәләр, аларга дошманлык күрсәтү юк, мәгәр Коръән юлына кермәгән залимнәргә дошман булу һәм аларны үтерү дөрес. <...>

216 Ий мөэминнәр! Үзегезне һәм динегезне саклау өчен кяферләрнең һөҗүменә каршы сугышу сезгә фарыз ителде. Ләкин үзегез өчен файдалы сугыш сезгә яман күренде, янә үзегез өчен изге булган нәрсәләрнең сезгә яман булып күренүе бик якын һәм үзегез өчен зарарлы булган нәрсәләрнең сөекле булып күренүе бик якын. Сезгә нәрсә файдалы, нәрсә зарарлы икәнлекне Аллаһ белә, әмма сез белмисез.

# Коръәндә очраган гарәп алынмалары сүзлеге

**Агяһ булу** – белеп тору.
**Бакый** – мәңге яшәүче, мәңгелек.
**Батыйль** – бозык; дөрес түгел.
**Бидгать** – элеккесенә каршы килә торган яңа бер эш.
**Бәгъзе** – кайбер.
**Бәлягатькә ирешү** – буйга җитү.
**Бәни Исраилгә** – Исраил угылларына.
**Варис** – мирас алган яки мирас алырга хокукы булган кеше.
**Важиб** – тиешле.
**Вәли** – ия, хуҗа; яклаучы; якыны.
**Вәхи** – Аллаһыдан пәйгамбәрләргә иңгән хәбәр.
**Вөҗүд** – барлык, бар булу.
**Гаиб** – күз алдыннан югалучы; күз алдында булмаучы.
**Галиб** – җиңүче, өстенлек алучы.
**Гареш** – тәхет, күкнең иң югары катламы.
**Гасый булу** – буйсынмау.
**Гаурәт** – тәннең кешегә күрсәтергә ярамый торган өлеше.
**Гафил** – ваемсыз.
**Гафләт** – игътибарсызлык, гамсезлек.
**Гаһед** – йөкләмә, килешү, ант итү.
**Гыйззәт** – кадер, хөрмәт, мәртәбә.
**Гөман** – уй, фикер; шик, шөбһә.
**Гөнаһкяр** – гөнаһ эшләр кылучы.
**Дәләләт** – дәлил.
**Дәрхаль** – шунда ук.
**Дәхи** – янә; шулай ук.
**Зан** – анык булмаган уй .
**Зарыйлык кылу** – зарлану.
**Зекер** – Аллаһыны зурлап һәм мактап укыла торган доганың бер төре.

**Зәкят** — ислам дине буенча сәүдәгәрләргә еллык керемнең 40 тан бере күләмендә салынган еллык налог.
**Зәляләт** — түбәнлек, хурлык.
**Игътикад итү** — чын күңелдән ышану, инану.
**Изһар** — күрсәтү, ачып салу.
**Илаһә** — Аллаһ; табына торган пот.
**Ингам** итү — яхшылык итү.
**Инкяр** — кире кагу, танымау.
**Ислях кылу** — үзгәртү.
**Истигъфар кылу** — Аллаһыдан гөнаһларны кичерүне сорау.
**Истирахәт кылу** — ял итү.
**Итагать** — буйсыну, күндәм булу.
**Иттифак** — бер сүздә булу, союз.
**Ифтира кылу** — яла ягу.
**Ихсан** — ярдәм, булышлык.
**Ихтыйлаф** — каршылыклы булу, фикер башкалыгы.
**Йөк йөкләү** — йөк төяү.
**Кадир** — көчле, булдыра алучы.
**Каим** — аяк өстендә басып торучы; төнне йокламый уздыручы.
**Карагыл** — кара төсле.
**Касд кылу** — ният итү.
**Кыбтый** — мисырлы.
**Кыйбла** — намаз укыганда йөз юнәлткән як; көньяк; идеядә юнәлеш, күзәткән максат.
**Кяфер** — динсез.
**Кәләлә** — ата-анасы да үлгән, балалары да булмаган кеше.
**Кәнизәк** — кол хатын.
**Кәфил** — гарантия бирүче, ышаныч күрсәтүче.
**Кәффарәт** — гөнаһтан котылу өмете белән кылынган эш.
**Көферлек** — Аллаһыны инкяр итү.
**Көфран** — Аллаһыны хурлау, танымау.
**Лязим** — тиеш, кирәк, мәҗбүри.
**Ләүхелмәхфуз** — язмыш тактасы.
**Мизан** — үлчәү, бизмән.
**Миннәт** — ярдәм, булышлык.
**Михраб** — мәчет түрендә кыйбла тарафын күрсәтүче махсус урын.
**Монафикъ** — икейөзле.



**Муафыйк** — яраклы, лаек.
**Мәгъбуд** — пот, санәм.
**Мәгъриб** — көнбатыш.
**Мәзлум** — җәберләнгән, кыерсытылган.
**Мәкруһ күрү** — читкә кагу.
**Мәнзил** — торак.
**Мәхкәм** — таза, чыдамлы, нык.
**Мәхлук** — җан иясе.
**Мәшрикъ** — көнчыгыш.
**Мәһәр** — калым.
**Мөбарәк** — кадерле; бәхетле, хөрмәтле.
**Мөддәт** — ара, вакыт.
**Мөсафир** — юлчы; узгынчы.
**Мөселман** — үзен Аллаһыга багышлаган, Аллаһы ихтыярына буйсынган кеше.
**Мөстәгъни** — кешегә хаҗәте төшмәүче.
**Мөшрикләр** — мәҗүсиләр, күп аллага ышанучылар.
**Мөэмин** — ышанучы, инанучы.
**Насара, насрани** — Гайсә диненә иярүче, христиан.
**Насраниять** — христианлык.
**Нигъмәт** — муллык.
**Нида** — чакыру, тавыш.
**Нәфес** — көчле теләк.
**Нәүбәт** — чират.
**Пакьләнү** — пакь булу, чистару; бозык хисләрдән, начар ниятләрдән арыну.
**Ригая** — кайгырту, хөрмәтләү.
**Риялану** — ясалма кылану.
**Рузә** — ураза.
**Рәсүл** — илче, пәйгамбәр.
**Рөкен** — әйбернең төп өлеше, нигез.
**Рөкүгъ** — иелеп тору, намазда тезләргә таяну.
**Сабит** — кузгалмаучы; үз уенда нык торучы; даими; шиксез, ачык.
**Садака** — сәдака; әҗер өчен бирелгән ярдәм, хәер.
**Сыгыну** — сыену.
**Сәваб** — савап, әҗер (яхшы эш өчен бирелгән бүләк); яхшы (изге) эш.

**Сәждә итү** — тезләнгән хәлдә алга бөгелеп табыну; берәү алдында хөрмәт белән, буйсынып баш ию.
**Таифә** — төркем, җәмәгать.
**Такать** — көч, куәт.
**Тасдыйк** — раслау, дөрес итеп әйтү, дөреслеген тану.
**Туба** — җәннәттә булган бер агач исеме.
**Тәгам** — аш, ашамлык.
**Тәдбир** — эшнең ахырын уйлап эшләү, алдан күрү.
**Тәкрар** — кабат, кабатлау.
**Тәкъва** — дин кушканны эшләү, диндар булу.
**Тәнбиһ** — кисәтү, искәртү.
**Тәсбих әйтү** — Аллаһыны зурлап, мактап әйтелә торган сүзләр, догалар.
**Тәхкыйк** — хакыйкатьтә, дөреслектә.
**Тәэвиле** — юралуы.
**Фазыл** — өстенлек, камиллек.
**Фарыз** — үтәлүе тиешле булган бурыч.
**Фасикъ** — әхлагы бозык кеше; Алласыз, имансыз.
**Фидия** — йолым.
**Фирка** — төркем, партия.
**Фәсад** — бозык, бозыклык.
**Фәтва** — нинди дә булса бер эшнең дини яктан дөресме, түгелме икәнлеген күрсәтеп бирү.
**Халык кылу** — бар итү, ярату.
**Хаҗәт** — кирәклек, кирәк нәрсә.
**Хилаф** — капма-каршы.
**Хитаб** — эндәшү, сүзне берәүгә юнәлтеп сөйләү.
**Хорафат** — юк-барга ышану.
**Хәерле (Аллаһыга карата)** — яхшы, изге, игелекле.
**Хәйрият** — яхшылык, изгелек, хәерлелек.
**Хәлифә** — берәүнең эшен үзеннән соң дәвам иттерүче.
**Хәләл** — шәригать тарафыннан тыелмаган, рөхсәт ителгән; намуслы; никахлы.
**Хәрам** — дини яктан тыелган нәрсә, законсызлык.
**Хөсетләнү** — көнләшү.
**Шикаять** — зар, зарлану, сукрану.
**Ширек** — күп аллага ышану, мәҗүсилек.
**Шәр** — явызлык, яманлык, начарлык.
**Шәригать** — дини закон.
**Шәрик** — иптәш, катнашучы.
**Шәфагать** — арадашлык, яклау, арага керү.
**Шәһадәт** — шаһит булу, күрсәтү.
**Эстәү** — теләү.
**Әшкярә** — ачыктан-ачык, яшермәстән.
**Әҗер** — бер эш өчен бирелгән нәрсә; савап.
**Өлфәт** — аралашу,ияләшү, дуслашу.
**Өммәт** — өммәт, пәйгамбәрнең дингә өндәгән халкы.
**Җиһад** — изге.
**Һибә кылу** — бүләк итеп бирү.
**Һидаять** — туры юлга кертү.
**Һәйбәт** — курку катыш хөрмәтләү тойгысы уята торган күренеш, мәһабәтлелек.

# Эчтәлек

Кереш сүз ........................................................................................ 3

Тәүрат, Зәбур, Инҗилдән алынган китапларның тулы һәм кыскартылган исемнәре ............................................................ 7

Тәүрат, Зәбур, Инҗил һәм Коръән ........................................... 9

Коръәндә очраган гарәп алынмалары сүзлеге .......................... 261

# ТӘҮРАТ, ЗӘБУР, ИНҖИЛ һәм КОРЪӘН
## охшаш урыннар

*Библия и Коран*
*параллельные места на татарском языке*

Институт перевода Библии
101000 г. Москва, Главпочтамт, а/я 360
www.ibt.org.ru
ibt_inform@ibt.org.ru

Подписано в печать **.**.2018
Формат 60×90 1/16. Печать офсетная. Усл. печ. л. 16,75
Тираж **** экз. Заказ №

Отпечатано в типографии “Акварель-принт”
Казань, ул. Тэцевская, 11
+7 (843) 571-91-35, +7 (843) 571-91-25